да да нәселләренең килеп чыгышын Бачман хан белән бәйләп караган шәҗәрәләр очрый. Бачман хан – «олбурлик» дигән кыпчак кабиләсеннән була. Ул үз янына монголларга буйсынырга теләмәгән Идел һәм Урал буе халыкларын туплый. Баш күтәрүчеләр арасында кумыклар, аслар, болгарлар һ.б. булуы мәгълүм. Нәкъ менә шушы факт, төрле ыру-кабилә халыкларының монгол яулап алуларына каршы бергәләп баш күтәрүе, әлеге шәхеснең исеменең төрле халыклар фольклорында саклануына китергән ахрысы. Баш күтәрүчеләр көчле гаскәр булып оеша һәм алар монгол басып алучыларына зур куркыныч тудыра. Бачманга каршы көрәшкә монголларның иң көчле гаскәр җитәкчеләре – Сүбәдәй һәм Мунке җитәкчелегендәге гаскәрләр күтәрелә. Бачман һәм аның кул астында көрәшүчеләр җиңелә һәм Бачман хан җәзалап үтерелә.

Тарихи чыганаклардан Бачман хан исеме Йакинф (И.Я. Бичурин), фарсы тарихчылары Җүвәйни һәм Рәшид-әд-дин хезмәтләрендә саклана. Җүвәйнинең «Тарих-и-җиһангуша» дигән хезмәтендә Бачман ханга аерым бүлек багышланган [Из «Истории завоевателя мира» Джувейни: 1941. С. 24].

Рәшид-әд-диннең «Җәми ат-әварих» хезмәтендә дә Бачман хан турындагы шушы ук риваять бәян ителә. Вакыйганың сүзгә сүз кабатлануыннан Рәшид-әд-диннең бу тарихны Җүвәйнидән алуы аңлашыла. Шулай да, Рәшид-әд-дин Бачман ханга карата тискәре эпитетлар кулланудан, аны бүре, шакал белән чагыштырып, түбәнсетергә омтылудан өстен кала.

Бачман хан турындагы риваять кытай чыганакларында да сакланган. Аны үзенең «История первых четырех ханов из дома Чингисова» дигән хезмәтендә Йакинф (Бичурин) кабатлый [Бичурин: 1829. С. 272, 303–304]. Әмма Җүвәйни хезмәтендәге өзектән аермалы буларак, бирелә Бачман хан чын батыр буларак сурәтләнә. Аңа азатлык өчен көрәшче буларак авторның хөрмәте чагыла. Йакинфта Бачман хан «Бацимак» дип бирелә. Өзектән Бачманның гади кеше булмавы, ә дәүләт башлыгы булуы, горур, намуслы кеше булуы аңлашыла. Кытай чыганаклары Бачманны ырусыз юлбасар итеп түгел, бәйсез хан итеп тасвирлыйлар. Кытай тарихчылары кулга төшкән Бачман ханның үзен горур тотуына соклануларын яшермиләр. Бачманның исеме «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә дә искә алына. Анда аның турында мәгълүмат бер җөмләгә сыйган. Ул «Урыннар һәм шәһәрләр турындагы дастан» дигән бүлектәге түбәндәге җөмлә: «Ак Түбә – Бачман ханның йорты иде». Ягъни «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә Бачман Туктамыш, Җанибәк кебек реаль ханнар янәшәсендә хан дип күрсәтелә. [Дәфтәре Чыңгыз-намә: 2000. Б. 37].

«Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә нинди территорияләрне кайсы ханнарга каравы күрсәтелеп, Бачман ханның «Ак Түбәдә» хан булуы язылган.

М.Г.Госманов Ак Түбә дигән урынны кайда урнашуын аңлатып: «Вактөяк төбәк һәм урын исемнәрен исәпкә алмаганда, Көнчыгыш Европадагы иң мәгълүм «Актүбә» дигән географик атама ул елга исеменнән гыйбарәт. Дөресрәге, Түбән Иделнең хәзерге Волгоград яннарыннан ук төп үзәннән бүленеп, Әстерханга хәтле диярлек аерым ага торган зур тармагы урта гасырларда да шулай Актүбә дип аталган. «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә дә, минемчә, шул Актүбә күздә тотыла», дип яза [Госманов: 1994. Б.287].

Дастанның тагын бер персонажы – Чачдар хан исеменең килеп чыгышы турында галимнәрдә төрле гитотезалар бар. Без, дастанның мифологик сюжетына нигезләнеп, бу исемне татар халык әкиятләре аша аңлатырга телибез. Татар халык әкиятләрендә су астында Аждаһа яши. Ул – Идел буе, Себер, Кавказ, Кече һәм Урта Азия халыклары мифологиясендә тискәре образ. Ул Иран мифологиясендәге Ажи-Дахакадан кергән. Иң киң таралган әкият сюжетлары буенча, Аждаһаның күңелен күреп аңа ел саен шәһәрнең иң чибәр кызын корбанга бирәләр. Аждаһаның Аждарһа дип аталуы да мәгълүм. Чачдар хан белән Аждарһаның охшаш яңгырашын истә тотып, бу ике геройны берләштереп булмыймы икән дип, фараз итәбез. Бу гипотезаның дөреслеген дастан сюжетын кытай, япон халыклары фольклоры белән чагыштыру да раслый. Кытай халыклары фольклорында дракон су асты патшасы. Кытайдан ераккарак киткән саен драконга Кытай императорларының исемен бирү күренеше ешая. Аждаһаның яшәү урыны төрле халыкларда төрлечә күрсәтелә. Үзбәк, төркмән, казакъ халыклары фольклорында Аждаһа җир асты мәгарәләрендә дә яши һәм андагы хәзинәне саклый. Татар, әзербайҗан, һәм башкорт халыклары мифологиясендә ул су, яңгыр болытлары белән бәйләнештә карала. Татар әкиятләрендә ул күлдә, диңгез төбендә яки диңгез эчендәге утрауда яши.

Дастанның Олы Кариле вариантының кыскача эчтәлеге болай. Бачман хан улы Түләкне иптәшләре яки абыйлары гел кыерсыталар. Шоңкар урынына ябалак, аргамак урынына аңа ике яшьлек кыркымыш тай бирәләр. Түләкнең ябалагы бер чөюдә җиде аккош (каз) алган шоңкарга, тае – җил җитмәс Тулпарга әверелә. Иптәшләре көнләшеп, атының тоякларына кадак сугалар. Түләк төшендә Хозыр Ильясны күрә. Ул аңа «Исме Әгъзам» догасын өйрәтә. Иптәшләре атның йөгәнен кисеп камчылыйлар. Ат Түләкне олы диңгез ярына китерә. Ярда су иясе Чачдар ханның кызы чәч тарый. Түләк җир тормышыннан ваз кичеп, кыз артыннан диңгез астына төшә, су кызына өйләнә. Әмма бераздан җирне сагынып, су өстенә чыга һәм җирдә яшәп үлә.

Су кызы образы белән бәйле фольклор әсәрләре күп халыклар иҗатында бар. Дастанда рус былинасы «Садко» белән охшаш урыннар еш

очрый. Мифологик үзенчәлекләрен саклаган былинаның фәнгә мәгълүм тугыз варианты да Олонец губернасында язып алынган. Бер вариантта Садко гөсләче, икенчесендә сәүдәгәр була. Гөсләче Садко Новгород сәүдәгәре белән «алтын канатлы» балык тотарга бәхәсләшә. Бәхәстә диңгез патшасы ярдәмендә җиңә. Аның сәүдә кораблары диңгездә туктап кала, ә Садконы, җирәбә буенча, диңгезгә төшерәләр. Диңгез патшасы сараенда Садко гөсләдә уйный, патша аның уенын бик ярата, бии башлый. Ул биегәндә диңгездә давыл чыга, диңгезчеләр бата башлый. Садко, Микола Угодник киңәшен тотып, гөслә кылларын өзә. Диңгез патшасы исә Садкога кызын бирә. Садко Микола киңәше белән шул кызга – Чернавага өйләнә. Йоклап киткән герой Чернава елгасы ярында уяна. Садко аннан соң Новгородта чиркәү салдыра [Былины Севера: 1938. 654 с.]. Ике әсәрдә дә геройлар музыка коралларында уйнап, диңгез патшасының мәхәббәтен яулыйлар. Икесе дә су кызына өйләнә. Дөрес, Түләк су кызына үзе гашыйк булып өйләнә, ә Садко диңгез патшасының тәкъдимен кабул итеп өйләнергә мәҗбүр була.

Л. Суходольский варианты «Түләкнең йөз иптәше бар иде» дип башлана. Алар барысы да тигез хокуклы кешеләр. Шулай да, аларның Түләкне һәрчак кыерсытулары сизелә. Кошның да, атның да иң начарын Түләккә бирәләр. Бу күренеш әкиятләрдәге төпчек ул, таз малай кебек образлар белән бәйле эпизодларны хәтерләтә. Геройларның төп шөгыле – ауга йөрүе дә әсәрнең архаиклыгына ишарәләүче деталь буларак карала ала [Урманчеев: 1984. С. 75]. Әкиятләрдәге корчаңгы тай Акбүз атка әверелгән кебек, Түләккә бирелгән ике яшьлек кырыкмыш тай да җил җитмәс аргамакка әйләнә, ак ябалак/ау шоңкарына әверелә. Түләкнең уңышларыннан көнләшкән иптәшләре, алда әйтелгәнчә, атының тоякларына кадак кагалар, ә геройга зыян китерү өчен атының тоякларына кадак кагу, иярен кисү кебек эпизодлар башка халыклар фольклорында да очрый. Галимнәр аерым шәхес һәм коллектив арасындагы конфликтның архаик характерда булуын әйтәләр. А.Н. Киреев бу конфликт борынгы община строе таркалуын күрсәтә дип саный. Көчле шәхеснең башкалардан аерылып торуы бөтен кабилә-ыруның протест белдерүенә китерә. Герой, яхшырак тормыш шартлары эзләп, кабиләдән китә [Киреев: 1970. С. 76]. Икенче вариантта Түләк ханның икенче хатыныннан туган улы буларак күрсәтелә, ә беренче хатыннан туган балалар нурлы йөзле Түләкне яратмыйлар.

Әсәрнең күпчелек вариантларында геройның тууы, балачагы турында мәгълүмат аз. Алар урта бер җиреннән башланган, башламы төшеп калган кебек фикер калдыра.

Төрки эпос традициясе буенча, геройның үзенә аталган аты – беренче ярдәмчесе һәм кайбер очракларда киңәшчесе була. Эпос герое атын

тапканда беренче батырлыгын кыла. Атны исә ул үзе сайлап ала, яки ул атын каяндыр табарга, яулап алырга тиеш. Түләккә атны, бер вариант буенча, иптәшләре бирә. Кырыкмыш тай җилдән җитез аргамакка әверелә. М.Г. Госманов тапкан вариантларда Түләкнең аты каян килгәне әйтелми, бары геройның менгән аты «Акбүзчә йил йитмәз», ягъни әкият атына хас сыйфатларга ия булуы гына әйтелә. В.И. Даль вариантында Түләкнең аты тулпар ат [Туль-фаръ]. Бары бу вариантта гына ат геройның киңәшчесе, ярдәмчесе ролен үти. М. Гафури вариантында Түләк атны атасының киңәшен тотып сайлый. Ат образы дастанга тагын бер тапкыр килеп керә. Түләк су астында яшәгәндә аны сагынып үз янына диңгез астына алдыра.

Аты Түләкне олы дәрья ярына алып килә (В.И. Даль вариантында Ачулы күл). Түләк диңгез ярында су кызын очрата: «Гайәт сахибе җәмалдыр (чырае матур), кем күрсә гыйшкындин җан бирердәй булыр иде. Ул су пәрие Чачдар хан дигән падишаһның кызы иде. Түләк аты туктаган йиргә кәлеп, һәр иртә сачын тарар иде... Сачының озынлыгы алтмыш карыш бар иде». Күпчелек вариантлар буенча, Түләк аны беренче тапкыр күрә. Түләк белән Су кызы бер-берсенә гашыйк була, әмма су кызы егетне калдырып китәргә омтыла, җир кешесенең башка стихиядән булуыннан курка: «Бу җегетне бер заман алдаламасам, шайәт кешегә катылып киткәймән, – тиде».

Түләк белән су кызы арасында шигъри диалог башлана. Түләк кызның исемен сорый:

Атың-йулың белмәймән, –
Атың әйтче, Сусылу!

Су кызы үзенең кем икәнен түгел, Түләкнең кем икәнен әйтеп бирә:

Атың-йулың белмәсәң,
Атың әйтеп бирәйем,
Атың үзең беләсән
Әрәмзәлек кыласән (алдашу):
Сары Миркас угълы сән –
Түләк атлы егет сән!

Түләк кызның исемен кабатлап сорый. Кыз:

Атым сорап нидәрсән?
....
Мән дә сәнлек түгелмән
Кайтып киткел, Түләгем! –

дип җавап бирә.

Түләк су кызына гашыйк булуын, аның белән булу өчен шоңкарыннан, аргамагыннан, ата-анасыннан баш тартырга әзер булуын аңлата. Су кызы исә Түләкне кире китәргә үгетли, бу мөнәсәбәтләрнең бәхетле булмаслыгын аңлата, диңгез астында яши алмаячагын әйтә. Сусылу Түләккә үзенең алтын сыргасын, йөзеген, тарагын, көзгесен тәкъдим итә. Г. Потанин һәм Л. Суходольский вариантларында тарак, көзге һәм ике шарф, ике йөзек күрсәтелә. Г. Потанин: «Бу бүләкләрнең ни өчен тәкъдим ителүе хәзер аңлашылмый. Алар геройга бернинди ярдәм күрсәтмиләр. Соңгы икесе, көзге белән тарак, геройның артыннан куа чыксалар коткарыр өчен кирәк булыр иде. Көзге диңгезгә, тарак урманга әверелергә тиеш. Түләкнең китүе кыз урлап качу түгелме, Чачдархан аларны куа чыкмыймы икән, дигән шик туа», дип яза.

Күренә ки, Түләк кошыннан, атыннан, ата-анасыннан ваз кичә. Ф. Урманчеев: «Халык эпосында ата-анадан баш тарту мотивы чагыштырмача сирәк очрый. Аны аңлар өчен, әсәрнең сәнгатьчә үзенчәлеген, идея-тематик эчтәлеген, дастанның беренче бүлегендәге конфликтны истә тотарга кирәк. Түләкнең ата-анасы традицион ыруг мөнәсәбәтләре тарафдарлары. Гаилә кору өчен алып барган көрәшендә Түләк алардан да баш тартырга тиеш була. Башка очракта аның эш-гамәлләре тиешле дәрәҗәдә ышандырырлык булмаячак. Шулай итеп Түләккә бөтен ыру-кабилә мөнәсәбәтләренә каршы көрәшергә дә, су кызының мәхәббәтен яуларга да туры килә», – дип яза [Урманчеев: 1984. С. 84].

Монда Түләкнең бөтенесеннән баш тартуын бүтәнчә дә аңлатып була. Диңгез патшалыгы, яки су стихиясе кабул итсен өчен, Түләк җир белән арасын өзәргә тиеш, ягъни ата-анасы, кошы-аты, туган туфрагы кешене туган җире белән бәйләп торган иң көчле объектлар. Ике стихия арасындагы чикне үтү өчен аны алдагы стихия белән бер нәрсә дә бәйләмәскә тиеш. Бер стихиядән тулысынча баш тарткан очракта гына, ул икенче стихиягә керә ала. Шуңа күрә герой бер-бер артлы бөтенесеннән ваз кичә. Ыруыннан, ата-анасыннан гына түгел, ә кош белән атыннан баш тартуын бүтәнчә аңлатып булмый. Башта ул кошын, аннары кыйммәте югарырак булган атын бирә, аннары гына ата-анасын. Түләкнең аларга булган мөнәсәбәте аны җиргә бәйләп торган җепләр. Җирне бөтенләй оныта алу, ягъни аларга булган хисләрдән азат булу, эмоциональ багажы булмау – аның алга таба бәхетле була алу шарты да. Су кызы Түләкне китәргә үгетли алмагач, алдалап качарга тели.

«Әнә аргы йагыңа
Килә торыр биш кеше, –
Күрмәймүсән, бай угълы?! –

дип, Түләкне читкә каратып үзе суга чумды, «Алтмыш карыш сачының алты карышы суга кермәгән иде – Түләк кызның сачыннан беләгенә

урап алды; [шулай] барып, кыз судан чыкканчы, beләгендин [йибәрмәде]» [Госманов: 1994. Б. 243]. Түләк кызның чәч толымын тотып аны буйсындыра, җиңү яулый. А.Н. Киреев бу эпизодны аңлатып: «Хатын-кызның чәч толымы халык иҗатында аның төп атрибуты булып саналуын искә төшерсәк, бу эпизод геройның көч һәм осталыгын күрсәтә. Ул кызның иң кыйммәтле әйбереннән, чәченнән эләктерә», дип яза.

Су кызы Түләкне су астына алып төшә. Монда кыз егет белән бәйләнешне өзәр өчен икенче омтылыш ясый, аны алдалап диңгез төбендә калдырып, үзе сараена кереп бикләнә. Түләк калган җирендә өч тәүлек көтә. Өченче көн Аллаһы Тәгаләдән монда «көн эсселеге» җибәрүен сорый. Егетнең догасы кабул була, бөтен сулар кибеп-корыйлар, эсселек түзәрлек булмый. Бу хәлне белгәннән соң, Чачдар хан кызына җир егетенә кияүгә чыгарга рөхсәт бирә.

«Түләк» дастанының сюжеты Япония һәм Кытайда яшәүче халыклар фольклорында да очрый. Мәсәлән, диңгез төбенә «Көн эсселеге», ягъни кояш җылысы җибәрү турындагы эпизод Кытайда яшәгән дунган халыклары әкиятләрендә дә бар. Диңгез патшасының өч кызы була. Кече кызы Чжинляр, җиргә чыгып, цитрада уйнаган Чжон Юйны очрата. Бер-берсенә гашыйк булган геройлар көзен очрашырга сөйләшәләр. Диңгез патшасы, кызны аның җиргә чыкканын белеп, бикләп куя. Кыз күкләр өчен билгеләнгән була. Билгеләгән көнне егет диңгез ярына килә. Кыз аңа көмеш казан, тимер кашык һәм алтын тәңкә җибәрә. Егет казанга тәңкәне салып, кашык белән диңгездән су сала. Казандагы су кайный башлагач, диңгез дә кайный башлый. Бөтен диңгез халкы ни эшләргә белми, драконга барып ялына. Диңгез патшасы, үзенең патшалыгын коткару өчен кызын җир егетенә кияүгә бирә [Дунганские: 1977. С. 49–56].

В.И. Даль вариантында су кызы Түләкне ал җайдактан – абыйсыннан һәм кара җайдактан – әтисеннән качырып асрый. Түләк алар булмаганда гына сарайдан чыга ала. Дунган әкиятендә герой су астына, ярда ике елан – ак һәм кара еланнарның сугышканын күреп, аларның агын коткаргач, эләгә. Ак елан диңгез патшасының улы була. Бераз вакыттан ул ак җайдакка әйләнеп, геройны су астына кунакка чакыра. Герой диңгез патшасының кызына өйләнә.

Кара җайдак, ягъни Диңгез патшасы, Түләк турында белгәннән соң аларга фатихасын бирә: «Яратышыгыз, – диде Ачулы һәм Кандракул хуҗасы. – Бер-берегезгә гашыйк булгансыз икән, берни эшләр хәл юк, яратышыгыз. Кызым, сине дә ачулана алмыйм. Бу синең тәкъдирең. Ә син, Зая Түләк, кызымны калымсыз кияүгә биргәнем өчен аны кимсетмә. Калым итеп кызыма мәхәббәтеңне бир» [Даль: 1843. С. 113].

Түләк белән Сусылу Диңгез төбендә күпмедер вакыт тыныч кына яшиләр. Беркөнне Сусылу җиргә чыгарга рөхсәт сорый. Ул һәр иртә ярга чыгып чәчен тарый, йөзен бизи. Шулвакыт Түләк тә җирне исенә төшерә, сагына башлый. Ул сагынуына түзә алмыйча Аллаһы Тәгаләдән аты белән кошны су астына төшерүен сорый. Алардан соң ул туган җиренең бер атрибуты булган Балкан тауны диңгез төбендә күрергә тели. Иртә белән торганда сарай алдында «алтын белән коршалган, мәрвәр берлә йапкан» тау – Балкан тавы тора. Әсәрдә ул тауга зур игътибар бирелә. Түләк туган ыругына, ата-анасына түгел, ә кат-кат Балкан тауга дан җырлый.

Бәнем тауым Балкан тау,
Башы һауага чыкган тау! –
Тимер берлә тайаган,
Алтын берлә коршаган,
Ак мәрмәрдән йапкан тау.

Тауларга мондый зур игътибар шулай ук дунган фольклорында очрый. Дунган халык фольклорының үзенә генә хас ландшафты бар. Монда үзәктә таулар тора. Тауларга герой ауга йөри, ул анда дошманнарыннан кача. Тауда куркыныч урыннар бар, анда явыз затлар да яши. Бу очракта герой аларны җиңү өчен бара. Бу фольклорда беркайчан да урман очрамый, елга-күлләр телгә алынмый. Аларны тау алыштыра. Әмма Кытай һәм дунган әкиятләренең төп герое – Дракон яшәгән Көнчыгыш Кытай диңгезе / Дунхэй еш телгә алына.



*Үртәкә. Илсөяр Закирова фотосы.*

Түләк гөлстан, думбра, кыл кубыз дигән уен кораллары һәм үртәкә ясый. Аллаһы Тәгалә Түләккә музыка уен сәнгате бирә. Үртәкә дигән уенчыкны дастан түбәндәгечә сурәтли: «Ул үртәкәнең мөгезен алтындин, аякларын көмешдин, ике күзен данәдин ясады. Ул үртәкәне бу җиһан бизәге берлән бизәде» [Татар халык иҗаты: Дастаннар: 1984. Б. 131].

Әмма төннәр буе уен коралларында уйнау да Түләкнең күңелен күтәрми. «Аһ дәрига! Сәнең зифа сүрәтенә алданып, адәмнәрдин аерылып нәсәбсез булдым, үләр булдым. Атам-анам кайда? Ыругым бәнем – адәм», – дип үкенә башлый. Чачдар хан Түләкнең уен кораллары ясавын ишетеп, үзенә чакыра. Түләк үртәкә дигән нәрсә ясап, уен коралларын алып, Чачдар хан янына бара. Анда күпмедер яшәгәч, хан китәргә рөхсәт бирә. «Китәрмен тигәнне нәчәгә тикле тотармын», – тиде. Пәриләргә әмер кылды: «Барыңыз, Түләкне сарайына илтеп килеңез», [Түләк]: Кабул кылса, атамыз йортына барсак булгайму?» – тиде. Анда Чачдар хан падишаһ әйде: Ир – туган йирендә, эт – туйган йирендә газиз торыр. Атасы йортын сагынмаган ирне ирме дип булыр?» – дәйү дәстүр бирде».

Түләк шушы рөхсәттән соң гына җир өстенә чыга булса кирәк. Әгәр җир өстенә рөхсәтсез чыга алса, атасы йортына барырга гына рөхсәт сорамас иде.

Л. Суходольский вариантында Түләкнең саргайганын, күңелсезләнгәнен күреп Чачдар хан аны үзе җир өстенә җибәрә. Ул кызы белән киявенә ярты байлыгын бирә һәм юлда борылып карамаска куша. Җир өстенә чыккан Түләк түзә алмый, артына борылып карый. Алар артыннан чыккан чиксез күп малларның яртысы кире борылып диңгезгә кереп китә. Бу эпизод «Йиртөшлек» дастанында да бар. Якут олонхоларында, башкорт эпосында да очрый.

Диңгез патшасының музыка яратуы һәм геройның музыка коралларында уйнавы, су кызына өйләнүе Кытай территориясендә яшәгән халыклар фольклорында да еш очрый торган сюжет. Бу сюжетка корылган әсәрләр Кытайда яшәүче дунган халкы фольклорында аеруча күп. Алар, нигездә бер үк сюжетка корылган булса да, һәрберсенең аерым, кабатланмас мотивлары бар. Мәсәлән, «Лосань» дигән әкияттә карт белән карчыкның өч улы була. Үсеп җиткәч алар өчесе өч якка һөнәр өйрәнергә чыгып китәләр. Ике елдан соң һөнәр урынына щяньцзы дигән музыка коралында уйнарга өйрәнеп кайткан төпчек улын этисе куып чыгара. Диңгез ярында кайгыдан щяньцзыда уйнап утырган Лосаньның уенын диңгез патшасы ишетә һәм үз сараена чакыра. Үзенең кызын аңа кияүгә бирә. Алар озак һәм бәхетле яшиләр [Дунганские: 1977. С. 46–49]. Су ияләренең музыка яратуы «Чжон Юй» әкиятендә дә тасвирлана. Диңгез патшасының төпчек өченче кызы атасы рөхсәтеннән башка җиргә чыга һәм цитра дигән

уен коралы тавышын ишетеп, җир егетенә гашыйк була. Күп каршылыкларны җиңеп, геройлар кавышалар [Дунганские: 1977. С. 49–56].

Түләкнең гөлстан дигән уенмы, уен коралымы уйлап табуын әсәрнең бик борынгы икәненә ишарә итә дип, Ф.В. Әхмәтова аны болай аңлата: ««Түләк» әсәренең үзенә генә хас, кыйммәтле һәм үтә архаик бер ягы бар: анда татар музыкаль инструментларының килеп чыгышы эпик традицияләрдә сурәтләнә. Дөрес, текстның ул өлешләре җуела төшкән һәм каяндыр башка берәр әсәрдән килеп кергәндәй тәэсир дә кала. Ничек кенә булмасын, геройның кыл кубыз, думбра, кондак кебек инструментларда уйнап, кешеләрне һәм хайваннарны үзенә багындыруын безнең кайбер дастаннарда (мәсәлән, «Алыпмәмшән»дә) очратырга мөмкин. Андый мотив Угыз каган, Коркыт-ата кебек бик борынгы образларга карый һәм фольклористикада озанлык мәсьәләсе дип карала. Ә инде нәрсәнедер беренче тапкыр ясау һәм файдалану мәсьәләсен эпос өйрәнү гыйлемендә әһәмиятле бер өлкә – культургеройлык белән бәйлиләр. Ул күренеш бик борынгы эпосларда гына очрый» [Татар халык иҗаты: Дастаннар: 1984. Б. 23].

Безнең эраның беренче мең еллыгының икенче яртысына караган Кытай чыганаклары хәбәр иткәнчә, уйгурларның тормыш-көнкүрешендә кыллы музыка кораллары киң кулланылышта булган һәм алар «сузынкы, озын» көйләрне «бүреләр төсле улап» җырларга яратканнар [Бичурин: 1950. С. 205, 216, 231]. Менә шушы хәл, күрәсең, аларны көйнең озын һәм салмак та, моңлы да яңгырашын тудырырлык яңа чаралар эзләүгә этәргән. Кыллы музыка коралларына борынгы төркиләр аеруча зур хөрмәт белән караганнар. Европага Азия мәдәнияте казанышларын алып килгән төркиләр сызгычлы музыка инструментларының Көнчыгыш Европа халыклары арасында таралуында зур роль уйнаганнар. Әлеге музыка коралларының Көньяк славяннар арасына үтеп керүен галимнәр Балкан ярымутравына төрки кабиләләр килүгә бәйле рәвештә аңлаталар. Болгарлар Урта Азия, Шәрекъ илләренең культура казанышлары белән яхшы таныш булалар. Ибне Фазлан, мәсәлән, болгарларның тамбурга охшаш музыка инструментын телгә ала. Сызгычлы музыка коралы Идел буена нәкъ менә болгар чорында үтеп кергән булырга мөмкин [Монасыйпов: 1977. №2. Б. 152]. Кыллы музыка коралларын беренче булып ясый башлаган уйгурлар, аны башка халыкларга да таратканнар. Уйгурлар агач, күн, металлдан пипа, кунхоу дигән һәм башка кыллы, сызгычлы, бәрмә һәм тынлы музыка кораллары ясаганнар [Краткая история уйгуров: 1991. С. 131, 161].

Борынгы уйгурлар исә хәзерге төньяк Кытай территориясендә яшәгәннәр. Диңгез патшалыгын, су кызы белән җир егетенең өйләнешүен

тасвирлаган әсәрләр Кытай халыкларында әле дә популяр. Бу исә аларның «Түләк» дастаны белән охшашлыгы тамырларының уртак булуын дәлилли.

Су асты патшалыгын күргән җир кешесе турындагы язмага теркәлгән иң борынгы әсәр VIII гасырга карый. Шул гасырда төзелгән «Манъёсю» дигән япон җыентыгында «Урасима Таро» исемле баллада урын алган. Инде VIII гасырда ук бу әсәр архаик булып саналган [Японские сказки: 1958. С. 5]. Урасима Таро исемле балыкчы су буенда балаларның бер ташбаканы җәберләүләрен күрә һәм балыкчы балалардан ташбаканы сатып ала да аны ирекккә җибәрә. Икенче көнне ташбака аны су асты патшалыгына кунакка чакыра. Патша сараенда балыкчыны драконның гүзәл кызы Ото-Химэ каршы ала. Иң зур могҗиза – сарай бакчасы була. Аның беренче ягында чия-алмагачлар чәчәк ата, сандугач сайрый – яз була, икенче ягында җәй хөкем сөрә – җиләк-җимеш пешә, өченче ягында – купшы хризантемалар чәчәк ата, өрәңге яфраклары кыштырдый – алтын көз җиткән, дүртенче ягында – ап-ак карга күмелгән кыш була. Су кызына гашыйк булган Урасимо Таро күпме вакыт үткәнен дә тоймый. Шулай да бер көн әти-әнисе, йорты исенә төшә һәм ул җиргә кайтырга теләк белдерә. Саубуллашканда су кызы Ото-химэ аңа яшма ташыннан ясалган тартма бүләк итә, әмма аны беркайчан да ачмаска куша. Туган ярына чыгып баскан Урасима бернәрсәне дә танымый, өендә дә танышларын-туганнарын тапмый. Кешеләр аңа «Монда 700 ел элек Урасима дигән балыкчы яшәгән», дип риваять сөйлиләр. Урасима диңгез ярында картка әйләнеп үлә [Японские сказки: 1958. С. 9–13].

«Урасима Таро» белән «Түләк» дастаны арасында охшашлыклар, уртак мотивларның күп булуы, аларның уртак чыганагы турындагы фикергә этәрә. Ике әсәрнең дә геройлары су астына, диңгез патшасының сараена эләгәләр. Икесе дә су кызына гашыйк була һәм шушы стихиядә кала. Мәхәббәттән башлары әйләнгән геройлар җир өсте дөньясын, анда калган тормышларын озак вакыт үткәч кенә искә төшерәләр. Икесе дә җирне сагынып, җиргә чыга. «Урасима Таро»да сарай бакчасы дүрт якта дүрт ел фасылын күрсәтә. «Түләк» дастанында исә сарайның бер ягында сөт дәрьясы, икенче ягында бал дәрьясы, дүрт ягында дүрт олуг су дәрьясы агып тора.

«Түләк» – мәхәббәт дастаны булып санала. Әмма анда мәхәббәт гашыйклар арасындагы көчле хис буларак кына сурәтләнми, ул икенче зур тема – ватандарлык, туган илне ярату, аны сагыну һәм матур итеп мактый белүдә дә күренә [Госманов: 1994. Б. 264].

Әсәр төрки халыклар эпосының классик формасында иҗат ителгән. Анда шигъри һәм чәчмә өлешләр чиратлашып бара. Шигъри өлешләрдә

геройларның эчке кичерешләре, күңел дөньясы тирән ачыла, аларның үзгәртүләргә кыенрак бирелүен дә искә алмый ярамый. Чәчмә өлешләр күбрәк үзгәртелгән, төшеп калган, яки яңа эпизодлар килеп кергән. Әсәрдәге ислам идеологиясе соңыннан гына өстәлгән катлам булырга тиеш дип уйлыйбыз. Мифологик үзенчәлекләрен саклаган әсәргә ислам идеологиясе килеп керү, билгеле, дастанның үз эчендәге каршылыклы урыннарга китерә.

«Түләк» дастаны гаять үзенчәлекле мифологик әсәр. Ул бик борынгы заманнарда иҗат ителгән һәм үзенең тамырлары белән Кытай территориясендә яшәгән борынгы төрки халыклар фольклорына ук барып тоташа булса кирәк.

## Әдәбият


1. Әхмәтҗанов М.И. Түләк белән Сусылу // Әдәби мирас. Дүртенче китап. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1997. – Б. 14–33.
2. Бичурин Н.Я. (Йакинф). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена Т. I. М.-Л.: Изд-во Акад. Наук СССР, 1950. – 382 с.
3. Бичурин Н.Я. История первых четырех ханов из дома Чингизова. – СПб., 1829. – 440 с.
4. Былины Севера [Текст] / А.М. Астахова; Записи, вступ. статья «Былинное творчество северных крестьян» и комментарий А.М. Астаховой. Мезень и Печора [Текст] / 2 т.; 22 см. Москва; Ленинград: Акад. наук СССР, 1938–1951, 1938. – 654 с.
5. Госманов М.Г. Каурый каләм эзеннән. Казан: Тат. кит. нәшр., 1994. – 463 б.
6. Даль В.И. Башкирская русалка // Москвитянин. 1843. – № 1. – С. 97–119.
7. Дәфтәре Чыңгыз-намә /Китапны басмага хәзерләүче, сүзлек һәм аңлатмалар авторы Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: «Иман», 2000. – 44 б.
8. Дунганские народные сказки и предания. М.: Главная редакция восточной литературы издательства «Наука», 1977. – 573 с.
9. Игнатьев Р. Сказания, сказки и песни, сохранившиеся в рукописях татарской письменности и в устных пересказах у инородцев-магометан Оренбургского края // Зап. Оренбург. Отд. Имп. Рус. геогр. о-ва. – Вып. 3. – Оренбург, 1875. – С. 207–211.
10. Из «Истории завоевателя мира» Джувейни // Сборник материалов относящихся к истории Золотой Орды. Извлечение из персидских сочинений собранных В.Г. Тизенгаузеном. – М.-Л., 1941. С. 257–262
11. Исхаков Д.М. Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих. («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннарына

һәм тарихи риваятьләргә анализ) // Туган җир. 2022, №2. Махсус сан. – Б. 10–168.

12. Киреев А.Н. Башкирский народный героический эпос. Уфа: Баш. кн. Изд-во, 1970. – 304 с.
13. Краткая история уйгуров. Алма-Ата: Гылым, 1991. – 256 с.
14. Монасыйпов Ш. Татар кыллы музыка сәнгате тарихыннан // Казан утлары. – 1977. – №2. Б. 152–160.
15. Потанин Г.И. Дочь моря в степном эпосе / // Этнографическое обозрение. – Кн. XII. – М., 1892. – №. 1. – С. 38–69.
16. Султанов Х.С. Зоя-Тулек и Су-сулу. Башкирское предание // Самарская Изета. 1902, №83.
17. Суходольский Лев. Легенда о Туляке // Вестник Имп. Рус. геогр. о-ва. СПб., 1858. – №12. – Ч. 24. С. 65–72.
18. Татар халык иҗаты: Дастаннар / Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – 384 б.
19. Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа / Ф.И. Урманчеев. Казань: Тат. кн. изд-во, 1984. – 312 с..
20. Японские народные сказки. М.: Эксмо, 2019. – 576 с.
21. Японские сказки. М.: Гослитиздат, 1958. – 112 с.

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

## «ТҮЛӘК» ДАСТАНЫ: ТАТАР ВЕРСИЯСЕ ҺӘМ ВАРИАНТЛАРЫ

«Түләк» – татар халкының рухи тәҗрибәсен һәм иҗади аңын чагылдыра һәм трансляцияли торган дастан. Төрки эпосы үсешенең өзлексез процессында аның лаеклы үз урыны бар. Түләк һәм Сусылу турындагы архаик-героик дастан төрки халыкларның дөньяга карашларын тирән чагылдыра, шул ук вакытта татар халык иҗатының шигъри әһәмиятен дә саклый. Татар «Түләге» – кульъязмаларда безгә килеп җиткән чын мәгънәсендә милли китаби эпос. Әлеге сюжетка корылган дастаннарның татар вариантларына лаконизм хас, алар каһарманлык, маҗаралылыкны үз эченә ала. «Түләк» тарихи хәтерне, буыннар дәвамчанлыгын бүгенге көнгә кадәр җиткерә алганлыгы белән актуаль. «Түләк» дастанынының татар вариантлары милләтнең эпик мәдәниятен чагылдыра торган чыганак буларак гаять кызыклы.

Әлеге мәкаләбездә «Түләк» дастаны татар версиясенең барлык билгеле вариантлары системага салына. Язмабызның максаты – дастанның татарча версиясенең үзенчәлеген ачу. Безнең тарафтан дастанның бүгенге көндә мәгълүм барлыгы алты татар варианты текстларына тасвирлама характеристика бирелде, вариантлар арасындагы лексик, стилистик, семантик һәм күчереп язу вакыты, урынына бәйле аермалар билгеләнде; «Түләк» дастанының һәр варианты бертигез кыйммәткә һәм зур фәнни әһәмияткә ия булуы ассызыкланды. Моннан тыш, автор үзенең фәнни тикшеренү даирәсенә «Түләк» дастанының китаби версиясендә татарларның мифологик һәм дини карашларының ролен ачыклауны да ала; татар вариантларының башка төрки халыклар, аерым алганда, башкорт версиясе янәшәсендә төп хасиятен билгели; татар текстларында, мөселман ышанулары белән беррәттән, борынгы төркиләрнең дөньяга традицион карашының архаик элементлары да яхшы саклануына да игътибар итә.

Тикшеренүнең фәнни яңалыгы «Түләк» дастанының билгеле татар вариантларын, эпоста этник караш чагылуга аерым басым ясап, комплекслы анализлаудан гыйбарәт. Тикшеренү чыганагы – татарлар тупланып яшәгән урыннарда төрле елларда табылган «Түләк» дастанының татар телендәге текстлары. Тикшеренүдә фәнни эзләнүнең структур-тасвирлау, текстологик, герменивтик методлары кулланылды.

«Түләк» дастаны («Түләк китабы» яки «Түләк белән Сусылу») фәнни дөньяга күптәннән билгеле. Бу сюжет XIX гасырда ук рус галимнәренең игътибарын җәлеп итә. В.И. Даль [Даль: 1843. С. 97–119], Л.С. Суходольский [Суходольский: 1858. С. 65–72], Р.Г. Игнатьев [Игнатьев: 1857.

С. 207–211], Г.Н. Потанин [Потанин: 1892. С. 38–69] һ.б.ның әлеге эпик истәлеккә турыдан-туры катнашы булган хезмәтләре билгеле. XX гасыр башында дастанның бер вариантын рус матбугатында Солтангәрәй Солтанов бастыра, 1910 елда мәшһүр шагыйрь Мәҗит Гафури (Габделмәҗит Гафуров) әсәрне аерым китап итеп әзерли һәм бастырып чыгара [Заятүләк берлә Сусылу...: 1910]. Соңгы елларда М. Гафури вариантының иске татар кульязма китапларыннан төзелгән җыелма текст булуы ачыкланды [Түләк китабы...: 2008. Б. 4–5]. Татар эпосында «Түләк» сюжетына мөрәҗәгать итү XX гасырның икенче яртысында да дәвам итә. Мәсәлән, язучы һәм галим Н.И. Исәнбәт, «Түләк» операсы өчен либретто язып, бу әсәргә яңа яшәеш бирә [Исәнбәт: 1944]. Н.И. Исәнбәтнең «Түләк» пьесасы аның «Сайланма әсәрләр» дигән өч томлык басмасының беренче томында басылып чыга [Түләк. Исәнбәт. Сайланма әсәрләр: 1960. Б. 310–367]. Дастанның Түләк турындагы татарча версиясе алман теленә тәрҗемә ителә, 1971 елда дөнья күрә [Csikai: 1971. S. 55–77]. «Түләк» дастаны безнең көннәрдә шулай ук рус теленә дә тәрҗемә ителде һәм басылып чыкты [Татарское народное творчество: 2019. С. 170 – 185].

Фольклористикада Түләк турындагы дастанның татар вариантларына багышланган хезмәтләрдән Ф.И. Урманчеев [Урманчеев: 1979. С. 10–25; Урманчеев: 1984. С. 72–89], М.И. Әхмәтҗанов [Ахметзянов: 1991. С. 89–97; Әхмәтҗанов: 1997. Б. 14–33], М.Г. Госманов [Госманов: 1994. Б. 225–300], Р. Мәрданов [Түләк китабы...: 2008], Д.Ф. Исхаков [Исхаков: 2022. Б. 36–71], И. Закирова [Закирова: 2003. Б. 75–98], Л. Мөхәммәтҗанова [Мөхәммәтҗанова: 2024. Б. 168–184; Мухаметзянова: 2023. С. 68–76; Мухаметзянова: 2024. С. 5–14] һ.б. мәкаләләре иң төп хезмәтләрдән санала. Фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләрнең булуына карамастан, дастанны тулы күләмдә тиешенчә өйрәнүгә фәнни ихтыяҗ бүгенгәчә кимемәде, киресенчә, дастан белән кызыксынучылар арта, төрле аспектта яңа тикшеренүләр үткәрү зарурлыгы туу күзәтелә. Яңа табылган экспедиция материаллары исә дастанның татарча версиясен фәнни яктан өйрәнүнең потенциалы гаять зур булуны дәлилли.

**Татарларның «Түләк» дастаны нинди һәм ул ни турында?**

Әсәр шактый борынгы сюжетка нигезләнгән. Барлыкка килү чоры күзлегеннән караганда, «Түләк» эпосы XIII–XV гасырларга карый [Түләк китабы...: 2008. Б. 6]. Дастан кыпчак кабиләләре һәм аларның варислары – татарлар, башкортлар арасында формалашкан. Дастанның мифологик үзенчәлекләреннән күренгәнчә, аның архаик тамырлары борынгы төркиләр фольклорына барып тоташа. Түләк исеме белән бәйле әсәрләр бүгенге көнгә татар һәм башкортлар яшәгән төбәкләрдә билгеле. М.Г. Госманов

сүзләренчә, «бер эпосның ике халык иҗади репертуарында да булу факты бик аңлаешлы: татарлар белән башкортлар, борынгы заманнардан ук бергә аралашып, һаман янәшә яшәгәннәр. Гасырлар буена сузылган менә шушы янәшәлек, күршелек, хәтта гел яңарып торган кардәшлек нәтиҗәсендә фольклорда андый уртак сюжетлар барлыкка килүе әллә ни гаҗәп түгел» [Госманов: 1994. Б. 235].

Башкорт халкында дастан яки дастаннан өзекләр телдән башкару характерында булса [Юлдыбаева: 2015. С. 14], татарларда, телдән вариантлар белән беррәттән, дастанның язма-китаби вариантлары зур популярлык казанган, чөнки татарларда дастан – язма мәдәният тәэсирен кичергән эпик жанр. Китап культурасын үстерүгә зур йогынты ясаган булулары, язма әдәби-мәдәни процессны югары баскычка күтәрүдә әһәмиятле функция үтәүләре – башка халыклар белән чагыштырганда татар эпос-дастаннарының төп үзенчәлеге. Халкыбыз күләмле дастаннарны берничә гасыр элек кәгазьгә төшергән, ягъни мәгълүм дастани сюжетлы иң камил, иң төзек вариантлар язмага теркәлеп, кулъязма нөсхәләр яисә китапка әверелеп таралган [Мухаметзянова: 2014. С. 15–125]. Бу закончалык «Түләк» дастанының татар версиясенә дә хас. Татар телендәге язма-китаби «Түләк» дастаны текстлары, гарәп язулы кулъязмалар булып хәзерге көннәргә килеп җиткәннәр. Галим Д. Исхаков сүзләре белән әйтсәк, дастанның «...иң борынгы һәм тулы версиясе язма рәвештә (кулъязмасы XVI йөзгә карый) татарларда гына сакланган» [Исхаков: 2022. Б. 37]. Шул ук вакытта «Түләк» дастаны вариантларына күзәтү ясау татарларның китаби характердагы «Түләк» дастаны да төрки сөйләмә дастаннар традициясен дәвам итеп үсеш алган дигән фикерне куәтли.

Дастанның эчтәлегенә кыскача тукталыйк. Татар телендәге Түләк турындагы версиядә әйтелгәнчә, Түләкнең иптәшләре аны гел рәнҗетәләр, ау кошларыннан аңа фәкать кечкенә генә ябалак, атлардан исә ике яшьлек юбалгы тай эләгә. Ә иптәшләре үзләренә яхшы аргамаклар сайлыйлар. Эпос традицияләре һәм кануннары буенча, тора-бара Түләкнең йолкыш тае җилне узып чабарга сәләтле чын атка, ә ябалак-кошы лачын-кошка әверелә. Түләкнең бу кадәр уңышка ирешүе, төшеп калмыйча, проблемаларын уңышлы хәл итүе, әлбәттә, аның иптәшләрендә көнчелек уята. Алар, сүз куешып, Түләк Аргамагының тоякларына кадаклар кагып куялар. Вакыйгалар Балкантауга якын урында бара. Күп сынаулар кичергән дастанның төп каһарманы Түләк болардан аерылып, читкә китә. Бу – төркиләрнең героик дастаннарында еш кабатлана торган мотив – каһарманның төрле сәбәп белән туган җиреннән читкә чыгып китү мотивының «Түләк» дастанында чагылышы. Кайбер вариантта Түләк йөз иптәшеннән китә диелә, кайберсендә кырык егеттән яки явыз күршеләрдән качуы

бәян ителә. Түләкнең үсмер вакыты батыр балачак буларак тасвирланган булу – шулай ук төрки героик дастаннарның барысына да хас сыйфат. Батыр балачак мотивы булган бу өлеш «Түләк»нең кайбер вариантларында сакланмаган, әсәр шунда ук икенче өлештән башлана, әмма бу вакыйгаларның булганлыгы әсәрнең икенче өлешенең логик эчтәлегеннән һәм эзлеклелегеннән аңлашылып тора.

Алга таба Түләк юлга кузгала. Түләк образы һәм аның гамәлләре аша бу өлештә сюжет тагын да үстерелә. Батыр юлын дәвам итә һәм яңа сынаулар аша уза. Дастанның күпчелек вариантларында Түләкнең Сусылу белән очрашуы турында сөйләнелә. Сусылу – татар халык авыз иҗатында Су анасы образына бәйле мифологик персонаж. Аның дастан сюжетына килеп керүе төрки халыкларда борынгы су культына барып тоташа.

Бик борынгы мифологик карашлар буенча, Җиһанны чолгап алган тирәлек бары тик судан гына торган. Суның хуҗасы – Су иясе бар дип саналган, аның исеме Су анасы яки Су бабасы [Урманче: 2011. Б. 58–74]. Су анасы – җирдән тыш читтәге дөнья – су мохите вәкиле. Су көченә ышанулар татарларда бүгенге көндә дә очрый. Мәсәлән, суга батучы турында «Су анасы алган» дип әйтү сакланып калган. Бу – татарларның су асты патшалыгы турында исламга кадәрге борынгы фикерләүгә бәйле мифологик күзаллауларыннан ук килә. Суда яшәүче Су анасы безнең көннәрдә шартлы рәвештә түбән мифология персонажларыннан берсе санала. Кешенең табигать белән тәңгәллеген һәм охшашлыгын аңларга омтылу «Түләк» дастанында герой язмышын Сусылу мифологик атрибуты белән бәйли. Су стихиясе вәкиле Сусылу белән җир кешесе Түләк арасында сөйләшү башлана:

Андан Түләк әйтде:
– ...Суның кызы Сусылу,
Сәнең берлән булаем,
Атың әйтче, Сусылу!
Андан кыз әйтде:
– Хуш хәмаил, хуш йөзек
Алмадың син, Түләгем!
Алтын сыргам, ал йөзек –
Янә бирдем – бүләгем.
Бүләк биреп алмыйсән,
Нидер сәнең теләгең?
Сүзең әйтче, Түләгем?
Андан Түләк әйтде:
– Хуш хәмаил, хуш йөзек –
Зифа йөзең бизәгел!

Алтын тарак, ал көзгене
Мән ни итим, Сусылу?
Йөзек-бүләк кирәкмәс,
Зифа буең – теләгем!
Сүзем шулдыр, Сусылу! [Татар халык иҗаты: 1984. Б. 126–127].

Кыз Түләкнең үгет-нәсихәтенә һич бирешми, ул Сусылуны үзенеке итә алмый. Герой белән озын чәчле су чибәре арасындагы сүз диалогы акрынлап физик көрәш формасына ала, Сусылу үз мохитенә, су астына китәргә тели. Ә Түләкнең аны җибәрәсе килми. Билгеле бер мизгелдә аны ычкындырачагын күреп, Түләк Сусылуны су өстендәге чәчләреннән эләктереп ала да, кызны судан тартып чыгарырга тырышып, толымнарын кулына чорный башлый.

Мифологик ышанулары буенча, су хуҗасы, ягъни су иясе һәм аның нәселе – Су бабасы (Су атасы), Су анасы, Су кызы һ.б. су астында яшиләр һәм үз патшалыкларында хуҗалык алып баралар [Мифы народов мира: 1992. Б. 162]. Төрки мифологиядә киң таралган су культы архаик-героик дастанның татар версиясе сюжетында сәнгати-фантастик яктан ачыла. Су асты чибәре белән көрәштә бу дөнья кешесе Түләк җиңелүгә дучар була, ул Сусылу белән бергә су асты патшалыгына элгә, су стихиясенең хуҗасы – Сусылуның әтисе каршына баса. Чачдархан Түләккә кызы Сусылуны никахлап бирә. Түләк берникадәр вакыт Сусылу белән бәхетле яши. Су иясе тормышын һәм хуҗалыгын гәүдәләндереп, «Түләк» дастаны татарларның борынгы карашларын бүгенге көнгә кадәр җиткерә. Алга таба сюжет буенча Түләк әкренләп туган җирен сагына башлый, үз иленнән башка яши алмавын аңлый. Чачдарханның аңа туган җиренең Балкантавын диңгез төбенә күчерергә тырышуы да юаныч китерми. Түләк кире үз җиренә кайта.

**«Түләк» дастанының татар вариантлары хакында**

Бүген татар телендәге «Туләк»нең алты варианты билгеле. Текстлар бер-берсеннән нигездә тәрҗемә итү вакыты һәм урыны, тулылыгы яки тулы булмавы, текстта архаик лексика кулланылышы дәрәҗәсе, шигъри өлешләрнең кайбер үзенчәлекләре һ.б. белән аерыла. «Түләк» дастанының һәр татар варианты бер үк дәрәҗәдә кыйммәткә һәм зур фәнни әһәмияткә ия.

«XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия» җыентыгында басылган вариантка [XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия: 2006. Б. 267–284] тукталып үтик. Татар язма дастаннары арасында бу кулъязма үзенең күләме белән аерылып тора. Ул 1991 елда Казан шәһәрендә инженер, язучы Зөфәр Кормашев архивында галим-текстолог М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган, дастан тексты аның тарафыннан ук басып чыгаруга әзерлән-

гән. Табылдыкны 1985 елда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенә мәрхүм Зөфәр Кормашевның хатыны – Мөнирә Җәләлетдин кызы Кормашева тапшырган. Дастанның шартлы атамасы – «Түләк»нең Казан варианты. Кәгазьгә 1887 елда күчерелгән. Күчереп язучы – Мөхәммәтгәрәй бине мелла Шакирҗан, Минзәлә районының Теләнче Тамак авылындагы Габделҗәббар хәзрәт мәдрәсәсе шәкерте. Текст 162 биттән торган кулъязмада теркәлгән [Түләк китабы... Сак. бер 5011]. «Түләк китабы» дастанының Казан вариантына багышланган берничә фәнни мәкалә басылып чыккан [Ахметзянов: 1991. С. 89–97; Әхмәтҗанов: 1997. Б. 14–33].

«Түләк» дастанының татарча версиясенең бу үзенчәлекле вариантында төп геройның мавыктыргыч тарихларына басым ясала. Чыганакта Идел-Кама һәм Урал буе территорияләренә хас географик атамалар, Алтын Урда чорында бу тирәләрдә халыкның табигатькә чыгып күңел ачуына, корбан чалуларына һ.б. га бәйле күчмә тормыш рәвеше телгә алына. Тикшеренүчеләр раславынча, дастанда сүз бара торган Балкан тавы (Балкантау) хәзерге Башкортстан Республикасының Дәүләкән районындагы «Асылы күл» дигән күлгә якын гына урнашкан шул ук исемдәге тау белән тәңгәл [Исхаков: 2022. Б. 45–47].

Дастанда ислам йогынтысы көчле, биредә ул маҗаралы характер алган. Текстта Коръән персонажлары да бар, шулай ук мөселман йолалары һәм гореф-гадәтләре тасвирлана. Текст башында сюжетта Коръән каһарманы – Хозырның булуына игътибар итәбез. Хозыр төшендә Түләккә килә һәм аңа Аллаһның 99 гүзәл исеме санап үтелә торган «Исме Әгъзам» догасын өйрәтә. Үз проблемаларын хәл итү һәм дошманнарының мәкереннән котылу өчен, Түләк Аллаһка корбан итеп тәкә китерергә, картларны корбан ите белән сыйларга, шулай ук дога укырга тиеш була. Түләк барысын да төгәллек белән башкара. Аллаһы Тәгаләгә өмет баглау каһарманга уңыш китерә. Алга таба кискен моментларда Түләк үз эшләрендә һәрвакыт әлеге сыналган ысулны куллана. Мәсәлән, Чачдар ханның игътибарын үзенә җәлеп итәр өчен, иртәнге намаздан соң ул ике рәкәгать өстәмә намаз, «Исме Әгъзам» укый һәм Аллаһтан бу илгә түзә алмаслык эсселек иңдерүен сорый. Кызудан интеккән Чачдар Түләк янына тәүбә итеп килсен һәм бәладән котылу өчен кызы Сусылуны үзенә бирсен өчен шулай эшли. Түләк теләгәненә ирешкәч, Аллаһыдан сорап, барысын яңадан үз урынына кайтарта:

«*Түләк чыкты, кешесез урында таяммум итте, ихластан ике рәкәгать хаҗәт намазын укыды. «Исме Әгъзам» догасын укыды, баш иеп, сыгынып Аллаһыга: – Я Раббым, минем авырлыкларымны син җиңел итә аласың, рәхим-шәфкатеңне күрсәт, хәлдән тайдырган эсселекне бу ха-*

*лыктан ал, рәхим-шәфкатеңне иңдер!» Ихласлыгы белән ялварып сорады, шул вакыт салкынча җил исеп, бал елгасы, сөт елгасы, су елгасы акты*» [Түләк китабы… Сак. бер. 5011. Б. 7].

Бөтен шартын төгәл үтәп, су белән тәхарәтләнү урынына таяммум гына үтәү урта климат шартларында яшәүчеләргә караганда сусыз коры чүлдә яшәүчеләргә күбрәк хас. Әлеге элементның татар вариантында булуы сюжетның бер өлеше яки билгеле бер детальләрнең дастанга Көнчыгыш язма истәлекләреннән күчкән булу мөмкинлегенә ишарә итә. Шәрык дастаннарыннан яхшы билгеле кайбер сюжетлар, мәсәлән, чүлгә чыгу (чүлгә китү), табигатьтә ял итү (сәхрәгә чыгу) кебек, татарларның башка китаби дастаннарында да киң таралган булган, алар, мәсәлән, сюжеты Борынгы Көнчыгыш язма истәлекләреннән алынган «Ләйлә-Мәҗнүн», «Таһир һәм Зөһрә»нең күп вариантларында әллә ничә кат кабатлана [Мухаметзянова: 2014. С. 258, 318, 319]. Әмма шул ук вакытта бу элементның татар вариантында ислам традицияләре һәм Коръән тәэсире астында барлыкка килү мөмкинлеген дә кире какмыйбыз.

Таяммум йоласы дастан текстында Чачдарханның су асты патшалыгында урнашкан түзә алмаслык эсселек белән бәйле рәвештә тасвирлана. Барлык елгалар һәм су чыганаклары кипкәч, биш вакыт намаз алдыннан су белән гадәти тәхарәтләнү мөмкинлеге калмый. Дастанны күчереп язучы, мөселман буларак, таяммумны башкару тәртибен, аны нинди очракларда башкарырга кирәклеген яхшы белә һәм бу элементны дастан сюжетында мөстәкыйль дә куллана алган.

Бу вариантта Түләк мөселман буларак сурәтләнгән, ул намазын калдырмый үти, ә соңрак хатыны Сусылу да аңа иярә, мөселманга тиеш төп шартларны үти башлый. Дастанда Түләкнең Аллаһыга мөрәҗәгать итеп теләгән теләкләре шунда ук тормышка аша бара. Аллаһ Түләкнең гыйбадәт артыннан сораган һәр үтенечен кичекмәстән үти. Сюжетта доганың шул арада кабул булуын күрсәтә торган мондый акцент куелуда, мөгаен, төрки эпик традицияләр белән яхшы таныш булган, табигать көчләренең кичекмәстән кешегә ярдәмгә килүенә һичшиксез ышанган күчереп язучының менталитеты зур роль уйнагандыр. Дастанда эпик геройны олылау, аңа яхшырак шартлар тудырырга омтылыш, каһарманны көчле итеп, мөмкинлекләрен зуррак итеп күрсәтү, аны башкалардан аерып кую, мактау, эпос кагыйдәрәнә гомумән хас булганча, эпик каһарманны калку сурәтләү традициясеннән дә килергә мөмкин. Архаик-героик, тарихи-героик, соңрак дини-героик татар дастаннарының күбесендә әлеге закончалык сакланган. «Түләк» дастаны да бу җәһәттән чыгарылма түгел.

Моннан тыш, тикшеренүчеләр фикеренчә, Түләкнең реаль чынбарлыктагы прототибы затлы нәселгә – Бөек Монгол империясенә нигез

салучы кыйатларга барып тоташа [Исхаков: 2022. Б. 42–43]. Дастанның үзендә дә Түләкнең түрә булганлыгына бик күп ишарәләр бар. Ул һәрвакыт кыю, батыр, карарны тиз кабул итүчән, үз дигәненә ирешүчән, үз сүзен сүз итүчән курку белмәс каһарман. Су төбендә дә тәхетен сагына. Болар барысы да – Түләкнең югары социаль статуска ия булуы хакында сөйли торган билгеләр. Түләк шәхесенә күләмле эпик әсәр иҗат ителгән булу үзе генә дә әлеге фикерне яклый. Урта гасыр әдәби-мәдәни традициясендә хан-солтаннарга багышлап күләмле әсәрләр иҗат итү традициясе булганлыгы билгеле. Болардан чыгып фикер йөрткәндә, Түләк исеме белән аталган әсәрдә Түләкнең өстенлекле вәкаләткә ия булуы эпик кануннар белән генә аңлатылып калмыйча, реаль җирлеккә дә дәгъва кыла.

Дастанда ислам чынбарлыгы традицион дөньяга карашлар белән катнаштырылган, ягъни дастан структурасына кешенең дөнья турындагы кайбер архаик күзаллаулары да бик җиңел кереп урнашкан. Этномәдәни катламнарның мондый урнашуы файдасына дастанда төп геройларның гарәпчә түгел, ә типик төрки исемнәре: Түләк, Сусылу, Чачдархан һ.б. Да сөйли. Дастанның төп геройлары гарәп-мөселман исемнәре түгел, ә төрки исемнәр йөртүләреннән чыгып, әсәрнең сюжет канвасы исламга кадәрге төркиләр арасында ук барлыкка килгән дип уйларга нигез бар.

Дастанның икенче варианты – М. Гафури тарафыннан 1910 елда төзелгән җыелма текст. Китапның татар телендәге кереш сүзендә әдип үзенең 1909 елда Бәләбәй өязенә баруы, анда «Заятүләк»нең көен җырлап уйнаулары, «Заятүләк» дигән китап та бар дип ишетүе турында яза. «Мин элек бу китапның Уфада мәшһүр бер зат тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, үзе вафат булуы сәбәпле бастырылмый калуы турында ишеткән идем. Монда да бунын барлыгын ишеткәч, аны шундук эзләп таптым. Кулыма төшкән мөтәгаддид (күп санлы. – Л.М.) нөсхәләрне бергә китереп караганда, китапның әһәмияте мин уйлаганча булмаса да, түбәндәге сәбәпләр өчен язып алып, тугры килсә табигъ кылдырырмын (нәшер итәрмен – Л.М.) дип уйладым», – ди ул [Заятүләк берлә Сусылу…: 1910. Б. 3]. Әсәрнең шигъри өлеше, стиле дастанның башка татар вариантлары белән охшашлыгы турында сөйли, әмма сюжетта аз гына аермалар бар. Дастанның М. Гафури варианты язучының соңрак дөнья күргән басмаларына, аннары «Башкорт халык иҗаты» җыентыгына башкорт эпосы үрнәге буларак кертелгән [Башкорт халыҡ ижады: 1972].

М. Гафури тексты Олы Кариле авылында табылган кульъязмага якынрак (бу кульъязма турында сүз алдарак барачак). Аларны хәтта бер кульъязманың ике варианты дип тә карарга мөмкин. Бертөрле диярлек чәчмә һәм шигъри өлешләрнең тотрыклылыгы, стиль уртаклыгы да шуны

күрсәтә. Төп аерма – күчереп язу вакыты һәм урынының үзенчәлегендә һәм күчереп язучыларның грамоталылык дәрәҗәсендә.

«Туләк»нең тагын бер вариантының кулъязмасы (бәлки берничә вариантның җыелма кулъязмасы) Н.И. Исәнбәтнең шәхси архивында саклана дигән мәгълүматлар бар. Мәгълүм булганча, дастанның Туләк турындагы кулъязмасына нигезләнеп, 1929 елда Н.И. Исәнбәт пьеса яза башлый. Үз вакытында опера һәм балет театрының әдәбият бүлеге җитәкчесе Муса Җәлил Н.И. Исәнбәткә операга либретто язарга тәкъдим итә. Нәтиҗәдә «Туләк»драматик поэмасы иҗат ителә. Н. Исәнбәт вариантында «Туләк» беренче тапкыр 1944 елда басылып чыга [Исәнбәт: 1944].

Кызганычка, бу текстның нинди чыганаклар нигезендә барлыкка килүе турында әлегә бик аз билгеле. Кулъязманың язылу вакыты да анык түгел, ул – Түләк турындагы дастанның тулы булмаган варианты буларак характерлана: документның соңгы битләре югалган. Композитор Х. Ибраһимов Н.И. Исәнбәтнең «Түләк» әсәренә җырлар, арияләр яза. Композитор Н. Җиһанов шул исемдәге опера иҗат итә. Опера Бөек Ватан сугышы елларында, шулай ук 1970 елларда куела.

«Түләк» дастанының тагын бер варианты 1969 елда Кама Тамагы районының Олы Кариле авылында Казан (Идел буе) федераль университеты тарафыннан тарихчы галим Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә оештырылган археографик экспедиция вакытында табыла. Бу кулъязманың оригиналы КФУ Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана [Түләк... Шифр 4474-т]. Документ 32 битлек, язулы 64 биттән тора, шактый иске, тузган, тулы булмаган нөсхә. Документта дастанның ахыры теркәлгән соңгы битләр барыннан да бигрәк зыян күргән. Кулъязманың XIX гасырның икенче яртысында күчереп язылган булуы билгеле. Күчереп язучы – Олы Кариле авылыннан Хәсән исемле укымышлы. Кулъязма табылган, өйрәнелгән, хәзерге язуга күчерелгән, академик М. Госманов тарафыннан өлешчә реконструкцияләнгән. «Түләк»нең бу варианты турында тарихчы үзенең мәкаләсендә җентекләп бәян итә [Госманов: 1994. Б. 117–132], мәкаләгә кушымтада ул дастан текстын транскрипцияләп бастыра. «Түләк китабы» дастанының бу варианты шартлы рәвештә «Кариле варианты» дип атала.

Бишенче вариант – Татарстан Республикасының Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында табылган кулъязма. Аны фәндә Мәңгәр варианты (Олы Мәңгәр кулязмасы) дип атау кабул ителгән. Дастан 1994 елда Татарстанның Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табыла. Кулъязманы галимгә авылда яшәүче Закировлар гаиләсе тапшырган. Ул дүрт биттән тора. Текст тулы түгел, кайбер битләр югалган, текст фрагментар характерда. Дастанның бу вариантының стиле һәм

теле, кулланылган кәгазе һәм карасы XVIII гасырның икенче яртысына карый. Күчерүчесе турында мәгълүмат юк. Кулъязма ТФА Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИның Язма мирас үзәге фондында саклана [Түләк... Сак. бер. 1].

Алтынчы вариантны 1996 елда Самара өлкәсенең Камышлы авылында тарихчы-галим, археограф, текстолог Р. Мәрданов тапкан. Дастанның бу варианты турында тәүге мәгълүмат Р. Мәрданов төзегән китапта авторның җентекле махсус фәнни мәкаләсендә китерелә. Шунда ук дастан тексты да урын алган [Түләк китабы…: 2008]. Дастан тексты XIX гасырның беренче яртысында күчереп язылган җыентыкта теркәлгән, 10 биттән тора. Текстны Спас өязенең (хәзерге Татарстан Республикасының Әлки районы) Зур Тигәнәле авылы мулласы, Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Чистай районы) Мөслим авылында туып үскән Сибгатулла бине Фәхретдин Мөдәррис (1820–1875) тәрҗемә иткән.. Бу вариант шактый тулы, «Түләк»нең башка билгеле кулъязмалары белән уртак яклары күп. Дастанның сюжеты күп очракта алдагы вариантлар белән тәңгәл. Текстның төп аермасы итеп гарәп сүзләренең төрлечә язылуын, күчереп язучының язу рәвешен, кайбер стилистик һәм орфографик үзенчәлекләрен һ.б. күрсәтергә кирәк. Түләк белән Сусылу диалогларындагы лексика соңгы вариантта эмоциональрәк булуы белән аерылып тора. Р. Мәрданов үзе бу хакта җентекләп сөйли. Китап ахырында кулъязманың факсимилесы, текстның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе һәм элегрәк табылган вариантларның күчереп язу вакыты һәм урыны күрсәтелгән чагыштыру таблицасы китерелгән. Текстның төп нөсхәсе Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана [Түләк китабы… шифр 1761 т].

«Түләк» дастанында халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирас бүгенге көндә дә иҗтимагый тормышыбызда билгеле бер роль башкара килә. «Түләк» дастаныннан килә торган традицияләрнең онытылмавы шул хакта сөйли. Бүгенге көндә бу дастанның төп каһарманының исеме, дастан вакыйгалары опера-балет, театр сәхнәләрендә һәм әдәбият мәйданында яшәвен дәвам итә. Татар фольклорындагы «эпик җыр» дип аталган, «Түләк» сюжетыннан этәрелеп, дастан авазын безнең көннәргә китереп җиткергән дастани җырларыбызның бүгенге көннәргә килеп җитә алуы, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә әле дә язып алына торуы да хаклы рәвештә «Түләк»нең дәвамы, татар җәмәгатьчелегендә бу жанрга карата булган ихтыяҗның чагылышы дип бәяләнә ала.

Бүген ТР ФАнең Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ тарафыннан татарлар тупланып яшәгән төрле төбәкләргә оештырылган фәнни экспедици-

яләр вакытында халыктан сораштырулардан күренгәнчә, «Түләк китабы» исемле әсәр халыкның тарихи хәтерендә саклана. Тарихи хәтер, милли эпик код бу очракта информантның «*Әйе, “Түләк” дип ишеткән бар. Су төбендә яшәгән Түләк. Аны элек китаптан укыганнар, иске китаптан*» (информант – Татарстанның Азнакай районы Җиңү авылында Гәрәева Сәгадәт Бари кызы (1927 елгы)) дигән кыска гына мәгълүматына яшеренгән. Бүгенге көндә «Түләк» дастанының яңа кулъязмасына юлыгу бик сирәк күренеш, әмма дастан кайтавазы буларак фабула характерындагы сөйләкләр, яисә дастан җыры дигән жанр атамасы белән мөстәкыйльләшеп бара торган шигъри юлларга әле бүгенге фәнни экспедицияләр вакытында да юлыгып торабыз. Бүгенге чор өчен мондый ядкяргә юлыгу – зур табыш. Мәсәлән, «Түләк» дастаны турында азмы-күпме мәгълүматлы югарыда телгә алынган информант Гәрәева Сәгадәт Бари кызы дастаннан түбәндәге дүрт юл тезмәне әйтеп бирде (2019 ел, язып алучы – Л.Х. Мөхәммәтҗанова):

Балкан тавы монда юк,
Ак киегем монда юк.
Утырып уйлар уйларга
Алтын тәхетем монда юк [Түләк. Дастан җыры... Экспедиция материаллары: 2019].

«Түләк» дастаныннан эпик җыр буларак мәгълүм бу юллар дастанның тулы вариантларындагы Түләк җыры белән сүзгә сүз диярлек аваздаш:

Балкан тавы монда юк,
Ак киекем монда юк.
Ултырып уен уйнарга
Алтын тәхетем монда юк!
Җөмлә буем җофары,
Зифа ярым монда юк [Татар халык иҗаты. Дастаннар: 1984. Б. 134].

«Түләк» дастанының XXI кайтавазы дип бәяләнә торган әлеге дүртьюллык тезмә – фольклорда кире бәйләнешнең ныклыгын исбатлый торган сирәк үрнәк. Ягъни билгеле бер чорда китаби эпоска әверелгән дастан, трансформацияләнеп, бүгенге чорда яңадан телдән сөйләмдә чагылыш таба. Мондый күренешләр масса төсен алган дип әйтә алмасак та, борынгы «Түләк» дастаны халкыбызда эссез юкка чыкмаган, димәк, тарихи хәтер дә исән. Дастаннар һәм дастан традицияләре – буыннан-буынга тапшырылып килә торган олы мирас, бу байлыкны файдалану, дастаннар сюжетында, стилендә, башкарылу үзенчәлекләрендә булган нечкәлекләрне килер буыннарга җиткерү милли үзаңны үстерү, асылыбызны саклауны нәтиҗәлерәк итә.

## Йомгак урынына

Түләк турындагы дастан – татар эпик фольклорының иң архаик үрнәкләреннән берсе. Тулаем алганда татар версиясе төрки эпос өчен классик булган шигырь һәм проза чиратлашу формасында төзелгән. «Түләк» дастанында архаик, урта гасыр, исламга кадәрге һәм мөселман чоры катламнары чагылыш тапкан. «Түләк китабы» – халык иҗаты җимеше. Дастанда тарихи чынбарлык, этносның исән калу һәм кырыс әйләнә-тирәгә җайлашу өчен көрәше, шулай ук ыруглык җәмгыяте җимерелү чорында патриархаль мөнәсәбәтләр һәм идеаллар, шулай ук соңгырак чорның социаль-мәдәни үзгәрешләре, әкияти-мифологик һәм эпосдастан эстетикасы белән тыгыз бәйләнештә чагылыш тапкан. «Түләк» эпосының кульъязма татар вариантлары дастанның татар халкы арасында киң таралуын, халыкның сүз-шигъри иҗатында лаеклы урын алуын күрсәтә. Дастанның Түләк турындагы тикшеренү темасы моның белән генә бетми. Дастанның татар вариантларын төрле аспектларда өйрәнүнең потенциалы бик югары, телдән эпик традицияләр кысаларында барлыкка килгән һәм вакыт узу белән китаби төр дастанына әверелгән әсәрләр, шулай ук эпик җыр формасында бүгенге көндә дә очрап куя торган авыз-тел ядкярләре, бик сирәк фольклор материалы буларак, тема буенча алга таба тикшеренүләр алып баруга киң мөмкинлекләр ача.

### Әдәбият

1. Ахметзянов М.И. Казанский список дастана «Туляк и Суслу» // Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. Казань: ИЯЛИ, 1991. С. 89–97.
2. Әхмәтҗанов М. Түләк белән Сусылу. Түләк китабы // Әдәби мирас. Дүртенче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 14–33.
3. Башҡорт халыҡ ижады. Эпос. 1-се китап / Төҙөүсе, баш һүҙ яҙыусы, аңлатмалар биреүсе М.М. Сәғитов. Өфө: Башҡорт китап нәшр., 1972. – 242 б.
4. Госманов М.А. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 463 с.
5. Даль В.И. Башкирская русалка // Москвитянин. 1843. № 1. С. 97–119.
6. Закирова И.Г. Болгар чоры халык иҗаты. Казан: фикер, 2003. – 144 б.
7. Заятуляк берлә Сусылу: башкорт хикәясеннән / төз. М. Гафури. – Уфа: типография «Товарищество Каримов, Хусаинов и К°», 1910. – 24 б.
8. Игнатьев Р.Г. Сказания, сказки и песни, сохранившиеся в рукописях татарской письменности и в устных пересказах у инородцев-магометан Оренбургского края // Записки Оренбургского отдела император-

ского Русского географического общества. Вып. 3. Оренбург, 1875. С. 207–211.
9. Исәнбәт Н. Түләк батыр: опера өчен либретто // Совет әдәбияты. 1944. № 4. Б. 27–36; № 5. Б. 25–33.
10. Исхаков Д.М. Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннары һәм тарихи риваятьләргә анализ): монография. Казан: ООО «Грумант», 2022. – 160 с.
11. Мифы народов мира. Энциклопедия: в 2 т. Т. 2. К–Я / главный редактор С.А. Токарев. Москва: Советская энциклопедия, 1992. – 719 с.
12. Мөхәммәтҗанова Л.Х. Түләк китабы. Казан утлары. 2024. № 6 (1208). Б. 168–184.
13. Мухаметзянова Л.Х. Архаические пласты и исламские воззрения в татарской версии дастана «Туляк» // Эпосоведение. № 3. 2024. С. 5–14.
14. Мухаметзянова Л.Х. Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ, 2014. – 380 с.
15. Мухаметзянова Л.Х. Эпическая культура татар. Дастаны. Казань : ИЯЛИ, 2023. – 120 с. (Серия «Обычаи и традиции татарского народа»).
16. Потанин Г.Н. Дочь моря в степном эпосе // Этнографическое обозрение. Кн. XII. 1892. № 1. С. 38–69.
17. Суходольский Л.С. Легенда о Туляке // Вестник императорского Русского географического общества. Ч. 24. № 12. Санкт-Петербург, 1858. С. 65–72.
18. Татар халык иҗаты. Дастаннар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы – Әхмәтова Ф.В. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 384 с.
19. Татарское народное творчество. В 15 т. Т. 8. Дастаны / составитель тома, автор вступительной статьи и комментарий Ф.В. Ахметова. Казань: Татарское кн. изд-во, 2019. – 471 с.
20. Түләк // Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр. 3 томда. Т. 1. – Казан: Татар. книж. изд-во, 1960. Б. 310–367.
21. Түләк // Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский ис. фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге, шифр 4474-т, 32 б.
22. Түләк // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИнең Язма мирас үзәге. Колл. 39, сак. бер. 1, Оп. 1, 4 б.
23. Түләк китабы // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИнең Язма мирас үзәге. Колл. 39, сак. бер. 5011, Оп. 1, 162 б.
24. Түләк китабы // Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский ис. фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге, шифр 1761т., 10 б.

25. Түләк китабы: дастан / төз.-авт. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. – 75 с.
26. Түләк. Дастан җыры. Информант – Гәрәева Сәгадәт Бари кызы (1927 елгы). 2019 елда Татарстанның Азнакай районына ТФА Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИ оештырган комплекслы фәнни экспедициядә Җиңү авылында язып алынды // Экспедиция материаллары. Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивы.
27. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. 3 (С–Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 199 б.
28. Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. Казань: Татарское книжное изд-во, 1984. – 312 с.
29. Урманчеев Ф.И. Татарско-башкирские сказания о Туляке // Советская тюркология. 1979. № 6. С. 10–25.
30. Юлдыбаева Г.В. Башкирский народный эпос «Заятуляк и Хыухылу» (история собирания, издания и исследования) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 8 (50): в 3-х ч. Ч. III. С. 214–217.
31. Csikai V. Eine unveröffentliche baschische Volksmärchen-variante // Acta orientalia. 1971. T. XXVIII. C. 55–77.
32. XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия / төз. М. Әхмәтҗанов. Казань: Дом печати, 2006. – 363 с.

*М.Р. Булатова*

# ЧЕПЦА БУЕ ТАТАРЛАРЫ
## (*Удмуртия һәм Киров төбәкләрендә таралган нократ сөйләше үзенчәлекләре*)

***Аннотация.*** *Статья посвящена этнолингвистической характеристике нукратского говора среднего диалекта татарского языка. Также рассматриваются история формирования татар Кировской области, Республики Удмуртия, история изучения их лингвистических особенностей. Публикация основывается на конкретных материалах, собранных автором во время комплексных экспедиций, предпринятых в 2012 и 2018 гг. ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ по татарским населенным пунктам Удмуртской Республики и Кировской области РФ.*

***Ключевые слова:*** *татары Кировской области и Республики Удмуртия, средний диалект татарского языка, нукратский говор, комплексная экспедиция.*

Халкыбызның рухи һәм милли-мәдәни мирасын туплау максаты белән Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты милләттәшләребез көн күргән төрле төбәкләргә комплекслы рәвештә экспедицияләр оештыра. Чепца елгасы буенда урнашкан татар авылларына да экспедиция уздырылды – ягъни 2012 елда Удмуртия Республикасының Глазов, Балезино, Юкамен районнарына, 2018 елда Киров өлкәсенең Слободской районына (шулай ук Малмыж һәм Нократ Аланы районнарында да булдык). Бу төбәкләрдә татар теле урта диалектының ике сөйләше таралган: Удмуртия Республикасында һәм Киров өлкәсенең Слободской районында – *нократ*, ә Малмыж һәм Нократ Аланы районнарында – *балтач* сөйләшләре.

Нократ сөйләше барлыгы 40 якын авылда, Нократ (Вятка) елгасының бер тармагы булган Чепца елгасы бассейнында таралганга күрә, сөйләш вәкилләрен *Чепца буе татарлары* дип атау очраклары да бар. Административ бүленеш буенча бу территория Киров өлкәсенең Слободской районына һәм Удмуртия республикасының Юкамен, Глазов, Балезино районнарына керә, элек исә Вятка губернасының Слободской һәм Глазов өязләренә караган.

Киров өлкәсенең Слободской районындагы Нократ (русча: Карино) авылы элек бик зур булган, үзе берничә авылны – Олы Ил яки Югары авыл (Югары Карино), Түбән авыл (Түбән Нократ), Ильяс авылларын берләштереп торган. Югары авыл үзе дә Митюк һәм Дәүләтьяр авылларына, Түбән авыл исә Арслан, Абаш, Касыйм, Юач авылларына бүленгән булган.

Сөйләш вәкилләренең бер өлеше – Чепца елгасының югары агымында, Удмуртиядәге авылларда яшиләр. Бу сөйләшкә караган авыллар арасында иң зурысы – Балезино районының Кистем авылы. Тарихи материаллардан күренгәнчә, Кистем авылының халкы, җир аз булу сәбәпле, Киров өлкәсендәге Нократ авылыннан аерылып чыгып, әлеге урынга килеп утырган. Бу авылның сөйләше дә шул ук Нократ авылы сөйләшеннән аерылмый диярлек. Шуңа күрә, фәндә сөйләш *нократ-кистем* сөйләше дигән исем белән дә билгеле [Баязитова: 2006. Б. 4].

Чепца буе татарлары казан татарларының мөстәкыйль этнографик төркемен тәшкил итәләр һәм глазов-кистем (югары Чепца), юкамен-палагай (урта Чепца), нократ (түбән Чепца) төркемнәренә бүленеп йөртеләләр [Сыркина, Касыймова: 1989. Б. 5; Исхаков: 1993. Б. 36–37]. Татар этнографлары, тарихчылары исә бу татарларны бары тик ике төркемгә: нократ һәм югары чепца (глазов) төркемчәләренә бүлеп карыйлар; беренче төркем барлыкка килүдә «арча кенәзләре» токымнары зур роль уйнаганлыгы билгеләнә, ә икенчесендә – бисерманнәр [Исхаков: 2010. Б. 6] («арча кенәзләре» һәм бисерманнәр турында алга таба әйтелер). Д.М. Исхаков фикеренчә, Чепца буе татарларының этнографик төркеме этник субстрат, ягъни болгар чыгышыннан булган бисермән (бераз көньяк удмуртлар кушылмасы белән) һәм суперстрат – кыпчаклардан (Алтын Урда татарлары) оешкан. Нократ төркемчәсендә кыпчакларга хас булган үзенчәлекләр сакланып калган (шуңардан тел һәм мәдәниятендә касыйм татарлары һәм мишәрләр белән уртаклыклар күренә), ә югары Чепца татарларында – субстрат мәдәниятенең бераз үзгәреш кичергән варианты күзәтелә [Исхаков: 1993. Б. 30, 36–37; 2010. Б. 29].

Татар диалектологлары, лингвистик үзенчәлекләренә карап, нократ сөйләшен дүрт урынчылыкка бүлеп карый [Баязитова: 2006. Б. 20]:

а) *нократ урынчылыгы* Киров өлкәсе Слободской районындагы татар авылларын үз эченә ала;

ә) *кистем урынчылыгы* Чепца елгасының югары агымындагы Кистем, Падера, Биктәш, Әхмәди (Балезино районы) һәм Тат. Парҗы, Пучинкә авылларын (Глазов районы) берләштерә;

б) *глазов* (*юкамен*) *урынчылыгы* Глазов (элеккеге Юкамен) районы татар-бисермән авыллары: Дасис (Засеково), Тегермән авыл (Тат. Ключ), Атабай (Богошур), Иманай (Иманаево), Шәфи (Шафеево) авылларында таралган;

в) *бисермән-керәшеннәр урынчылыгы* Бурча районы Яр (Ярово), Глазов районы Тегермән авыл (Тат. Ключ) һ.б. кайбер авылларда яшәүче бисермән-христианнар сөйләшенә карый. Күрүебезчә, соңгы өч сөйләш Удмуртия Республикасында таралган.

Нократ татарларының килеп чыгышы турында бер-берсенә капма-каршы берничә гипотеза яшәп килә. Берәүләр аларны көнчыгыштан Вятка елгасы буйларына беренчеләрдән булып үтеп кергән төрки кабиләләрнең, икенчеләре исә Идел болгарларының варислары дип саный. Бу төркемнәрнең килеп чыгышын болгарлар һәм Алтын Урда татарлары белән бәйләп караучылар да бар.

Тарихка килгәндә, нократ сөйләше вәкилләренең яши торган җирләре борынгы чорда Болгар дәүләте составына кергән. Аларның мөстәкыйль этник төркем буларак формалашуы Урта Идел һәм Урал алды төбәгендә булып узган катлаулы этник процесслар белән бәйләнгән. Идел болгарларының төньяк өлкәләргә бара торган юлларының берсе Чепца елгасының югары агымы аша үтә торган була. Биредә юл икегә аерылган: берсе – Бөек Пермьгә, икенчесе Чепца елгасының түбән агымы буйлап Вятка елгасына һәм шуннан Бөек Новгородка борылган. Чепца елгасының түбән өлеше Рус һәм Болгар дәүләтләренең мәнфәгатьләре очрашкан җирләр булган. Монгол яуларына кадәр үк бу яклар Идел болгарларының кыйммәтле җәнлек тиресе җыя торган ерак факторияләре булып саналганнар.

Болгар дәүләте һәм Алтын Урда җимерелгәннән соң, Чепца елгасы бассейнындагы җирләр Казан ханлыгы составына керә. 1489 елгы тарихи документларда Чепца буенда Казан ханлыгына буйсынучы «арча кенәзләре» турында әйтелә. Арча кенәзләренең Чепца елгасы янында беренче яшәү урыннары булып Нократ (Карино) авылы санала. Авыл исеме Вятка елгасы (Нократ иле) атамасыннан килеп чыккан [Исхаков: 2010. Б. 39–40]. Д.М. Исхаков кыпчак кабиләсеннән Кара би токымы (ханлыктагы карача-бәкләрнең бер тармагы), вәкилләре булган «арча кенәзләре»нең Арча «даруга»сына ия булуларын ассызыклый. Даруганың төньяк чиге тарихи Нократ (Карино) авылыннан узган [Исхаков: 2010. Б. 31].

XIX гасырда арча кенәзләре тарихын махсус өйрәнгән П.М. Сорокин аларның килеп чыгышын Идел Болгарлары белән бәйли. Галим әйтүенчә, «арча» сүзе бу этник төркемнең атамасы белән түгел, ә бәлки Чепца һәм Вятка елгалары арасындагы алар яшәгән борынгы ил исеме белән бәйле. П.М. Сорокин аларны «арча кенәзләре» дип атауны Болгар дәүләтенең төньягында урнашкан Арча шәһәре белән бәйләп аңлата [Сорокин: 1884]. Әбү Хәмит әл-Гарнатый Идел болгарларының Ару дигән өлкәсе булуы турында әйтә. Аның үзәге булып сәүдә факториясеннән үсеп чыккан Казаннан 60 чакрым ераклыкта гына урнашкан Арча (Арск) шәһәре саналган. Казансу буена урнашкан Арча даругы (даруга – салым җыя торган өлкә) әкренләп киңәйгән һәм тора-бара Кама елгасының урта һәм түбән өлешләрен дә үз эченә алган. Соңыннан Арча юлы буйлап бу икономик зонаны даими күзәтү астында тоткан шәһәрләр һәм калалар бар-

лыкка килгән. Шундый калаларның берсе Чепца елгасының уң як ярына урнашкан Гурья-Кала булган. Бу даруга тирәсендә һәм Арча юлы буйлап яшәгән халыкларны арлар дип йөртү кабул ителгән. Элек төрки телле кавемнәр бу атама белән удмуртларны гына атасалар, тора-бара арлар дип атау бу өлкәнең барлык халкына да, шул исәптән нократ татарларына да карый башлаган [Исхаков: 2010. Б. 128; Юсупов: 2023. Б. 332].

Казан ханлыгы җимерелү белән, Чепца буйлары Рус дәүләтенең административ-территориаль бер өлешенә әверелә. Җирле халык белән идарә итү өчен, иң беренчеләрдән булып Нократ (Карино) волосте оештырыла. Казан ханлыгы тар-мар ителгәч, төрле җәзалардан һәм көчләп чукындырудан качкан татарларның бу якларга чираттагы күпләп күчеп утырулары башлана. Аучылык, игенчелек белән дә көн күргән нократ татарлары Казан һәм Вятка арасында почта ташу эше белән шөгыльләнә башлый. Рус администрациясе һәм үз кенәзләренең басымы астында яшәү түзеп булмаслык дәрәҗәгә җитә һәм Чепца буе татарлары ватаннарын ташлап, көнчыгышка, Идел буеның башка өлкәләренә, бигрәк тә Иң елгасы буйларына һәм хәтта Әстерхан губернасына күчеп китәргә мәҗбүр булалар. XIX гасырның азагында Чепца буе татарлары, биләгән җирләренең күләме буенча, Россиядәге башка халыклардан күпкә калышалар. Шулай булуга карамастан, җирләрнең чагыштырмача иркен булуы белән данлыклы Чепца буйларына Казан арты районнарыннан (Балтач татарлары), хәтта ерак Башкортстаннан да күчеп килүче татарларның саны һич кенә дә кимеми [Юсупов: 2023. Б. 334].

Күчеп утыру дигәннән, мәсәлән, экспедиция вакытында халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә Киров төбәгендәге татарларның Татарстанның Балтач, шулай ук Кукмара, Арча районыннан күчеп килеп утырганнары билгеле булды. Бу күчеш төрле вакыт аралыгында булган. Мәсәлән, балтач сөйләше вәкилләре булган Малмыж районының Иске Йөрек, Татар Конбашы авыллары XVI гасыр урталарында ук (1554 елларда) барлыккка килгән. Арча районы Мәтәскә авылы һәм Балтач районы Түнтәр авылының күп кенә гаиләләре, Иван (Грозный) чукындыруыннан качып, бу җирләргә күчеп утырганнар. Малмыж районының Актүбә авылына исә XX гасырның башларында (1935 елларда), коллективизация вакытында Балтач районыннан килеп төпләнгәннәр. 1950–1960 елларда, Исәк авылына Балтач районының Югары Сәрдек һәм Түбән Сәрдек авылларыннан килеп утыралар [Булатова: 2022 (б). Б. 24].

XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә һәм риваятьләрдә Чепца елгасы буйларына килеп чыккан иң беренче кенәз дип Кара хан яки Кара би санала. Кара би, легенда буенча, үзенең гаскәре белән Мәскәү кенәзенә хезмәткә алына һәм 1337–1381 елларда Чепца елгасы башыннан алып

Вятка елгасына койган арадагы җирләр белән идарә иткәне өчен махсус грамота белән бүләкләнә. Аның Касыйм, Арслан, Дәүләт, Дүнәш, Абашид исемле улларыннан ишәйгән нәселе Чепца елгасы буйлап урнашкан авылларга гына түгел, бәлки вакытлар үтү белән хәзерге Татарстанның Әгерҗе, Актаныш, Арча, Башкортстанның Балтач районнарындагы, шулай ук Оренбург губернасының кайбер авылларына нигез салалар [Сыркина, Касыймова: 1989. Б. 20].

Удмуртиянең кайбер авылларында яшәүче татарлар бирeдәге удмуртлар һәм бисермәннәр белән аралашып көн иткән, үзара кыз алыша, кыз бирешә торган булганнар. Фәнни әдәбиятта бисермәннәр удмурт халкының бик үзенчәлекле бер этнографик төркеме итеп карала: килеп чыгышлары буенча алар төрки халык булып, тарихи сәбәпләр аркасында, удмурт теленең көньяк диалектын үзләштергәннәр, үзләре исә төньяк Удмуртиядә, удмурт теленең төньяк диалектында сөйләшүчеләр арасында утырып калганнар, дип күрсәтелә. XVII–XVIII гасырларда бисермәннәрнең бер өлеше христиан диненә кертелә. Шуннан соң бисермән-христианнар удмуртлар белән, ә бисермән-мөселманнар татарлар белән кушылып киткәннәр [Баязитова: 2006. Б. 4].

XVIII гасыр шәҗәрәләренә караганда, Нократ (Карино) авылы халкы үзенең чыгышы белән өч кенәзгә барып тоташа: Дәүләтьяр, Касыйм, Кара би. Әле дә Дәүләтьяр нәселләре Югары Нократта, Кара би нәселләре Түбән Нократта, Касыйм нәселләре Түбән Нократның Юач авылы өлешендә яшиләр [Исхаков: 1993. Б. 15, 60]. Авылның иң борынгы өлеше булып Дәүләтьяр ягы санала.

1972 елгы кыр материаллары нигезендә, Д.М. Исхаков бу төбәк авылларында таралган түбәндәге фамилияләрне барлап чыга: «Югары Нократта Дәүләтьяровлар («арча кенәзләре» нәселе), Митюковлар, Зелениевлар, Урачиннар (элеккеге бисермәннәр), Түбән Нократ авылында – Ситяковлар, Бузиковлар, Арслановлар, Касыймовлар («арча кенәзләре» нәселе), Абашев һәм Кибешевлар (элеккеге бисермәннәрдән), Ильяс авылында – Дуняшевлар, Зянчуриннар, Долгоаршиннар, Байшихиннар («арча кенәзләре» нәселе)» һ.б. [Исхаков: 2010. Б. 43].

Нократ сөйләшенең үзенчәлекләре фәнни яктан яхшы өйрәнелгән. Бу сөйләш турында беренче булып күренекле галим Җ. Вәлиди язып чыга. 1920 еллар азагында ул Нократ иленә диалектологик экспедицияләр уздыра һәм «нократ-глазов сөйләш»нә багышланган әһәмиятле мәгълүматлар теркәп калдыра [Валиди: 1930. Б. 135–144]. Галим әлеге сөйләшнең бик күп кенә билгеләре белән казан татарлары шивәсенә якын булуын күрсәтә. Кырым татарлары, касыйм татарлары сөйләшләрендә һәм көнбатыш (мишәр) диалектына хас булган үзенчәлекләрнең нократ сөйлә-

шендә дә булуын ассызыклый [Валиди: 1930. Б. 137]. 1947 елда басылып чыккан «Татар диалектологиясе» дигән китабында Л. Җәләй аны «нократ сөйләше» дип атый. Бу сөйләш фәнни югарылыкта һәм бөтен тулылыгы белән тел белгече Н.Б. Борһанова тарафыннан өйрәнелә, кандидатлык диссертациясе языла [Бурганова: 1953].

Диалектологлар Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Ф.Ю. Йосыповларның да әлеге сөйләшкә багышланган хезмәтләре бар. Мәсәлән, 1960–1972 елларда татар теленең диалектологик атласы өчен материал туплаганда, 1982–1985 елларда татар фигыльләренең ареал таралышын өйрәнү максатында, Фәрит Йосыповка да нократ татарлары арасында булырга туры килә. Галим нократ урынчылыгының нигезендә Идел болгарлары һәм борынгы кыпчак кабиләләренең теле ятса, кистем урынчылыгының формалашуында әлеге төркемнәрдән башка казан, касыйм татарларының да роле зур булган дип күрсәтә [Юсупов: 2023. Б. 340]. Ф.С. Баязитова Нократ якларына аеруча күп экспедицияләр уздыра (1986, 1988, 2002). 2006 елда галимәнең нократ сөйләшенең грамматик төзелеше, лексик системасы, бу төбәкнең матди-рухи мәдәнияте турында бай материалларны үз эченә алган китабы басылып чыга [Баязитова: 2006].

Удмуртия республикасына оештырылган 2012 елгы комплекслы экспедиция вакытында нократ сөйләшенең кистем, глазов (юкамен) урынчылыклары диалектолог М.Р. Булатова (мәкалә авторы) тарафыннан да өйрәнелә. 2018 елда Киров өлкәсенә уздырылган фәнни экспедициядә автор нократ урынчылыгын, шулай ук балтач сөйләшен дә тикшерә. М.Р. Булатованың ике төбәк вәкилләренә хас тел үзенчәлекләрен яктырткан һәм гореф-гадәт, көнкүрешен материалларын туплаган хезмәтләре коллектив китапларда басылып чыга [Рамазанова, Булатова: 2021. Б. 98–149; Булатова: 2022 (а). Б. 54–80; Булатова, 2022 (б). Б. 81–119].

***Нократ сөйләше. Тел үзенчәлекләре.*** Борынгылыкны аеруча яхшы саклаган кайбер сөйләшләр татар халкының теле, аның тарихи формалашуы турында гаять әһәмиятле булган фактларны үзләрендә саклап киләләр. Нократ сөйләше – менә шундыйларның берсе булып тора.

а) Фонетик үзенчәлекләр. Болгар дәүләте һәм аның дәвамчысы Алтын Урда чорларындагы төрки тел (В. Хаков, Җ. Вәлиди, Л. Җәләй кебек танылган телчеләр фикеренчә ул тел хәзерге татар теленә бик якын булган) авазлар составы ягыннан сузыкларның кулланылышы белән борынгы төрки телдән аз аерылган. Нократ сөйләше вәкилләренең бабалары шушы борынгы чорга хас телне үзләре белән алып китәләр. Башка телләр чолганышында, төп татар халкыннан аерылган хәлдә яшәү нәтиҗәсендә әлеге борынгы телгә хас авазлар системасы аларның телендә хәзергә кадәр сакланып килә. Идел буе төрки теле исә фонетик яктан шактый

зур үзгәрешләр кичерә. Мәсәлән, [а] авазы иренләшү төсмере ала, [*о*]-[*ө*], [*у*]-[*ү*] авазлары үзара алмашыну кичерәләр. Борынгы төрки телдәге [*о*], [*ө*] авазлары урынына [*у*], [*ү*], ә [*у*]-[*ү*] урынына [*о*], [*ө*] әйтелә башлый: борынгы кол сүзе – хәзер *кул* ‘рука’, *көл* – хәзер *күл* ‘озеро’ һ.б. Борынгы төрки телдә хәзерге [э] авазына охшаш аваз хәзерге татар телендә [*ә*] яки [*и*] авазына, ә борынгы [*и*] авазы хәзерге телдә [*е(э)*] авазына күчә: *кэлін* – әд. килен, *бэрі* – бире һ.б.

Шунысы игътибарга лаек, авазларның бу рәвешле күчеше Идел-Урал төбәгендәге төрки телләрдә, ягъни татар һәм башкорт телләренә генә хас. Әлбәттә, озак еллар буе барган мондый күчешләр төрле төбәкләрдә төрле дәрәҗәдә була. Мәсәлән, татар телендәге *йүгерү* – әд. йөгерү, *йүгән*, *йүткерү* кебек очраклар, пермь сөйләшендәге *отораv* – әд. утрау, *төгөрик* – түгәрәк, *бөрлигән* – бөрлегән, *кәрәк* – кирәк һ.б. Көнбатыш (мишәр) диалектындагы *орлау* – әд. урлау, *нә* – ни, Урал төбәгендәге татар сөйләшләрендә *кәбән* – әд. кибән, *кәштә* – киштә кебек күренешләр [*о*], [*ө*] – [*у*], [*ү*] ике яклы күчешенең төрле сөйләшләрдә төрле дәрәҗәдә булуын күрсәтәләр. Сүз уңаеннан күрсәтеп үтик, татар телендә борынгы төрки авазлар системасы шактый тулы хәлдә сакланып калган сөйләшләр дә бар. Мәсәлән, *бараба* диалектында (Новосибирск өлкәсе), *том* диалектының калмак сөйләшендә сузык авазларның башка төрки телләрдәге һәм борынгы төрки телдәге кебек кулланылышы сакланып килә [Рамазанова, Булатова: 2021. Б. 99].

Әйтергә кирәк, нократ сөйләшендә татар теленең башка реликт (нагайбәк, касыйм, пермь, керәшен, подберезье, мордва-каратай) сөйләшләрендәге кебек үзенчәлекләр сакланган.

[*а*] авазы, барлык позицияләрдә дә урта (казан татарлары) диалектның казан арты – дөбьяз, шулай ук нагайбәк, касыйм, пермь, керәшен сөйләшләрендәге кебек, иренләшү төсмере булмаган, ачык аваз булып әйтелә (мәсәлән, *қатын* – әд. хаᵒтын, графич. – хатын). Бу үзенчәлеге белән көнбатыш (мишәр) диалект сөйләшләре белән дә уртаклык күзәтелә.

[*ә*] авазы ике вариантта күзәтелә. Беренче вариант татар әдәби телендәгечә киң әйтелешле. Ул нигездә гарәп-фарсы алынмаларында һәм ялгызлык исемнәрендә күзәтелә: *сәгәт* – әд. сәгать, *сәләм* – сәлам, *қәгәз* – кәгазь, *Сәлимә*, *Мәдинә* һ.б. Шулай ук кайбер башка сүзләрдә: *әнкуᵒй* – әнкәй, *кәзә* – кәҗә һ.б.

Икенче вариант тар әйтелешле [*ә*] авазын тәшкил итә. Ул яңгырашы белән рус телендәге [э] авазына якын тора, биредә без дә аны [э] дип билгелибез, сүздә теләсә кайсы позициядә күзәтелә. Мәсәлән: *чэчкэ* – әд. чәчкә, *күбрэк* – күбрәк, *миндэ* – миндә, *нигэ* – нигә, *белэ* – белә, *килэлэр* – киләләр һ.б. Бу үзенчәлек белән нократ сөйләше казан арты керә-

шеннәре сөйләшенең мишә һәм кама буе урынчылыклары, шулай ук касыйм, пермь, мордва-каратай сөйләшләренә якын тора.

Нократ сөйләшендә [*ә*] авазының тараюы тагын да көчәергә һәм [*ә*]~[*и*] тәңгәллегенә әйләнергә мөмкин: *безги* – әд. безгә, *ийдин-ийги* – өйдән-өйгә, *тәрәзләрги* – тәрәзәләргә һ.б. Бу күренеш чыгыш килешендә актив: *бердин* – бердән, *синдин* – синдән. Урта диалектның пермь (*печин* – әд. печән, *мелиш* – миләш) һәм касыйм (*'иси* – әд. кисә, *бели* – белә) сөйләшләренә дә мондый күренеш хас.

[*ә*] авазының күчешләре нократ сөйләшендә еш кына әдәби әйтелеш белән чиратлаша. Бу аеруча Удмуртиядәге нократ сөйләшенең кистем һәм глазов (юкамен) урынчылыкларында (ягъни Глазов, Балезино районнарының Биктеш, Кестым, Гурья Кала, Падера, Тат Парзи, Әхмәди авылларында) күзәтелә. [Рамазанова, Булатова: 2021. Б. 102]. Ә Нократ (Карино) авылында борынгы сузыклар системасына якын булу шактый ныклы системалылык саклый.

[*ә*] авазының күчешләре [*и*] авазының тәңгәллекләре белән дә туры килә. Билгеле булганча, борынгы төрки телдәге [и] авазына хәзерге татар телендә еш кына [*ә*] авазы, ә борынгы [*э] авазына [*и*] авазы туры килә, шуннан э ~ *и* ~ *ә* ~ *э* күчешләре килеп чыккан (*ит* – әд. эт 'собака', *из* – эз, *ичэге* – эчәге һ.б.).

[*э(е)*] авазының нократ сөйләшендә шулай ук ике варианты бар: тар әйтелешле һәм киң әйтелешле. Тар әйтелешле [*э(е)*], гомумтатар сүзләрендәге кебек, тамыр һәм кушымчаларда, сүз башында һәм сүз ахырында килә ала: *эшче*, *беренче* һ.б. Ул әдәби телдәге [*ө*] авазы урынына да кулланыла, ягъни күпчелек очракта [*э(е)*]~[*ө*]: *кен* – әд. көн, *элеш* – өлеш, *тетен* – төтен һ.б.

Киң әйтелешле [*э(е)*] авазы әдәби телдәге [*и*] авазы урынына килергә мөмкин: *бәлчән* – әд. билчән, *эт* – ит 'мясо', *йәде* – җиде, *эке* – ике, *тәз* – тиз, *кәлгән* – килгән, *әзән* – идән һ. б.

Шулай итеп, нократ сөйләшендә [*и*], [*ә*], [*е*] сузык авазларының төрле вариантлары күзәтелә һәм бу күренеш татар телендә сузыкларның эволюциясе һәм үсү юллары тарихы белән аңлатыла.

Сөйләштә [*о*] авазы урынына [*ы*] авазын куллану системалы характерда (*былын* – әд. болын, *ылы* – олы һ.б.). Шулай ук иренсезләшкән [*ы*] сузыгы урынына көчле иренләшкән [*о*] авазы әйтелү очраклары да бар, күбесенчә [*қ*] һәм [*к*] тартыклары булган сүзләрдә (*қоз* – әд. кыз, *қоп-қозол* – кып-кызыл һ.б.).

Нократ сөйләшендә тел уртасы [*й*] авазы бик актив кулланыла. Ул әдәби телдәге [*җ*] тартыгы урынына да әйтелә: *йиңгәй* – әд. җиңги, *йәйәү* – җәйәү, *мырйа* – морҗа, *йыру* – җыру, *йыйабыз* – җыябыз һ.б. Тарихка

күз салсак, *й*-лаштыру күренеше иске татар теленең китаби тел традициясе итеп каралган, шул ук вакытта көнбатыш (мишәр) диалектның төп үзенчәлекләреннән берсе булып та тора. *Й*-лаштыру көнчыгыш (себер татарлары) диалектлары һәм урта диалектның башка сөйләшләре өчен дә хас. XIX гасырда һәм XX гасыр башында язылган әсәрләрдә сүз башы позициясендә *җ*-лаштыру һәм *й*-лаштыру параллель кулланылган. Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлеген раслый [Булатова: 2022 (а). Б. 64].

Урта диалектның касыйм, бәрәңге сөйләшләрендәге кебек, нократ сөйләшенә дә [*ң*] авазы урынына тел очы [*н*] тартыгы әйтелү шактый актив күзәтелә. Бу күренеш аеруча иялек килеше кушымчасында очрый: *анын* – әд. аның, *йылнын* – елның, *әнинен* – әнинең, *қаласын* – каласың һ.б.

Сүз һәм иҗек ахырында тирән тел арты [*қ*], [*к*] тартыкларына аерым очракларда йомык [’] (һәмзә) аваз тәңгәл килү күренеше күзәтелә: *йы’ла* – әд. йокла, *балы’* – балык, *би’йыра’* – бик йырак, *чи’ләwе’* – чикләвек. Сирәк очракларда йомык аваз [’] (һәмзә) тел алды [*д*], [*т*] тартыкларын да алмаштыра: *ир-а'лар* – әд. ир-атлар, *за’лы* – затлы, *қай'қаныма* – кайтканыма. [*қ*], [*к*], [*г*] тартыклары урынына [’] (һәмзә) тартыгын куллану касыйм сөйләшенә дә хас күренеш. Нократ татарлары арасында сакланып калган риваятьләрдә кайбер ыруларның килеп чыгышы касыйм татарларына бәйләп аңлатыла. Касыйм татарларының нократ татарлары арасына күчеп утырулары, нигездә, Чепца елгасының урта һәм түбән агымында урнашкан авылларга туры килә.

б) Морфологик үзенчәлекләр. Нократ сөйләше төп грамматик категорияләр, аларның ясалышы һәм мәгънәләре буенча татар әдәби теленнән, нигездә, аерылмый. Шуның белән бергә, кайбер үзенчәлекләр дә күзәтелә.

Исем-исем сүзтезмәләре нократ сөйләшендә күп очракта кушымчасыз гына кулланыла: *кез кен* – әд. көз көне, *йер алма баз* – бәрәңге базы, *қорбан бәрйәм* – корбан бәйрәме һ.б. Мәсәлән: *Мин үрәнмә келим гәрәп телгә* – Мин гарәп телен өйрәнергә телим. Бу күренеш татар теле урта диалектының пермь һәм көнчыгыш диалект сөйләшләрендә дә чагыла. Сирәк кенә минзәлә (яңавыл урынч.), златоуст, бәрәңге, бөре, чистай, темников сөйләшләрендә дә очрый.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең кушымчасы киң вариантта, ягъни *-ай* /*-әй* дип әйтелә: *син йасайсын* – әд. йасыйсың, графич. ясыйсың, *кәрәксенмәйләр* – кирәксенмиләр. Чагыштыр, *-ай*/*-әй* вариантларын кулланып сөйләү Башкортстандагы татар сөйләшләре (урта диалектка караган бөре, кормантау, турбаслы, тепекәй, учалы сөйләшләре, һәм, өлешчә, златоуст, минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы) өчен хас Бу күренеш Себер, Әстерхан, Чиләбе, Оренбург һ.б. өлкә татарларында да сакланган.

Әлеге форма татар әдәби телендә XIX гасыр ахырына кадәр кулланылган [Булатова: 2013. Б. 114].

Фигыльнең *-ма*/*-мә* формасы актив кулланыла: *Сабантуйда бүләкләрне китермә* (*китерергә*) *тийешләр*. Бу форма касыйм, пермь, әстерхан, бастан, нурлат сөйләшләренә, минзәлә сөйләшенең әгерҗе урынчылыгына хас. Сирәк кенә көнбатыш диалектта да очрый, әмма күбрәге *-ма кели* формасында. Чуаш, караим, комык телләрендә дә кулланыла.

Сөйләштә иске татар әдәби телендәге *-мага*/*-мәгә* инфинитив формасы да сакланган: *Қара агачның қайрысын қайрып алмаға кирәк, қыз баланы анасындан айырып алмаға килдек* (җыр). *-мага*/*-мәгә* формасы әлеге көндә урта диалектның касыйм, бәрәңге, пермь, бастан, эчкен, әстерхан һәм өлешчә тагын башка сөйләшләрендә сакланган. Бу инфинитив формасы нугай, комак, төрекмән, гагауз телләренә дә хас.

Нократ сөйләшендә, әдәби телдән аермалы буларак, исә, *-ды+исә* теркәгече дә бик еш кулланыла: *Сүземә исә қолақ та салмадылар. Йаңгыр йауды исә* (әд. *яуса*), *әйберләрне өйгә керт*. Чагыштыр: *-ды исә* (борынгы татар телендә *-ды ирсә*) конструкциясе Башкортстан, Пермь, Курган өлкәсендәге татар сөйләшләренә дә хас күренеш. Башкортстанның көньяк өлешендәге турбаслы, кормантау, учалы, минзәлә (бәләбәй урынчылыгы) сөйләшләрендә исә теркәгече зат кушымчаларын да ала, ә фигыльгә кушымчалар ялганмый: *бардисәләр* – әд. барсалар; тепекәй һәм стәрлетамак сөйләшләрендә зат кушымчасы теркәгечкә дә, фигыльгә дә ялганырга мөмкин: *бардың исәң* – әд. барсаң [Булатова: 2013. Б. 174].

Нократ сөйләше лексик-семантик системасының нигезен гомумтатар сүзләре тәшкил итә. Әдәби телдә булмаган сүзләр дә табыла. Аларның күпчелеге төрки-татар; шулай ук, күрше халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә, сөйләштә алынмалар (рус, удмурт) да урын алган (*сирик* – әд. почмак, *олан* – бала, *хуҗҗам* – ирем, *пәтери* – чорма; *бидрә* – чиләк, *гүлпич* – идән асты; *пүкән* – урындык, *қучақ* – тәрәзә, *угриҗ* – кыяр, *папа* – күбәләк, *кара зәлкә* – сыерчык, *зыпка* – бишек һ.б.).

Шулай итеп, диалекталь үзенчәлекләре булуга карамастан, нократ сөйләшенең авазлар системасы, сүз төркемнәре, грамматик категориясе һәм сүзлек байлыгы, нигездә, татар әдәби тел белән бертөрле. Нократ сөйләше татар теле урта диалектының борынгылык шактый яхшы сакланган кызыклы бер сөйләше булып тора. Бу сөйләштә тарихның тирән катламнарын ачарга ярдәм итә торган, иске татар язма әдәби теленә хас булган лингвистик үзенчәлекләр, халык традицияләре ныграк сакланып калган. Йолаларга, ырымнарга һәм мифологиягә караган, туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр, кием-салым атамалары, әлеге сөйләшнең татар телендәге казан арты, пермь, керәшен, касыйм сөйләшләре белән, шулай

ук көнбатыш (мишәр) диалекты сөйләшләре белән дә зур уртаклыгы булуын күрсәтә. Тарихи сәбәпләр аркасында, татар халкының төп өлешеннән территориаль яктан аерымланып, удмуртлар һәм руслар арасында яшәп калганлыктан, нократ сөйләше вәкилләренең гореф-гадәтләрендә әлеге халыклар белән уртаклыклар барлыкка килгән.




*Г.Ибраһимов ис. ТӘһСИ галимнәре Киров өлкәсенең Слободской районына юл тотышы (сулдан уңга: Эльмира Галимова, Алсу Хасавнех, Ильмир Ямалтдинов, Миңнира Булатова, Гөлнара Яхшисарова, Людмила Шкляева). Экспедиция. 2018 ел.*

Түбәндә фәнни экспедиция вакытында диктофонга язып алынган, тел үзенчәлекләрен һәм халык традицияләрен чагылдырган сөйләү үрнәкләре китерелә:

[Ийүндэ сабантуй уздырма (*уздырырга*) уйлайбыз. Конкурс булма (*булырга*) тийеш: күэндэлэр белэн сулар ташып, мешоклар белэн қыйнашып, қапчықларда йү$^{е}$гереп, күчтэнэчлэрне кискэлэп арқандан, бағанаға менү. Элекке калхузда арлар да бар эделәр. Урыслар да, бисерманнар. Анын күрә ’атыш (*катыш*) булғачын, аларнын бэрйэмнәрен (*бәйрәмнәрен*) туже уздырғаннар. Арларнын «Николин ден’» булғалай. Ул кез кен (*көз көне*) була, уборка беткәчен (*беткәч*). Қыш кен аларға «Масленица»ны уздырма булышқалайбыз. Арларнын бэрйэмнэре бар – «Выл′ Жук» (*яңа ботка*). Ул сабантуй формасында: уйыннары да булғалай, торговл′а да, канциртлары да. Безнен дә – татар, ар халықнын – ансамбл′ләребез йэри чығыш йасамаға (*ясарга*). Сабантуйларны уздырғанда без қатнаштырабыз татар

номерлар да, арлар номерларын да уздырабыз. Патамушто бэтенебез бер аwылда торабыз] (Киров өлкәсе Слободской районының Нократ авылында Н. Дәүләтьяровтан (1950 елгы) Миңнира Булатова язып алды. 2018 ел).

[Қыймақ, күзикмәк, кабарчи (*кош теле*) бешерер, зур-зур ипи, күмәч салыр иде әни. Пирәмәч ачы қамырдан була, эстегә йералма бытқа (*бәрәңге боткасы*) йаққалағанда. Тәбәғый (*зур кекс*), чепчигине (*чәкчәк*) бешермә була. Безди дә пилмин тыталар, аш шулпа йасайлар, йарма булса, йармалы аш. Балиш, кул'аш – итле бәрәңге, беккән (*бөккән*), қал'ағалы беккән – эченә шалқан салып бешергән беккән. Безди кушман (*ачы торма*) субырнысы (*төнәтмә*) булған] (Удмуртия Республикасы Юкамен районы Засеково авылында Т. Балтачевадан (1933 елгы) Миңнира Булатова язып алды. 2012 ел).

[Кийәүгә чыққанда, ийгә кергәндә бәләкәй (*мендәр*) салдылар. Бийатам, бийемем бачқычны менгәндә йәшел печин йәйделәр, топсасын басасын икән, бәләкәй салалар. «Әйдәгез, текле айақларығыз белин», дилэр. Бал, май да қаптыралар. Кич кәбен салдылар (*никах укыттылар*). Кизүлейләр (*аш-су әзерлиләр*): шанги (*пәрәмәч*), қабарчи, беккән, тәбәкмәк (*табада пешкән затлы камыр ашы*), эт (*ит*) бешерделәр. Безди башта чәй эчәләр, анан ары аш қуйалар] (Удмуртия Республикасы Глазов районы Кистем авылында З. Касыймовадан (1934 елгы) Миңнира Булатова язып алды. 2012 ел).

## Кулланылган әдәбият


1. Баязитова Ф.С. Нократ сөйләше. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. – Казан, 2006. – 240 б.
2. Булатова М.Р. Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». – Казань, 2013. – 240 с.
3. Булатова М.Р. Татар теле урта диалектының нократ сөйләше // Милли-мәдәни мирасыбыз: Киров өлкәсе татарлары. – Казан, 2022(а). Б. 54–80.
4. Булатова М.Р. Татар теле урта диалектының балтач сөйләше һәм халык традицияләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Киров өлкәсе татарлары. Казан, 2022 (б). Б. 81–119.
5. Бурганова Н.Б. Языковые особенности каринских и глазовских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1953. – 16 с.
6. Валиди Дж. Наречие каринских и глазовских татар // Труды общества изучения Татарстана. – Казань, 1930. С. 135–144.
7. Исхаков Д.М. Этнографические группы татар Волго-Уральского региона (принципы выделения, формирования, расселения и демография). – Казань, 1993.

8. Исхаков Д.М. Арские князья и нукратские татары (Историко-этнографические сведения, генеологии, клановая принадлежность, место в социально-политической структуре Казанского ханства и Русского государства). – Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2010. – 224 с.
9. Исхаков Д.М. История рода Яушевых в Средневековый период и кимакская проблема. – Воронеж–Казань: ООО «Фаворит», 2018. – 116 с.
10. Рамазанова Д.Б., Булатова М.Р. Тел – милләтнең җаны (Татар теле урта диалектының нократ сөйләше) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. – Казан, 2021. – 2 нче басма. Б. 98–149.
11. Сорокин П.М. Арские князья в Карино // Календарь и памятная книга Вятской губернии на 1885 г. – Вятка, 1884.
12. Сыркина И.А., Касыймова Д.Г. Загадки незагадочного народа. Историко-этнографический очерк о чепецких татарах. – Глазов, 1989.
13. Юсупов Ф.Ю. Казан татарлары шивәсе. – Казан: Тат. кит нәшр. 2023. – 993 б.

# МИРАСЫБЫЗНЫҢ ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАГЫЛЫШЛЫСЫ

# НАШЕ ИСТОРИКО-КРАЕВЕДЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ

## ТҮЛӘК – СУСЫЛУ ДАСТАНЫ

(*Кариле авылы варианты. Миркасыйм Госманов эшкәртүендә*)

### ***Хикайәт***

Бачман хан берлән Чачдар хан дигән ханлар бар ирмеш. Әүүәл заманлар Җайык сулаган[1] икән.

Бачман хан дигән бер хан угылы ирде; халкы, нигъмәте, полы[2] күп, йорты киң иде. Алтмыш йегет хезмәтче-нүкәре[3] бар иде – һәрберсен балатик[4] бизәп йөретер иде. Алтмыш беренчесе Миркасык би угылы Түләк атлыг[5] иде.

Түләкне хан үз катына[6] алды. Түләк бер йалгыз угыл иде.

Бачман хан даимән кош чөйәр иде[7], һәр кайу йегетләрнең үз-үзенә кошлары бар иде. Түләкнең кошы Ак Йапалак иде (15б). [Йегетләр] кош атмакдин[8] хәйран һәмкяр[9] ирделәр. Ул йегетләр, кошлары һәрни алса, Бачман ханга килтерерләр ирделәр.

Көнләрдә бер көн Бачман хан ауга чыкды. Һәрни кош очса, качса, Түләкнең Йапалагы алды. Ул йулда ханның [башка йегетләре һич ни] алмас [ирде]. Түләк алды – ханга бирде. Алтмыш йегет Түләкне гөстах күреп[10], пычакка эләккүтик[11] булдылар.

Һәрдаим Түләк Хакъ коллыгындан хали булмас иде[12], күңеле пакь иде.

---

1 Җайык – суламак – Җаек суы буенда тору. Суламак кебек үк «җирләмәк»нең дә элек, хәзергечә «күмү» төшенчәсеннән тыш, бер «җирдә яшәү» дигән мәгънәсе булган (хәзер казакъ телендә очрый).

2 Пол – акча.

3 Нүкәр – хан-солтан, феодаль бәкләр янындагы яран, хезмәтче (дружинник).

4 Балатик – баладай, бала шикелле.

5 Атлыг – атлы, исемле.

6 Катына – янына.

7 Кош чөй мәк – кош белән киек аулау.

8 Кош атмак – кош чөйү, киек өстенә кош очыру.

9 Кулъязмада «һәмлок» кебегрәк бозылып язылган, мәгънәгә туры килми; һәмкяр – хәзерге фарсы телендә: хезмәттәш, бергә эшләүче; әмма иске телдә: көндәш, конкурент (М.А.Гафаров. Персидско-русский словарь Т.II).

10 Гөстах күрү – әрсез, әдәпсез дип уйлау; бу очракта – көнләшү.

11 Пычакка эләккүтик – (көнчелектән) чәнчелеп үләрдәй.

12 Җөмләнең мәгънәсе: һәрвакыт Түләк аллага коллык итүдән бушамас иде.

Түләкнең менгән атын акбуз[чә] Йилйитмәз[1] дирләр иде. Ул кич, хас кылып[2], алтмыш йегет Түләк атының дүрт айакының йөрәк итенә үткен тимер кадак сукдылар, йөрергә дәрманы булмасын дип. Түләк бу эшне һәргиз[3] белмәде, үзе ойкыда[4] (16а) иде. Төш эчендә Хызыр галәйһессәлам кәлде, Түләккә Исме әгъзам[5] догасын үгрәтде[6]: «Әй, угылым, алтмыш йегет сәңа дошманлык [кылы]п, атың тойакына үткен тимер кадак сукдылар. Ошбу Исме әгъзам догасын укып дәм бирәр исәң[7], кадаклары төшеп, атың айаклары саг булгай», – тиде. Йәнә: «Әй, угылым Түләк, һәркачан сәңа мөшкел эш төшсә [бу доганы] укыгыл!» – тиде.

[Түләк] иртә уйганды, Исме әгъзам догасын укып, дәм бирде исә, ат айакларындан кадаклар төшде, айаклары уңалды[8], саг булды, һичкем ирсәгә боларны әйтмәде.

Иртә булды, атландылар. Түләк бер күлгә карарга кәтде. Алтмыш (16б) йегет таң калып: «Түләкне үлтермәзсәк, безгә нә булмагай?!» – диделәр. Анда әйтделәр: «Безләр өч йегет баралым, икемез акбүзчәнең җөгәнен алып, беремез акбүзчәне камчылалым[9]. Ул сәгать акбүзчә Йилйитмәз алып очкай, агачка йә ташка сугып үлтергәй – аның хурлыгындин котылгаймыз!» – тиделәр.

Өч йегет хас килеп, икесе [атның], җөгәнен суйып[10], берсе камчылады. Акбүзчә йола алып качты. Алты көн туктамады, йитенче көн иртә көн чыкарда бер олуг дәрйаның йанына кәлде, туктады. Түләк һич кайа кәтмешен[11] белмәде; [аның] кандә[12] кәткәнен [йәнә] һич кеше белмәде (17а).

Ул сәгать Түләк аты туктаган йирдә бер кыз күрде: гайәт сахибе җәмалдыр[13], кем күрсә гыйшкындин җан бирердәй булыр иде. Ул су пәрисе Чачдар хан дигән падишаһның кызы иде. Түләк аты туктаган йиргә кәлеп, һәр иртә сачын тарар иде. Ул кыз сачын тарап ултырган[14] вакыт Түләк атындин инде[15], кызның йанына кәлде. Кыз тоймады. Сачының озынлыкы алтмыш карыш

1 Йилйитмәз – Җилҗитмәс (атның исеме); акбүзчә – аксыл бүз (ат төсе).
2 Хас кылмак – туры китерү; бу очракта дөресе: кас (касд) кылу – дошманлык итү.
3 Һәргиз – һәр вакыт.
4 Ойкы – йокы; нугайча – уйкы.
5 Исме әгъзам – олуг исем; Алланың исемнәрен санаудан гыйбарәт булган дога (гадәттә, алланың мең дә бер исеме бар дип исәпләнә).
6 Үгрәтмәк – өйрәтү.
7 Дәм бирер исәң – өшкергән чакта өф иттереп, тын белән өрү (дәм – сулыш).
8 Уңалмак – төзәлү, савыгу; мәкаль: Кылыч ярасы уңалыр, тел ярасы уңалмас.
9 Баралым, камчылалым кебек форма Мөхәммәдъярда актив кулланыла.
10 Суймак – салдыру, чишендерү.
11 Сүз буталчыграк язылган, «кәлмешен» булуы ихтималга якын.
12 Кандә – кая.
13 Сәхибе җәмал – матур чырай иясе, ягъни гүзәл кеше.
14 Ултырмак – утыру.
15 Инмәк – төшү (мәсәлән, күктән иңү).

бар иде; сачын ике йаңакына салып, тарап ултырыр вакыты [иде]. Түләк килеп, кызга сәлам бирде. Кыз, сачын йөзендин китәреп, әйләнеп карады, Түләкне күрде, аһ кылып әйде[1]: «Әгәр аркан ултырган вакытым булмаса (17б), йөземне качан сәңа күргүзгәй идем!» – тиде. Түләкнең йөзенә карады: гайәт зифа йегет торыр. Түләккә кыз андагъ гашыйк булды, һич сүз әйтер хале һәм ул йирдән китәр дәрманы булмады. Күңелендин әйтде: «Бу йегетне бер заман алдаламасам[2], шайәт кешегә катылып киткәймән»[3] – тиде. Кызның ул сәгать барча тәне калтырады, торырга һич дәрманы калмады.

Түләк кызга кушаг[4] әйтде:

Инеп килдем атымдай
Имде күрәсең үзеңә,
Сәлам бирдем бән сәңа,
Айтик күрекле йөзеңә.
Гашыйк булдым бән сәңа –
Нәзек зифа буйыңа,
Сүзең әйтче, Сусылу!

Кыз йәнә[5] Түләккә әйтде:

Мән усалының үзенә[6] (18а)
Гашыйк булма, бай угълы;
Алтын сыргам бирәйен – *
Бүләк булсын, бай угълы.*
Безнең йирләр каты йир,
Түзалмассың, бай угълы;
Хәстә булып үләрсең,
Кайтып киткел, бай угълы!

Андан Түләк кызга әйтде:

Сәфәр кылдык йөз кеше,
Җөгән суйды өч кеше.
Атым кәлде йарышып.
Кулым кәлде карышып;
Атың-йулың[7] белмәймән, –
Атың әйтче, Сусылу!

---

[1] Әймәк – әйтү, әйде – әйтде.

[2] Кулъязмада: алдалармасам.

[3] Катылыпкитмәк – кушылып, ияреп китү.

[4] Кушаг – җыр, такмак.

[5] Бу «йәнә» кызның моннан элек тә егеткә берәр сүз әйтүенә ишарә ясый кебек.

[6] Кыз үзенең пәри затыннан булуына ишарә ясый кебек, усал – начар; бу сүзне башкача укып булмый.

* Монда һәм алга таба Мөхәммәтгәрәй күчермәсе буенча бирелгән шигъри юлларга йолдызчык галәмәте куела.

[7] Аты-йулы – исеме һәм нәсел-нәсәбе.

Андан кыз әйтде:

Атың килер йарышып,
Кулың килер карышып,
Атың-йулың белмәсәң,
Атың әйтеп бирәйем,
Атың үзең беләсән,
Әрәмзәлек кыласән:*[1]
Сары Миркас угълы сән –
Түләк атлы йегет сән!
Атың-йулың белмәйче
Кайда азып йөрерсән,
Зифа Түләк, йәш угыл?!

Андан соң (18б) Түләк әйтде:

Бер дигәндә бил алган,
Билән сайын сан алган[2],
Канат какмай каз алган,
Агызы канлы бүре алган,
Айагы силбәк[3] төлке алган
Муйны озын торна алган,
Кош очырмай кош алган
Ак шоңкарымдин бизәйен[4],
Суның кызы, Сусылу,
Сәнең берлә булайын*,
Атың әйтче, Сусылу!*

Андан кыз әйтде:

Атым сорап нидәрсән?
Куш хәмаил, куш йөзек[5] –
Мона сәңа бүләгем!
Безнең йирләр катыдыр,
Торалмассың, Түләгем,
Хәстә булып үләрсең!
Мән дә сәнлек түгелмән
Кайтып киткел, Түләгем!

---

[1] Әрәмзәлек кылу – харәмзәлек кылу, алдашу.

[2] Бил, билән – калкулык яки кечерәк тау; сан алу – дәрәҗә алу яки күп алу. Дастандагы ике юлның мәгънәсе: бер дигәндә тау өстенә (очып) җиткән, (һәр) тау саен күн (киек) алган.

[3] Силбәк (сәлбәк) – селкенеп тора торган, ягъни җитез, хәрәкәтчән (Себердәге төрки шивәләрдә «салбак» шул ук мәгънәдә).

[4] Шоңкарымдин бизәйен – шоңкарымнан ваз кичим. Шоңкар – карчыга һәм лачынның югары күтәрелеп, бик тиз оча торган иң затлы төре.

[5] Юл буталып язылган; «хәмаил» урынына, бер нокта артык куелудан мәгънәсез «җәмаил» килеп чыккан. Хәмаил – хәситә.

Андан Түләк әйтде:

Артык кошны ашырмас[1]
Шоңкарымдин бизәйен;
Айлык йирне бер баскан,
Йыллык йулны бер баскан,
Койрыгы-йалы таралган (19а),
Түрт айагын бер алган[2]
Аргамакымдан бизәйен!
Суның кызы, Сусылу*,
Сәнең [берлә] булайын*.

Андан кыз әйтде:

Акча йөзем күрсәткән*,
Ару* сачым тараткан,
Толымы* буйым сылаткан[3],
Алтын тарак, ал көзге[4] –
Мона сәңа бүләгем!
Шуны ал да йулың ал,
Кайтып киткел, Түләгем;
Мән дә сәнлек түгелмән,
Ошанмагыл[5], Түләгем!

Андан Түләк әйтде:

Ун ай төгәл күтәргән,
Уңгурткадин[6] бөгелгән,
Хәлал кулы талчыккан,
Тун тезегә[7] ултырткан,
Төн йокысын өч бүлгән,
Төнләр торып имезгән,
Айакдин[8] каймак йидергән,
Айры имчәкдән сөт биргән*

---

[1] Кулъязмада: ашырмай. Бу хата: «син» һәм «яй» хәрефләре буталудан туган; «ашырмай» җөмлә мәгънәсенә туры килми.

[2] Мәгънәсе: дүрт аягын бер юлы җирдән алган, ягъни очкан

[3] Кулъязмада ялгыш: «хилаткан». Беренче хәрефкә нокталар куелмаган, шуңа күрә «чылаткан» дип аңларга да мөмкин. Ләкин мин беренче хәрефне каты «са (сад) дип укыйм.

[4] «Ал» эпитетының мәгънәсе төгәл аңлашылмый («ай» дип төзәтергә нигез юк, чөнки бу сүз өч-дүрт мәртәбә шулай ачык рәвешле л белән язылган). «Ал йөзек» гыйбарәсе дә очрый, шуңа күрә, аны «алтын» эпитетының кыскартылган поэтик варианты дип аңларга туры килә.

[5] Ошанмак – ышанмак, ышану.

[6] Уңгуртка – умыртка.

[7] Кулъязмада: төзелгән.

[8] Айак – савыт.

Анамдин һәм бизәйем!
Алтын тезегә[1] ултырган,
Айры сакал үстергән
Атамдин һәм бизәйем!
Суның кызы, Сусылу,
Сәнең берлән булайым,
Атың әйтче, Сусылу!

Андан кыз әйтде:

Куш хәмаил, куш йөзек
Алмадың сән, Түләгем,
Алтын сыргам, ал йөзек (19б)
Йәнә бирдем – бүләгем.
Бүләк биреп алмайсән,
Нидер сәнең теләгең,
Сүзең әйтче, Түләгем?

Андан Түләк әйтде:

Хуш хәмаил, хуш йөзек –
Зифа йөзең[2] бизәгел!
Алтын тарак, ал көзгене
Мән нитәйен[3] [Сусылу?]
Йөзек-бүләк кирәкмәс, –
Зифа буйың теләгем!
Сүзем шулдыр, Сусылу!

Андан кыз әйтде:

Аптырапсың[4] бай угълы,
Тинтерәпсең, бай угълы,
Әнә аргы йагыңа
Килә торыр биш кеше,–
Күрмәймүсән, бай угълы?! – тип, Түләкне каратып үзе суга чумды. Алтмыш карыш сачының алты карышы суга кермәгән иде – Түләк кызның сачындан беләгенә урап алды; [шулай] барып, кыз судан чыкканчы, беләгендин[5] [йибәрмәде] (20а).

Бер заман көн, ай күренмәс йиргә чыкды. Бер булат сарай торыр. Алды-йанындин бердәй [дәрйалар] акып барыр: [йанында] балдин, йәнә адында[6] сөт дәрйасы акып барыр. Түләк күрде. Кызның сачын йибәр-

[1] Тезегә – тезенә; бу сүзнең «тәхеткә» булуы да ихтимал.
[2] Кулъязмада шулай, «буйың» булуы ихтимал.
[3] Мән нитәйен – мин нишләтим.
[4] Кулъязмада ялгыш: аптырапсыман.
[5] Кулъязмада «белгәйәндин» дип ялгыш язылган.
[6] Кулъязмада: алдындин.

мәс булды. Анда Түләккә кыз әйтде: «Имде сән бәңа[сәң], бән сәңамән[1], сачымны йибәргел, мән сарайга инәйен, түшәк салайын, андан соң сәне чыкып алайын». Анда Түләк кызга әйтде:

Алты көн дә йите төн
Атым алып килепдер;
Алдамачы, Сусылу,
Ай йөзеңдин бер үпмәй,
Һич йибәрмәм, Сусылу!

Андан кыз әйтде:

Алты көн дә йите көн
Атың алып килепдер;
Ашыкмачы, бай угълы (20б);
Урын-түшәк салайын*,
Тарыкмачы, бай угълы*,
Җөмлә буйым сәнеңдер,
Сабыр итче, бай угълы! – тип, кыз әйткәч, Түләк кызның сачындин йибәрде.

Кыз сарайга менде[2], ишекенә керүе [илә] сарайның ишекен беркетде[3]. Ул сәгать булат сарайның бийеклеке һавага чыкды. Кыз һәргиз[4] чыкмады. Өч көн-төн Түләк анда калды; һич дәрманы булмады. Дүртенче көн иртә намазын кылгандин соң ике рәкәгъәт намаз[5] кылды, Исме әгъзам догасын укыды, дәм килтерде, башын сәҗдәгә куйды, анда әйтде: «Илаһи, бу кызны, кауме-халкы, малы-тәуарыны[6] – [барчасыны] көн эсселеке берлә дәрмансыз кылгайсән!» – [тип] әйтде.

Ул сәгать догасы мөстәҗаб булып[7], өч көн-төн һава эсселеке кайнар булды, ул сарайның йанындин (21а) аккан бал дәрйасы, сөт дәрйасы, дүрт тарафыдан аккан су дәрйасы тәмам корыдылар, һичбер эчем су калмады, тәкатьсез булдылар – барчасы йанып үлгүтик[8] булдылар.

Ул кызның сарайы тигрәсендә ултурган кырык ивле[9] хезмәтче-нүкәре бар иде, барчасы зифа йөзлек пәриләр иде; барчасы [йо]

[1] Сүзләр беркадәре бозылып язылган, мәгънәсе: инде син минеке мин синекемен.
[2] Менмәк – менү, биредә: керү (җирдән югары күтәрелеп өйгә керү; элек «инде» булуы ихтимал).
[3] Беркетмәк – бикләү.
[4] Һәргиз – монда: һаман.
[5] Рәкәгъәт – намаз укуның композицион өлеше: үрә торган килеш догалар укый башлаудан алып, рөкугъ итү, ягъни иелеп, тезләнеп тору һәм, сәҗдә кылып, яңадан аягүрә басканга кадәр. Берәр зур теләк әйтергә җыенган чакта көн дә үтәлүе фарыз булган бишвакыт намазның берсеннән соң өстәмә рәвештә ике рәкәгать намаз укыганнар.
[6] Мал-тәуар – мал-туар.
[7] Мөстәҗаб булмак – кабул булу (алла тарафыннан).
[8] Үлгүтик – үләрдәй.
[9] Ив – өй.

йолыша[1] кыз сарайына килделәр, чарлашдылар[2]. Кыз һәргиз ишекен, тәрәзәсен ачмады һәм аваз бирмәде. Бу халайыклар анда Түләкне күрделәр, гайәт сахибе җәмал йегет торыр. Вә: «Кыз бу йегетдин качып бикләнмеш, бу эш бу йегетдин торыр! – тиделәр – Имде нә кылмак кирәк, тиз иттифак кылып, йойыла[3] килең, бу кызның атасы Чачдар ханга (21б) барып әйтмәк кәрәк!»

Андин Чачдар ханга барып әйтделәр. Чачдар хан падишаһ катыг ачу [берлә] берәгүне[4] йибәрде, әйтде: «Нә өчен андаг кылып халкын[5] һәлак кыла торыр? Әүүәлендә ул йегетне үзе кабул кылмаса ирде, адәмнең бу йиргә килергә нә хале бар? – тиде. – Үзе алып килеп торыр, имде нә өчен халкыны һәлак кыла торыр? Әлбәт[6], ул адәмнең догасы мөстәҗаб охшайдыр. Барып кызыма әйтеңез: сарайның ишек-тәрәзәсен ачсын, ул йегетне үз катыйга[7] алсын, гозерләр теләсен[8], дога үтенсен!» – тип, бер кемсәне иза[9] йибәрде.

Ул кем ирсә атасының сүзен әйткәч, кыз сарайның ишекен, тәрәзәсен ачды. Ул заман кызның (22а) тәнегә көн төшде[10], күкрәгендин кереп, аркасындин чыкды – кыз йанып үлгүтик булды. Булат сарай ут кебек булды. Шул заман Түләк сарайга керде, кызны күрде, сачындин урап алды, булат сарайның ишекенә сукды – кызның гакылы кәтде. Бер замандин соң кыз исен җыйды, күзен ачып карады, Түләкне күрде, әйтде: «Әй, йегет, мән сәне сәүмәзлекемдин мондаг эш кылган дәгелмән. Мән йир асты падишаһының кызымән. Ошбу эшем атамга фаш булсын дип, мондаг эш кылганмән», – дип йегетнең күңелен бу сүз илә алды. Йәнә әйде: «Әй, йегет, мончага тигрү[11] эшемез хәтәр ирде, имде Хакъ тәгаләгә шөкер, эшемез күни[12] булды! – тип, гаҗәп мәхәббәт илә Түләкнең муйныга (22б) кыз кулын салды. – Атамдин дәстүр[13] булды, хәбәр кәлде: сәне җефетлеккә алмага!» – тиде.

Түләк кызның бу сүзен ишетеп, кызның гыйшкына йәш җанын[14] корбан кылур тик андаг бөйек мәхәббәт илә кыз муйныга кул салды, мәгәр[15]

[1] Йойолыша (йыйылыша) – җыелыша, җыелышып, җыйнаулашып; сүзнең истәлектәге әйтелеше нугай телендәге формага якын: йыйылу.

[2] Чарлашмак – шаулашу, кычкырышу (ризасызлык белән).

[3] Катыйла-йойыла – кушылып, җыелып.

[4] Берәгү – берәү.

[5] Кулъязмада ялгыш: хаклын.

[6] Әлбәт – әлбәттә.

[7] Үз катыйга – үз янына (№ 6 искәрмәне карагыз).

[8] Гозер теләү – үтенеч әйтү; бiредә ялварып гафу теләү.

[9] Измак – юнәлтү, иза йибәрде – юнәлтеп җибәрде.

[10] Көн төшмәк – кояш яктысы төшү.

[11] Мончага тигрү – моңа тикле, моңа чаклы.

[12] Күни – дөрес, яхшы; изге.

[13] Дәстүр – рөхсәт, күрсәтмә.

[14] Вариант: башын-җанын.

[15] Мәгәр – бу очракта: ихтимал (кара: М.А. Гафаров. Күрсәтелгән сүзлек).

дигәйсән: күктән ай-көн инеп бер-беригә кушылган тип! Андаг мәхәббәтләре йакын булды, алладин гайре кемсәнә белмәс.

Андин кыз Түләккә әйтде: «Имде мәнем гайебемне кичергел!»[1] – тип гозерләр теләде. Әйде: «Әй, йегет, ошбу эсселекдән халемез мөшкел булды, имде Хакъ тәгаләдин үтүнеп, сез дога кылсаңыз, амин дисәк, Хакъ тәгалә шайәт гафу кылып, бу михнәтне китәргәй! – тип, кыз Түләкнең айагына төшде, үтенде (23а). Түләк анда кызга әйтде: «Әй, җаным мәхәббәте, бер сәгать сән сабыр кылып ултыргыл, мән хәлвәт йиргә[2] барып, Хакъ тәгаләдин хаҗәт теләйен[3], сән һәм теләкдә булгайсән», – тиде.

Сарайдан чыкып, бер хәлвәт йиргә барды, тәйәммем кылды[4], ике рәкәгъәт хаҗәт намазы кылды, Исме әгъзам догасына мәхкәм килтерде[5], башыны сәҗдәгә куйды, әйде: «Илаһи, барча мөшкел эшем сәңа асан[6] торыр, – тип, Хакъ тәгаләгә мөнаҗәт кылып әйде. – Бу каумемдин, [рәхмәт] кылып, көн эсселекене китәреп, сихәт бирмәк сәңа асан торыр!» – тип йалбарды исә, шул ук заман куңгыр салкын[7] йил исеп, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, су дәрйалары ака башлады. Тәмам халкы иссез булып (23б), өч көндез-кичә йокладылар. Өч көндән соң тордылар, мал-тәуарларын карадылар: өч өлеше һәлак булган көн эсселекендин.

Андин соң Түләк берлә [кызның] көндин-көн мәхәббәтләре артыграк булды. Кыз Түләккә әйтде: «Әй, йегет, сән мәңа дәстүр бирсәң[8], һәр иртә чыкып, сачым тарап[9], йөзем бизәп килер идем», – тиде. Түләк кызга дәстүр бирде, һәр иртә хәлвәт чыкып, сачын тарап, йөзен бизәп килер иде. Бер көн Түләк кызга әйтде: «Нә йиргә чыкып сачың тарарсән?» – тиде. Кыз Түләккә әйтде: «Нә йирдә сән сачымдин тотдың, шул йирдә тарармән», – тиде. Анда Түләк әйтде: «Әй, җан мәхәббәте, андаг (24а) ирсә, бәнем атым берлә кошымны күрмәзмүсән?» Кыз Түләккә әйтде: «Мәңа гашыйк булмадың[мы], әйтмәдең[ме] – атымдин һәм кошымдин бизәйен димәдеңме?!» Анда Түләк кызга: «Ул көн аның кебек иде, бу көн йәнә үзгә булды, күрсәң булса, айгыл!»[10] – тиде.

---

[1] Кулъязмада буталган: кичруирга...

[2] Хәлвәдйир – аулак җир.

[3] Хаҗәт теләмәк – ихтыяҗны теләү.

[4] Тәйәммем – су юк җирдә тузан ярдәмендә «тәһарәт алу», ягъни «пакьләнү».

[5] Мәхкәм килтермәк – нык ышану; мәхкәм (мәхкәм) – нык, таза.

[6] Асан – асат, ансат, җиңел.

[7] Куңгыр салкын – ягымлы салкын.

[8] Дәстүр бирү –рөхсәт бирү.

[9] Кулъязмада ялгыш: таран.

[10] Айгыл – әйт.

Кыз Түләккә әйтде:

Атың аты йилмайа*,
Аңа китәр йул кайа?*
Атың торыр йабыгып,
Кошың торыр бойыгып,
Үзең салып киткән[1] соң
Тәкый нәгә сорарсән?

Анда Түләк кызга әйтде:

Атым торыр ул йанда[2]
Бәнем өчен зарыгып,
Айлык йиргә бер баскан,
Дүрт айагы талыгып*,
Йыллык йирне караган*,
Ике* күзе калыгып;
Атым алып[3] килмәгә
Дәрман әйтче, Сусылу,
Халең йитсә[4], атымны*
Алып килче, Сусылу!

Андан Түләккә кыз әйтде[5]:

Атың, кошың бу йиргә
Кәлеп йитмәс, бай угълы,
Бу хезмәтне итмәгә
Халем йитмәс, бай угълы.
Теләче Хакъдин [теләгең] (24б).
Ашыкмачы, бай угълы,
Ул теләкне Хакъ бирер,
Кайгырмачы, бай угълы! – тип, кыз әйтде. Түләк торды, йәсигъ намазын[6] кылды, мәхкәм[7] килтерде, башын сәҗдәгә куйды, әйде: «Илаһи, барча агырлар сәңа асан торыр: атымны, кошымны ошбу йиргә килтәрсәң, кодрәтең бар! Мән бичарәнең хален кем белгәй, – тиде. – Рахманым сәндин йардәм!»[8] – тип, ул кичә кыз берлә йатдылар. Иртән таң намазы булды ирде. Намазга тордыгы вакытда Йилйитмәз кешнәп ирде, кошы шоңылдап[9] аваз

[1] Салмак – ташлау.
[2] Йан – тараф, як (ул ян, бу ян – ул як, бу як).
[3] Кулъязмада ялгыш: калып.
[4] Кулъязмада: килеп.
[5] Кулъязмада: Андан Түләк кызга әйтде.
[6] Йәсигъ намазы – ястү намазы.
[7] Кулъязмада: мөһим (№ 82 искәрмәгә кара).
[8] Кулъязмада бозылган: сән йин... йа р...б...; Рахман – рәхимле (алланың эпитеты).
[9] Шоңылдамак (шоңкылдамак) – чыңгылдау.

кылды. Ул сәгать Түләк сарайның тәрәзәсендин карады: акбүзчә кәлеп торыр, алтын ийәре өстендә, Йабалак ийәр кашында[1] күренде. Ул (25а) сәгать Хакъ тәгаләгә шөкерләр кылып, башын сәҗдәгә куйып әйде: «Бу мөлкәт, бу гыйнайәт[2] сәндин торыр!»

Атының кашына[3] барды. Аты, кошы Түләкне күрделәр ирсә, аты селкенде, кошы кагынды – борынгы тик булдылар. Ул сәгать Хакъ тәгалә ул булат сарайның кашына ут-үлән[4] йаратты [ат] һәркичә таң[га] тик йийәр[5] иде.

Йәнә Түләк кыз мәхәббәте берлә хәстә булды, сап-сарыг булды – йөзенә чыкды. Үзе белмәз иде. Кыз иртә сачын тарап бизәнмәгә чыкса, ал көзгесен түшәк өстенә куйып чыкар иде, бу йегет үзен үзе күрсен, нитәк[6] булмыш – белсен дип. Кыз сачын (25б) тарамага чыкып китде. Анда Түләк кызның ал көзгесен түшәк өстендә күреп ачып карады, үзенең йөзен күрде: сап-сарыг булмыш, [нуры] койылмыш, гайәт усал[7] булмыш. «Аһ, дәрига[8], хәстә булды, үлем халегә килепмән!» – тиде.

Торды, бер Гөлестан[9] дигән уйын йасады, бер думбыра, йәнә кыл кубызы[10], йәнә үртәкә[11] йасады. Ул үртәкәнең мөйезен[12] алтындин, айакларын көмешдин, ике күзен данәдин[13] төзеде. Ул үртәкәне бу җиһан бизәге берлән бизәде.

Торып тәһарәт төзеде[14], ике рәкәгъәт хаҗәт намазын укыды. Исме әгъзам догасын укып, мәхкәм килтерде, башын сәҗдәгә куйды: «Илаһи, хаҗәтемне сән рәва кылгыл[15], ошбу төн мәңа уйын сәнгатене (26а) сона биргел![16] Йәнә ошбу үртәкәгә җан биргел! Әй, бер ходая, ошбу йиргә сә-

---

1 Ийәр кашы – ияр башы, ияр очы.
2 Гыйнайәт – ярдәм, булышлык.
3 Кашы – яны (ияр кашы түгел!).
4 Ут-үлән, чирәм (№ 131 искәрмәгә кара).
5 Йимәк – ашау, йийәр – ашар.
6 Нитәк – ничек.
7 Усал – бу очракта: көчсез, хәлсез, зәгыйфь.
8 Дәригъ – үкенеч, аяныч; дәрига – ни аяныч! (пошыну ымлыгы).
9 Бер Гөлестан – формаль палеографик күзлектән караганда, «йир Гөлестан» яки «йыр Гөлестан» дип укырга да мөмкин: «р» хәрефе алдында «б» йайга охшаган. Ләкин, алга таба тексттан күренгәнчә, «гөлестан» махсус бер уен коралына бирелгән поэтик исем, һәм бу җөмләдә дә ул тиңдәш кисәк.
10 Кыл кубыз – кыллы кубыз; скрипка кебек смычок белән ышкып уйный торган кыллы инструмент.
11 Үртәкә – үр һәм тәкә сүзләреннән. Әгәр «үр» сүзе «тау» мәгънәсендә кулланылган булса, тау тәкәсе дип аңларга мөмкин.
12 Мөйез – мөгез.
13 Данә – энҗе.
14 Таһәрәт төземәк – тәһарәт төзәтү ягъни яңарту.
15 Рәвакылмак – бу очракта: яраклы, кабул ителерлек дип тану.
16 Сона бирмәк – бу очракта иңдереп (күктән төшереп, бүләк итеп) бирү.

нең хөкемең берлә грифтар булдым[1], шайәт ки, уйын кылсам, күңелем мәлүл булмагай», – тип, Хакъ тәгаләгә йалварды. Шул сәгать хаҗәтен кабул кылды, [йегеткә] уйын сәнгатене биреп, үртәкәгә җан бирде. Хакъ тәгаләгә шөкер кылып, уйын уйнарга кул биреп, Гөлестанын, думбырасын, кыл кубызын, кондакыны[2] бер кылып өчесен бергә уйнар ирде. Үртәкәсенә бойырды, [бийемәгә][3] әйде.

Барча [пәри] халкы җыйылды, сарай эченә сыймаз булдылар. Һәр кем[4] кичә-көндез Түләк катындан китмәс булдылар. Сарайның эчендә торыр йир булмады, тышкары (26б) чыгып, мәҗлес кырда булды[5]. Түләкнең уйыныга гашыйк булып, ашамакдин, эчмәкдин бизделәр. Иртә торсалар, кичә булганын белмәс кеби булдылар. Түләкнең уйыныга гашыйк булды һавадагы кошлар, йапандагы кийекләр – барчасы җыелып, кичә-көндез китмәз булдылар. Боланлар, коланлар, күп нәүгъ хайванлар, хәшарәтләр – барчасы Түләкнең уйыныга гашикъ булып, йимәк-эчмәкдин калдылар[6].

Көнләрдә бер көн Түләк күңелендин зарилык кылды: «Әй, кәриме рәхим[7], монча пәриләр, кошлар, кийекләр, хәйван-хәшарәтләр берлән шад булып тора торсам йил кузса[8], аның тузаны басып, сурәтем азып[9], җенләр, пәриләр сурәтенә әүерелер ирмешмен!» – дип зар-зар йыглады.

Ул кичә кыз катына йатды, тәкый кызга әйде: «Аһ дәрига! Сәнең (27а) зифа сурәтеңә алданып, адәмләрдин айырылып нәсәбсез булдым, үләр булдым. Атам-анам кайда? Ыругым бәнем – адәм!» – тиде. Кыз әйде: «Әй, йегет, гакылың китдеме? Бу гыйнайәт[10], бу дәүләт нәдин торыр, белмәймүсән? Бу дәүләтне тигергән падишаһлар падишаһы тәңре тәгаләне онытдыңмы? – тиде. – Айырылганларны кушмак аңа асан торыр».

Бу сүз берлә йегетнең күңелен ауытды[11]. Йатдылар. Иртә намазга тордылар ирсә, күрделәр: алтын тәхет сарайның алдында корылмыш, сәкез

---

1 Грифтар булмак – дучар булу.

2 Кондак – асылда: мылтык түтәсе; бу очракта сүз, ихтимал, өч коралның да төпләрен бер итеп, ягъни бер җиргә куеп уйнау хакында барадыр. Алга таба күренгәнчә, Түләк өч коралда да берьюлы уйный.

3 Истәлектә «магә-мәгә» фигыль формасының активлыгына (бизәнмәгә, таранмага, бармага һ.б.) таянып өстибез.

4 «Һәр кеше» дип түгел, бәлки «һәр ки» мәгънәсендә булырга охшый.

5 Кулъязмада: булдылар.

6 Җөмлә Мөхәмматгәрәй күчермәсеннән.

7 Кәриме рәхим – олуг рәхим (иясе).

8 Өч сүзнең укылышы шөбһәле (йил кузу – җил кубу).

9 Сурәт азу – кыяфәт бозылу, начар якка үзгәрү.

10 Гыйнайәт – кайгыртучанлык, ярдәм; бу очракта: яхшы тормыш.

11 Ауытмак – йуату.

кырыны, дүрт тарафыны тимер берлә коршаган [бер таг] тәхетдин йукары калкып сайә[1] кылып торыр. Ул тагны алтын берлә коршаган, башыны ак мәрвәр[2] берлә йапкан (27б). Түрт йаны агач үскән һәм чыбыклык урман булган. Барча боланлар, коланлар, айулар, төлкеләр, кош-кортлар, бүреләр анда урнашмышлар. Бу эшләрне күреп, кыз берлә Түләк Хакъ тәгаләгә шөкерләр кылып, Түләк килеп, ул тәхет үзә[3] менеп ултырды. Уйынларыны кулына алып, бизнәп-сарнап[4] уйнай башлады:

Гөлестаным көйләсен,
Думбырам бәнем сөйләсен,
Кыл кубызым сарнасын*,
Үртәкә хуш уйнасын,
Күрмәгә килгән халайык
Үзен үзе белмәсен!
Уйнау биргел, үртәкәм,
Бийи биргел, үртәкәм!
Алтын тәхет урнаткан,
Көмешдин айак йараткан*,
Тәхет-бәхет түрәткән[5]
Хакь тәгалә кодрәте, –
Шөкер кирәк, Сусылу!

Андин (28а) җыйылган халайыклар әйделәр: «Бу кем тауы[6] торыр? Бу ни тау торыр?» – диделәр. Түләк әйде:

Бәнем тауым Балкан тау,
Башы һауага чыкган тау! –
Тимер берлә тайаган*[7],
Алтын берлә коршаган*,
Ак мәрмәрдән йапкан тау*, – тип кубсаган ауазын ишетеп, кийек кош, җылан-хәшарәтләр йыйылып килеп, башларын түбән салып тыңлар иределәр. Түләк анларны күреп дыбсап әйтде[8]:

Утлар уты май татыр[9], –
Болан сәүгән Балкан тау;

---

[1] Сайә – күләгә, ышык.
[2] Мәрвар (мәрварид) – энҗе.
[3] Тәхет үзә – тәхеткә, тәхет өстенә.
[4] Бизнәп-сарнап – төрләндереп, сарын беләп (сарын – җыр юлларын тулгау, ягъни бер-бер артлы тезеп, күтәренке тавыш белән һәм кызу темп белән әйтү).
[5] Түрәтмәк – ярату, барлыкка китерү. Икенче күчермәдә: төзәткән.
[6] Кулъязмада: табы (бер генә очрак).
[7] Тайаган – терәп куйган.
[8] Дыбсап әйтмәк – гадәттә: әкрен тавыш белән әйтү; бу очракта: тавышланып әйтү.
[9] Юлның мәгънәсе: утлый (ашый) торган уты (үләне)ннән май тәме килер (май ике мәртәбә язылган).

Эчәр суы бал татыр, –
Колан сәүгән Балкан тау!
Йатыр йире йакма алтын*[1]
Йылан сәүгән Балкан тау*;
Кырлары күп, йире киң* –
Төлке сәүгән Балкан тау;
Йийәр йимеше төгәнмәс[2], –
Айу сәүгән Балкан тау!
Кайалары кайырчак*[3] –
Карсак сәүгән Балкан тау;
Күл-кыйусы[4] камышлык, –
Кабан сәүгән Балкан тау! (28б)
Йире салкын, йимеше күп* –
Кошлар сәүгән Балкан тау!
Су-дәрйасы суалмас[5] –
Суыр[6] сәүгән Балкан тау;
Башымызның өстендә
Сайә булган[7] Балкан тау! – тип әйтеп уйнар ирде.

Ул хәбәрләр, ул эшләр кыз атасы Чачдар ханга ишетелде. Чачдар хан падишаһ кызындин йыраклыкы йиде көн-төнлек йулда иде. Түләкне һәм уйынларыны күрмәгә андаг гашыйк булды: йимәкдин, эчмәкдин бизде[8] – дийүләрене, пәриләрене алмага йибәрде. Түләкне пәриләр алып[9] китәр булдылар. Кыз Түләккә айды: «Әй, йегет (29а), ошбу үртәкәңне алып бармагыл, ошбу газиз сүрәтне Хакъ тәгалә җанлыг[10] кылып, сәңа биреп торыр, нәгяһ[11] атам алып калмасын. Мондаг нәрсә падишаһга тансык торыр, ул йиргә[12] бер үртәкә сурәтен алып баргыл», – тиде. Түләк аның сүзен хуш күрде, үртәкә сурәтене йасады, ул җанлыг үртәкәсен кыз йанына куйып китде.

Чачдар хан падишаһга йакын йитә [Түләк] дыбсап[13] уйнай башлады. [Хан] Түләк уйнаган авазын ишетеп гашыйк булды. Шәһәр хал-

[1] Йакма – ?
[2] Йийәр йимеше төгәнмәс – ашар җимеше бетмәс (№ 101 искәрмәгә кара).
[3] Кайалар – кыялар; кыйыпчак – вак таш.
[4] Күл-кыйу – күл-кое.
[5] Суалмак – кибү, кору, бетү (сыеклыкка карата).
[6] Суыр – сөркә; байбак (җәнлек).
[7] Сайә булмак – күләгә, ышык була.
[8] Кулъязмада: бизделәр.
[9] Кулъязмада: алуг.
[10] Кулъязмада ялгыш: халлыг (тексттагы шушы абзацның ахырына карагыз).
[11] Нәгяһ – көтмәгәндә, кинәт.
[12] Кулъязмада ялгыш: уйигә.
[13] Дыбсап – тавышлап.

кы барчасы каршы чыкдылар. Чачдар хан үзе уйынга гашыйк булып, сабыр итә алмады: бер таз колы бар иде, аны (29б) үз урнына тәхеткә ултыртып, үзе каршы килеп тыңлар иде. Кыз атасының сыйфатын тәгайен Түләккә әйткән иде, Түләк анда, Чачдар ханны танып, уйнай башлады:

Гөлестаным көйләйдер,
Думбырам бәнем сөйләйдер[1],
Кыл кубызым сайрайдыр,
Үртәкә хуш уйнайдыр!
Тәхетендә ултырып,
Тәхетдин төшеп килгәйдер[2];
Ишекдәге таз чура[3]
Тәхетдә ултырып тыңлайдыр!

Андин соң Чачдар хан әйде: «Валлаһ, бу Түләк бер дәррәк[4] кеше булмага кәрәк, мәне мондаг белде!» – тиде, тәхетенә кайтып ултырды. Түләк килеп йитде падишаһ сарайына. Кырык көн-төн йимәк-эчмәкдин тәмамы[5] берлә калдылар.

Андин (30а) соң Түләк кызны, Балкан тауны, урыныны, йирене гайәт сагынды. Чачдар ханга купсап[6] әйде:

Балкан тауым монда йук,
Ак кийекем монда йук,
Ултырып уйын уйнарга
Алтын тәхетем монда йук!
Җөмлә буйы җофарлы[7]
Зифа йарым монда йук, – тип, Түләк Балкан тауны әйтдә ирсә, Чачдар хан падишаһ дийүләргә, пәриләргә бойорды: «Барынлар, Түләкнең тауыны килтереңләр!» – тиде.

Дийүләр, пәриләр бардылар. Хакъ тәгалә Балкан тауны аңларга күргәзмәйен, йир (берлә) бәрабәр кылды. Дийүләр, пәриләр ул пулат сарай катында андаг тау тапмадылар. [Хакъ тәгалә] ул сарай йанындагы тауларны йир берлә бәрабәр кылды. Олуг тауларның (30б) [берсен] бер пәри өстенә куйдылар, тимер берлә коршатдылар, күтәреп килтерделәр. Анда Түләк, пәриләрнең алып килгәнен күреп, дыбсап әйде:

---

1 Икенче нөсхәдә: сарнайдыр.
2 Икенче нөсхәдә: тыңлайдыр.
3 Чура – хезмәткәр (вассал).
4 Дәррәк (дөресе: дәррак) – сизгер, аңлы, күрәзә.
5 Кулъязмада традицион «тәммәт тәмам» дигән гыйбарәнең фигыль өлеш ялгыз (тәммат) бирелгән.
6 Купсамак – җырлау; купсап әйтү – җыр белән әйтү.
7 Кулъязмада: булум чфары.

Бәнем тауым ул түгел,
Алтын тәхетем ул түгел!
Тауны тауга охшатып,
Тимер белән коршатып,
Алып килә торырлар!* – тип, Түләк әйде исә анда Чачдар хан дыбсап әйде:
Тауны тауга охшатып,
Тимер берлә коршатып,
Торыр монда Туләгәм,
Балкан тауга охшатып.

Чачдар ханга каршы Түләк әйде:
Бары, бары бийек тау,
Барындин бийек Балкан тау;
Сублап[1] каккан казыкдай
Суыры[2] күп Балкан тау;
Майлап (31а)[3] салган кайышдай
Йыланы күп Балкан тау;
Айыры тойак, шеш мөйез[4]
Боланы күп Балкан тау;
Алпан-талпан йөрегән
Айуы күп Балкан тау;
Йилкә йоны санчелгән*,
Башы түбән ийелгән*,
Кабаны күп Балкан тау*
Кыз угъландай сөзелгән[5],
Төлкесе күп Балкан тау;
Күп йәшәгән кари тик[6]
Карсагы күп Балкан тау;
У йан – бу йан[7] йыры* хуш
Кошлары күп Балкан тау;
Йомры тойак кыл койрык
Коланы күп Балкан тау, –
Дәстур[8] бирсә Чачдар хан

---

[1] Сублап – сулап; кульъязмадагы язылыш бик борынгы архаик үзәнчәлек булырга да мөмкин.

[2] №138 искәрмәгә кара. Образ исә җәнлекнең өн янында хәрәкәтсез озак урә торуына ишарә итә.

[3] «Сайла» дигән артык иҗекләр бар.

[4] Мөйез – мөгез (кара: №108 искәрмә).

[5] Сөзелгән – «сызылып тора торган», ягъни нәфис хәрәкәтле».

[6] Кари тик – карт (кеше) шикелле.

[7] Уйан – бу йан – ул як, бу як.

[8] Дәстур – рөхсәт.

Күргем микән[1] Балкан, тау! – тип, Түләк әйде ирсә, Чачдар хан падишаһ әйде:

Китәм дигән Түләкне

Ничәгә тикле тотармын?! – тиде. Пәриләргә әмер кылды: «Барыңыз...» (31б)[2]

........................................................................................................

........................................................................................................

(I) ... үз туган йире...

(II) ... газиз торыр. Атасы йор[тын]

(III) [Сагын]маган ирне ир тип әйтеп булыр –

(IV) [мы тип], дәстүр бирде. Йәнә анда әйде: «Йортыңыз,

(V) [малы]ңызны, сарайыңызны, халкыңызны

(VI) [имд]е нәтәк кылырсыз?» Анда Түләк әйде: «Падишаһ

(VII) [Әгъза]м барчамызның теләген биргүче торыр», –

(VIII) – тиде Чачдар хан падишаһ: «Аллаһе тәгаләгә

(IX) тапшырдым», – тип, пәриләр берлә йибәрде (32а)...

........................................................................................................

........................................................................................................

(I) ... думбырасын...

(II) ... сарнап, үртәкәсен уйынла[рын уйнай]

(III) башла[д]ы ирсә, кузгалып кәтдекенд[ә]...

(IV) үртәкәсе бийегәндә әйтер иде:

Әй үртәкә[м], (V) [үртәкә]м

Мөйезләрең хуш тәкәм,

Буйы[ң]... (VI) ...ш тәкәм,

Уйна, күңелең ачылсын,

Тәкый... (VII) сачылсын!

Уйнай биргел, үртәкә[м],

Бийи биргел, [үр] (VIII) тәкәм, – тип, төрле уйынлар кылып, халайыкның [күң] – (IX) лен ачып, вә йәнә кийек-кошларның күң (IX) лен ачып, шад[д] ил[3] [кылды] (32б).

........................................................................................................

........................................................................................................

Югарыда әйтелгәнчә һәм төгәл күчерелгән тексттан күренгәнчә, Хәсән шәкерт дәфтәрендәге 32 нче кәгазьдән бер фрагмент кына сакланган. Шул ук вакытта 15б биттән башланган әсәр тексты бу 32 нче кәгазь белән дә тәмамланмый.

---

[1] Күргем микән – күрерменме икән.

[2] Кулъязманың бөтен битләре шушында бетә. 32 нче кәгазьнең түбән яктан якынча яртысы гына сакланган. Андагы фрагментлар юлга-юл күчерелде (юл тәртибен җәяләр эчендәге рим цифрлары күрсәтә); шигъри өлешләрдә, строфа төзелеше сакланды.

[3] Шад дил – шат күңел.

Югалган битләрнең санын төгәл әйтүе мөмкин түгел. Бәлки ул, нәкъ шушы күчермәдә, әлләни күп булмагандыр да. Чөнки кулъязма версияләргә нигезләнгән. М. Гафури текстында да, Түләк җир өстенә чыккач, хикәя өзелә, һәм бу аңлаешлы: әсәр героеның чибәр кызны үзе белән бергә алып җир өстенә – кешеләр янына кайтуы белән сюжетның төп өлеше, ягъни әсәрнең эчтәлеге дә нигездә тәмам була. Геройның җир өстен сагынуы Гафури текстында да, нигездә, Олы Кариле дәфтәрендәгечә тасвирлана. Егетнең азаккы сагыш җырыннан соң (кулъязмада 31б биттә теркәлгән җыр) Гафури тексты, Түләкне моңарчы да җир өстенә бер чыгарып алуга карамастан, болайрак тәмамлана: «Падишаһ (Чачдар хан – М.Г.) моны күргәч Заятүләк берлә Айсылуны (Сусылуны – М.Г.) йир өстенә чыкартды. Алар кире шул Балкан тауы өстенә барып күп еллар гомер итделәр. Иң ахырда шул тауда вафат булдылар.

Заятүләк белән Сусылуның каберләре шундадыр. Заятүләк, үз иле Төркстаннан киткәч, кире анда урап кайта алмады. Сусылуга гашыйк булу сәбәбендән Ачылы [күл] тирәсендә Балкан тауында йөреп гомерене үткәрде. Иң ахырда Балкан тауы өстендә вафат булып, шунда күмелде».

Сакланып калган фрагментлардан күренгәнчә, Олы Кариле дәфтәрендәге текст буенча да, Түләк, Сусылуны бергә алып, җир өстенә чыга, анда уен коралларында уйнап, кешеләрне, хәтта җан-җанварларны да үз һөнәренә табындыра.

Дөрес, халык авызыннан язып алынган һәм күп очракта әкият кыяфәтенә керә төшкән кайбер сөйләмә версияләрдә күп мал-мөлкәт алып, җир өстенә чыккан Түләк сөйгәнен Балкан тауда калдырып, үз иленә кайтып китә, үлгән атасы тәхетенә утырып, гаделлек белән илен били. Аны зарыгып көткән Сусылу исә, сагышка түзә алмыйча, үлеп китә. Вәгъдәсеннән чак кына соңгарып килгән Түләк тә, сөйгәненең үле гәүдәсе янына ятып, җан бирә. Мәсәлән, 1959 һәм 1972 елларда чыккан «Башкорт халык иҗаты» китапларында китерелгән төп версияләрдә әсәр шулай тәмамлана (боларның беренчесе В.И. Даль бастырган текстның башкортчага тулыландырылган кире тәрҗемәсе булса, икенчесе 1964 елны М.М. Сәгыйтов тарафыннан Мәкәш авылында язып алынган; һәр ике вариантта да Заятүләкнең атасы Сәмәр хан дип күрсәтелә). Әмма боларда да, кайбер башка вариантлардагы кебек үк, хикәяләүнең бу соңгы өлеше мөстәкыйль әһәмияткә ия түгел: ул бары киңәйтелгән йомгак кына, чөнки анда әсәрнең композициясенә, фәлсәфәсенә әллә ни яңалык өстәлми. Дастанның бөтен фабуласы да шул соңгы сюжеттан түгел, бәлки әсәрнең элгәрге өлешендәге ике моменттан гыйбарәт: беренчесе Түләкнең Сусылуны үзенә буйсындыруы, икенчесе җирне, кешеләрне сагынган адәм баласының су асты падишалыгындагы зар-моңы, тирән сагышы.

Менә шуларның һәммәсен игътибарга алып, мин китабымның беренче басмасында Олы Кариле дәфтәрендәге эпос версиясенең югалган соңгы битләре әлләни күп булмагандыр дип уйлаган идем. Ләкин аннан соң табылган кульязма, Мөхәммәдгәрәй күчермәсе, бу фикерне үзгәртергә нигез бирде. Ягъни Олы Кариле дәфтәре, М. Гафури варианты һәм башка сөйләмә версияләр нигезендә чыгарылган хөкемнең дөрес булу-булмавын киләчәктә табылачак нөсхәләр күрсәтер дигән шөбһә катыш нәтиҗәм дөресрәк булып чыкты. Чөнки, югарыда бер әйткәнемчә, анда әсәрнең ахыр өлеше шактый тәфсилле вариантта бирелгән (97б–101а битләр). Хәзер аның белән тулысынча танышып узыйк.

## «ТҮЛӘК КИТАБЫ»НЫҢ АХЫРЫ
(*Мөхәммәдгәрәй күчермәсе*)

...Анда Чачдархан падишаһ әйде: «Китәрмен тигәнне нәчәгә тикле тотармын», – тиде. Пәриләргә әмер кылды: «Барыңыз, Түләкне сарайына илтеп килеңез». [Түләк]: «Кабул кылса, атамыз йортына барсак булгайму?» – диде. Анда (97б) Чачдар хан падишаһ әйде: «Ир – туган йи[р] ендә, эт туйган йирендә газиз торыр. Атасы йортын сагын[ма]ган ирне ирме дип булыр?» – дәйү дәстүр[1] бирде. Йәнә әйде: «Йортыңызны, сарайыңызны, халкыңызны, малыңызны нәтәк[2] кылырсыз?» – тиде. Анда Түләк әйде: «Әй, падишаһ, барча галәмнең теләген биргүче тәңре тәгалә торыр», – тиде. Анда Чачдар хан падишаһ әйде: «Сезне Аллаһы тәгаләгә тапшырдым», – тип йибәрде. Пәриләр [Түләкне] кызга тапшырып кайтдылар.

Чачдар хан падишаһның шәһәре диңгез арасында (астында? – М.Г.) иде. Түләк кәлде, кыз берлә күрешде, хәл-әхваль сорашдылар. Аты, кошы йамансулап йабыгыпдыр. Үртәкәсене күрде – йабыгыпдыр, күз йәшләре, борын сулары агып торыр. Шул заман Түләк Гөлестанын көйләп, думбырасыны уйнай, кыл кубызын сарнап, үртәкәсен алдыга[3] алып уйнай башлады. Үртәкәсе төзәлеп күрекләнде, куанды. Түләк анда, үртәкәсе бийегәндә, әйтер иде:

Әй үртәкәм, үртәкәм,
Мөйезләрең куш тәкәм,
Буынларың буш тәкәм;
Күзең йәше агыпдыр, ...
Гарибсебсән[4], үртәкәм,
Йәтимсебсән[5], үртәкәм.

---

[1] Дәстүр – рөхсәт.

[2] Нәтәк – ничек.

[3] Алдыга – алдына.

[4] Гарибсебсән – гарибсенгәнсең (гариблек хәленә төшкәнсең).

[5] Йәтимсебсән – йәтимсерәгәнсең.

Уйна, күңелең ачылсын,
Тугъ-тузаның сачылсын
Уйнай биргел, үртәкәм! – тип, күп төрлек уйынлар кылып, халайыкның күңелләрен ачып һәм кийек-кошларның күңел[ләр]е ачылды, шад булдылар.

Бу кичә Түләк йәсигъ намазы кылгандин соң ике рәкәгъәт хаҗәт намазы кылды, Исме әгъзам догасыны укып мөһим кәлтерде. Башын сәҗдәгә куйып әйде: «Илаһи, барча хаҗәт[ем]не рәва кылдың[1]. Имде бер теләгемне рәва кылсаң. Ошбу сарай, тәхетем-бәхетемне сән Рахманым төзеп бирдең, сән Җәббарга[2] шөкер. Имде ошбу тәхет-бәхет, халык, милкемез вә йәнә ошбу Балкан тауны, киек-кошы берлә, урманы-утауы[3] берлә, вә йәнә ошбу бал-сөт, су дәрйалары берлә адәм шәһәренә урнатсаң, кодрәтең бар торыр. Мондаг кылмак сәңа асан торыр, әй Җәббарым!» – тип күзендин йәшен (98а) сачты. Хакъ тәгаләгә йалбарып күп мөнаҗәт кылды.

Ул кичә йатды, иртә таң намазы кылдылар. Анда кыз карады, пулат сарай тәрәзәсендән көн[4] төшде. Андан борын сарай эченә көн төшә тор[ган]дәгел иде. Тышкары чыкды, тиз карап күрде: бер олугъ шәһәр йәнәшәсендә халкы, милке, тәхете-бәхете, Балкан тауы, урманы, киек-кошы, пулат сарайы, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, су дәрйасы – барчасы бөйлә килеп, бер олугъ шәһәр йанында урнамыш. Кыз кайтып сарайга керде, Түләккә әйде: «Әй, йегет, сән белермүсән бу ни йиргә кәлдекең?» – тиде. Анда Түләк әйде: «Әй, җаным мәхәббәте, мәнем йирим-йортым ошбу шәһәр торыр. Атам йортына кәлдек!» – тиде. Андан кыз торды, урынларын төзеде, күшәргәсен корды, ултырды. Һич нәрсә сүз әйтмәде.

Ул вакытда ул шәһәрнең падишаһы үлгән ирде. Ул [көн]дин борынгысы көн ул шәһәрнең олугълары йыйылып иттифак кылган[5] иделәр, таңдагы көн бу шәһәргә төш вакытына тигрү[6] һәркем килсә, [аны] падишаһлыкта күтәргәймез тип. Олугъ-кечек, алтмыш йәшдин алты йәшкә тигрү, бер киңәштә булып, кем килсә дә, падишаһлыкка күтәргәймез тип көтеп торыр ирделәр. Ул кичә йатып, иртә тордылар ирсә, күрделәр: ул шәһәргә йәнәшә бер олугъ тагъ урнамыш. Ул тагъ[ны] тимер ыстанлары берлә йукары калку [йиргә] урнатмыш. Ул тагъның астында бер алтын тәхет урнамыш. Ул тәхетнең айаклары көмешдин, башы гәүһәрдин, ул тагъны алтын берлә коршаган, тагъның[7] башыны ак мәрмәрдән йапкан. Ул та-

---

[1] Рәва кылу – кабул итү.

[2] Рахман – рәхим иясе; Җәббар – җәбер (көч, кодрәт, җәза) (алланың исемнәре).

[3] Утрау –бу урында болын (маллар утлап йөри торган җир).

[4] Көн – кояш.

[5] Йыйылып иттифак кылу – җыелып берләшү.

[6] Тигрү – кадәре (тикле).

[7] Кульязмада: тугъның.

гъның каршысында бер пулат сарайның алдындин бардыр: бер дәрйасы балдин агып барыр, ул сарайның артындин сөтдин бер дәрйа агып барыр; түрт тарафындин судин түрт дәрйа агып барыр[1]. Йөз аргамак ул тагъның төбендә утлай йөрер. Бер ак шоңкар кошы – меңтүлек (?) кош тагъның тигрәсендә очып (98б) шанкылдай йөрер.

Барча олугъ-кечек күрделәр, таң-гаҗәебә калдылар. Бу мондагъ пулат сарай[ны] җиһанда һич кем[нең] күрмеше йукдыр тиделәр. «Мәгәр безләргә бу пулат сарайның ийәсен Хакъ тәгалә падишаһлык[ка] йибәрде бугай тип, гайәт сәүенештеләр. Андин олугъ вәзирләр вә әкябирлар[2] тордылар, ул пулат сарайга бардылар. Ул сарайның ишегендә саклап торган берничә йегетләрне күрделәр – мисле ай берлән көн булгай. Боларның күрекләрен күрделәр ирсә, гакыллары китте, заил[3] булды[лар]. Бер замандин соң гакылларын йыйып алдылар, анда ул сакчы йегетләргә әйделәр: «Бу сарай кемнең торыр вә йәнә бу халык, милек кемнең торыр? – тиделәр. – Вә йәнә бу тауның атыны [ни] тип әйтерләр?» – тип сордылар ирсә, анда ул сарай ишегендә саклап торган йегетләр әйделәр: «Бу сарай Чачдар хан падишаһның к[ийә]ве берлә кызының сарайы торыр. Вә йәнә бу тәхет-бәхет, халык, милек аларның торыр. Вә йәнә бу тауны Балкан тау дип әйтерләр», – [тиделәр] ирсә, иҗазәт[4] теләп, эчкәре сарайга иңделәр.

Ул халайык эчендә Түләкнең атасы Миркас[5] би һәм бергә вар ирде. Түләк берлә һәм катындагы кешеләр берлә күрешә башладылар. Анда күрешә кәлеп, Түләк атасына йитде, кочаклашып күр[еш]деләр, Түләкнең барча буынлары калтырап, төсе үзгәрде. Гяһ кызарды, гяһ уңарды[6]. Анда кыз Түләкдин хөфйәтән[7] сорды: «Ул кеше берлә күрешмәкдә буынлары[ң] ни өчен калтырап, төсең үз[гә] булды», – тиде. Анда Түләк кызга әйде: «Әй, җан мәхәббәте, шул кеше мәнем атам торыр, аның берлә сөеп күрешмәкдән буынларымның хәле кәтде. Шуның өчен калтырадым», – тиде. Кыз белде – кайын (99а) атасы торыр.

Андин олугъ биләрнең вә тәкый олугъ вәзирләрнең, олугъ әкябирларның хатынларыга хәбәр кылдылар: ошбу падишаһның кызына күрешүгә килсенләр дип. Барча олугъларның хатынлар[ы] килде[ләр]. Түләк берлә һәм кызы берлә күрешделәр.

Ул би хатынлары эчендә Түләкнең анасы һәм бар ирде. Анасының ике имчәгенә сөт тулып кәлде. Түләк инәсе берлә күрешмәкдә инәсенең ике им-

[1] Моннан соң «бер ак» сүзе артык (ашыгычрак) язылган.

[2] Әкябирләр – бөекләр (аксакаллар мәгънәсендә).

[3] Сүз шартлы рәвештә укыла, аңлашылмый.

[4] Иҗазәт – рөхсәт.

[5] Исем «с» хәрефенә артык нокта куелып, Мирказь рәвешендәрәк язылган.

[6] Гяһ кызарды, гяһ уңарды – бер кызарды, бер агарды.

[7] Хөфйәтән – яшерен рәвештә.

чәгендин сөт атылып чыкды, Түләкнең йөзенә сачылды һәм агызына[1] керде, Түләк йотды, бал һәм шикәрдин татлыг ирде[2]. Түләкнең сөт ләззәтендән, мәҗлес хушлыкыдан гакылы китеп, йыгълай язды. Инәсе, сөте сачылганга ойалып, тугъры карай алмады, шайәд угылы иркәнен андагук[3] белгәй ирде. Күңелендә әйтер ирде: «Аһ дәрига, мәнем бу ике имчәгемә сөт тулды, булган балага иммәгә, йаки[4] йөклеме булдым икән», – тип йәшерен йыгълар ирде.

Кыз йәнә Түләкдин хөфийәтән сорды: «Ул сөте йөзеңә сачылган нә хатын ирде?» – тиде. Анда Түләк кызга әйде: «Әй, җаным юлдашы, шул кари[5] хатын мәнем инәм торыр». Кыз белде – кайын анасы торыр. Кыз торды, сандык ачды, ике тун[6] алды, алтын-көмеш, гәүһәр-җәүһәр берлә мөрәссәгъ[7] кылы[н]мыш. Түләккә бирде: «Берсен атаңа, берәүсен анаңа йап», – тиде. Түләк бер тунны атасына, бер тунны анасына йапды.

Халайык анда таңга калдылар. Әмма Түләкнең ата-анасы аслан белмәйләр, гайреләре һәмишә белмәйләрмеш. Йегет илән кыз үзләре генә беләләрмеш. Соңра ул шәһәр халкы, йәгъни әкябирлар әйделәр: «Әй, солтан угылы, безләрнең ханымыз[8] үлде торыр. Төнәген барчамыз йыйылып иттифак кылдык. Ханымыз (99б) дин угыл-кыз калмады, ханлыкга ултыртмага. Барчамыз әйдек: таңдагы көн төш вакытына тигрү һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез тидек. Имде сезне безгә тәңре тәгалә кәлтерде торыр. Безне сәңа тәңре тәгалә бойырды, бирде торыр. Кил, имде сәне тәхеткә күтәрәле», – тиделәр. Анда Түләк әйде: «Сез кабул кылыр булсаңыз, мән риза», – тиде.

Шул заман барча халайык бер [б]улып, Түләкне ханлыкка күтәрделәр.

Өч йыл хан булып утырмады, – андаг гаделхаһ[9] кылды – барча вәйран йортлар төзәлде. Мәгәр куйлар бүреләр бергә йөргүтик булды – монынтик гаделлек бәрәкәтендә. Һәм шул вакытгача Түләкне[ң] кем ирдекен һичбер кеше белмәз иде. Әмма һәрдаим Түләкнең инәсе* әйтер ирде: «Ошбу хан безнең гаиб булган[10] угылымызга охшар» – тип әйтер ирде. Анда Миркас би әйтер ирде: «Әй, хатын, гаиб булган угылымызга мондагъ ханлык кайда булыр?»[11] – тип әйтер ирде.

---

[1] Сүз «агазына» рәвешендә язылган.

[2] Бу эпизод Түләкнең «яңадан тууына» (ягъни «теге дөньядан кайтуына) ишарә булса кирәк, чөнки бала туар алдыннан яки ул туган чакта ана күкрәге сөт белән тула.

[3] Андагук – анда ук, шул җирдә үк.

[4] Ике сүз хаталы язылган: имәгәк яр...

[5] Кари – карт.

[6] Тун – гомумән кием, монда: җилән.

[7] Мөрәссәгъ – зиннәтләнү, бизәлү.

[8] Бу сүздән элек артык «үлеп» язылган (яки башка бер-ике сүз төшкән булуы ихтимал).

[9] Гаделхаһ – гаделлек теләү.

[10] Гаиб булу – юк булу, югалу.

[11] Йолдызчыктан алып шунда кадәр текст кызыл кара белән язылган.

Түләк җомга көн Балкан тауга чыкып, алтын тәхеткә ултырып, барча халайыкны җыйып, йимәк-эчмәк[1] биреп, Гөлеста[нын] көйләп, дум[б]расын уйнап, кыл кубызын сарнап, үртәкәсе биеп, аның гыйшкындан корбан кылгутик булып торыр ирделәр.

Бер көн Балкан тауга чыкып, йийеп-эчеп, уйын-тамашалар берлә ултырыр ирделәр. Олугъ биләр, вәзирләр иттифак кылып, сордылар: «Әй, шаһи җиһан, сән безләргә хан булдың. Без сәңа халык илә көтү булдык. Өч йыл булды сорарга [батырлык] кылмадык. Имде безләр сорармыз: кемнең нәселесән? Үзең кемнең угылысән? Атыңыз ни торыр?» – тип сордылар. Анда Түләк әйде: «Мән сезнең үз нәселеңездин, мән вә йәнә үз угылыңызмән», – тиде.

Анлар әйделәр: (100а): «Безнең барча угылымыз үз катымызда торыр. Мәгәр күпйыллар булды бер угылымыз гаиб булып торыр. Сәнең атың кемдер?» – тип сордылар. Анда Түләк әйде: «Мәнем атым Түләк торыр. Атам аты Миркас би торыр», – [тип әйтер][2] иде ирсә, барча халайык кочаклашып күрештеләр, хәл-әхваль сораштылар.

Түләкнең атасы берлә анасы Аллаһы тәгаләгә шөкерләр кылып, [барчага] хәбәр кылып, фәкыйрьләргә күп маллар өләштерде. Алар анда Түләкдин сордылар, ни хәл берлә гаиб булып киткәнен.

Йәнә [Түләк] бу алтмыш йегет атының йөгәнен суйып[3] йибәргәнен, йите кичә-көндез аты алып киткәнен, атының айакына тимер кадак сукканын – барча[сын] әйде ирсә, барча вәзирләр әйделәр: «Бу алтмыш кеше әүүәл сәңа көнләшер дошман булып һәм андаг эш кылдылар. Имде бу көн сән [исән] икәнен белделәр, андин йаманрак дошман булыр», – тиделәр. Анларга Түләк әйде: «Анларны ни кылмак кирәк?» – тиде.

Барча олугълар әйделәр: «Анларны апал итеп измәк кәрәк», – тиделәр. Андин соң анларны өй-илләре берлә апал итеп, ул йыйылган[4] халайыклар берлә иттифак әйләп изә башладылар. Әүүәл ун өйлесен, ил чите тип, азага[5] әйделәр[6]; икенче ун [өйлесен], урыс йорты тип – эчтуккә (?), өченче ун [өйлесен], чит халык тип, чиркәскә әйделәр; түртенче унын, кыр халкы тип – кыргызга, бишенче унын, башка йорт тип – Бохарга, алтынчы унын, каныш (?) йорты тип, кайага әйдә[р] ирделәр.

Андин соң Түләк ул дәүләт эчендә ултырып (100б), утыз алты йыл ханлык сөрде. Андин соң ханише[7] Сусылу дөнйадин үтде. Икенче йыл

---

1 Йимәк-эчмәк – ашау-эчү.

2 Кулъязмада монда «сордылар» дип ялгыш язылган – мәгънәгә туры килми.

3 Кулъязмада ялгыш: «кую».

4 Йыйылган – җыелган.

5 Бу сүзне «Азау» (Азов) дип аңларга да, «атау» рәвешендә кабул итәргә дә мөмкин.

6 Бу һәм моннан соңгы «әйделәр»не куу, сөрү мәгънәсендәге «әйдәделәр» дип аңларга да мөмкин.

7 Ханиш – ханның ише, ягъни ханбикә.

Түләк үзе дөнйадин үтде. Түләк дөнйадин үткәндин соң Түләкнең угылыны ханлыкга күтәрделәр. Ике йыл хан булып торды. Андин соң ул Түләкнең угылы Габдулла дөнйадин үтде. Түләкнең угылы дөнйадин үткәндин соң Балкан тау, алтын тәхет, пулат сарай, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, дүрт тарафдин акган су дәрйасы, бергә килгән халкы, милке – барчасы бер кичәдә гаиб булып, юк булды. Һәм адәм кайда киткәнен белмәделәр...».

Әсәр, Мөхәммәдгәрәй күчермәсе буенча, менә шулай тәмамлана. Олы Кариле дәфтәрендә сакланып калган фрагментлардан, дөресрәге аларның текстуаль раслануыннан күренгәнчә, һәр ике нөсхәнең дә ахырлары бердәйрәк яңгыраган булып чыга. Димәк, безгә кулъязмада хәзергә мәгълүм һәр ике текст та бер чыганакка барып тоташа икән. Бу хәл исә язма версиядәге «Түләк – Сусылу» дастанының фәлсәфәсе, элек белгәнебезгә караганда, күпкә катлаулы, күпкә тирән икәнлеге хакында сөйли. Шуңа күрә мәсьәләгә тәфсиллерәк һәм этрафлырак тукталу зарури.

***Алынды:*** *Госманов М.Г. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Р.Даутовның автор турында белешмәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 237–262.*

## [ТҮЛӘК КИТАБЫ]

(*Самара өлкәсе Камышлы авылында Р. Мәрданов тарафыннан табылган*)

(*4а кәгазь*)[1] «...Безләр өч[2] йегет варалум, ике йегет...[3] суйуб, беремез Акбүзчәне камчылату кәрәк. Ул сагъәт Йилйитмәзнең йөгәнен суйуб алмак кәрәк. Йилйитмәз алып очкай, йә агачка йә ташка сугуб үлтүргәй, аның хурлыгындин[4] котулгаймыз!» – тиделәр.

Өч йегет хәзер килүб, икесе Акбүзчәнең[5] йөгәнен суйуб, берсе кәлеб Акбүзчәне камчылады. Йилйитмәз Акбүзчә Түләкне алыб иллә ...[6] кем, алты-йите көн-төн туктамады. Йитенче иртә, көн чыкар вакытда, бер олуг дәрйаның йакасыйга килеб туктады. Түләкнең һичкайда китмешене белмәгән булмадылар.

Ул сагъәт Түләк карады[7], күрде – бер су пәрисенең[8] падишаһы бар ирде, аты – Чачлар[9] хан атлы[10]. Аның бер кызы бар ирде, гайәт сахибе җәмал ирде. Һәр кем ирсә күрсә, гыйшыклыкындин җан биргү тик булур ирде. Ул Чачлар хан падишаһның кызы ошпу Түләкнең тотган вә туктаган йирдә һәр иртә кәлеб чәчен тарар ирде. Үзенең йөзене йөз мең төрлек[11] берлә бизәр ирде. Ул кыз ул йирдә чәчен тарай ултурур ирде. // (*4б кәгазь*) [...][12] атындин төшде. Кызның йанына кәлде. Кыз тоймады,

---

[1] Дастан тексты язылган кулъязма җыентыкта бу битнең өске өлешендә күчерүче тарафыннан биш юл чамасы буш урын калдырылган. Күрәсең, кулъязманы күчерүчегә дастан текстының протографында (ягъни, күчергеч өлге булган нөсхәдә) ниндидер дефект-бозыклык (кәгазе яисә язуы зарарланган) булгандыр. Кәгазь битендәге әлеге буш урынга соңрак гарәп телендәге бер юллык дога язып куелган.

[2] Кулъязмада: «өҗ».

[3] Кулъязмада бу урында бер-ике сүз язарлык буш урын калган. Әсәрнең М. Госманов бастырган текст вариантында әлеге урында «акбүзчәнең җөгәнен» сүзләре язылган (Госманов М. Каурый каләм эзеннән..., Б. 239. Алга таба М.Г. дип һәм бит саны күрсәтеләчәк).

[4] Кулъязмада: «хураэгындин (حوراعندين). Күрәсең, бу ялгыш протографтагы «хурлы гындин» (حورلي عيندين ) дип, аерыбрак язылганнан киткәндер.

[5] Кулъязмада: «Акбүзҗәнең».

[6] Кулъязмада бу урында бер сүз язарлык буш урын калган. Дастанның М. Әхмәтҗанов бастырган вариантында (алга таба: М.Ә.) «иллә» сүзеннән соң «очды» сүзе язылган (Мирас. – Б. 19).

[7] Кулъязмада: «арады». «Карады» вариантын әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләре буенча куйдык.

[8] Кулъязмада: «бәрисенең».

[9] Кулъязмада: «Чалчлар».

[10] Кулъязмада: «атаг» (اتاع). Күчерүче тарафыннан протографтагы «атлы» (اتلي) яисә «атлыйг» (اتليع) сүзләренең берсе шулай бозып күчерелгән булса кирәк.

[11] Монда бер сүз төшеп калган. М.Ә. текстында бу урында «бизәкләр» сүзе бар.

[12] Кулъязмада 4б кәгазьнең өске өлешендә уң як почмагы ертылган булу сәбәпле, дүрт юлның башындагы берничәшәр сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «Түләк кызны күреп» сүзләре язылган (Б. 20).

чәченең озын[...][1] бар ирде. Чәчен ике йанына ачуб, йөзендин китәрүб тарай [...][2] кәлеб кызга сәлам бирде. Кыз сачен йөзендин китәрүб торга[...] еб[3] әйде: «Әгәр иңсәмне бирүб торган вакытум булмаса ирде, йөземне сәңа нийәтән күргәзгәй ирдем», – тиде. Түләкнең йөзүн күрде, гайәт зиба йегет торур. Түләккә кыз андагъ гашыйк булды, һич сүз әйткүчегә хале булмады. Ул йирдән китәр дәрманы булмады. Күңлүндә әйден[4] әйде: «Бу йегетне бер заман алдай торайын, шайәт ки котулурмән», – тиде вә «котулуб киткәймән», – тиде. Кызның ул сагъәт Түләкне күреб тәне калтуралы[5], һич кузгалур хале булмады. Түләк кызга андагъ кушагъ әйде:

Инеб кәлдүм атымдин,
Имди сәнең үзеңә.
Сәлам бирдүм бән сәнең
Ай тик күреклү йөзеңә.
Гашыйк булдум бән сәнең
Назик зифа буйыңа,
Сүзең әйтче, Сусылу,
Сүзең әйтче, Сусылу!

Кыз Түләккә каршу андагъ әйде:

Сән усалның үзенә[6],
Гашыйк булдуң, бай угълы!
Алтун сыргам бирәйүм,
Бүләк булсун, бай угълы.
Хәстә булуб үләрсән,
Кайтуб киткел, бай угълы,
Кайтуб киткел, бай угълы!

Андин йәнә Түләк кызга кушагъ әйде:

Сәфәр кыйлдук йөз кеше,
Йөгәнем суйды өч кеше.
Атум килде арушыб,
Кулум кәлде карушуб.
Атуң-йулың белмәймән,

---

1 Алдагы искәрмәдә күрсәтелгән сәбәп аркасында берничә сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «озынлыкы алтмыш карыш, буйы» сүзләре язылган (Б. 20).

2 Алда күрсәтелгән сәбәп аркасында берничә сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «торган вакыты ирде. Түләк» сүзләре язылган (Б. 20).

3 Алда күрсәтелгән сәбәп аркасында берничә сүзе билгесез. М.Ә. текстында бу урында «торганы берлән әйләнеп» сүзләре язылган (Б. 20).

4 Бу сүз артык язылган булса кирәк.

5 Бу сүз башта «калтураб» дип ялгыш язылып, күчерүче үзе «б» хәрефен сызып «ды» кушымчасын өстәгән.

6 «Үзенә» сүзе күчерүче тарафыннан кульязма битнең читенә соңыннан өстәп куелган.

Атың әйтче, // (*5а кәгазь*) Сусылу,
Атың нәдүр, Сусылу!

Андин кыз йәнә Түләккә кушагъ әйде:

Атың килсә арушыб,
Кулуң килсә карушыб,
Атың-йулың белмәйсән[1],
Атуң әйтеб бирәйен,
Атуң үзең beләсән:
Һәрамзалык кыйласән,
Сары Мыркас угълы сән,
Гайан Түләк атлигъ сән!
Атуң-йулың белмәйсән,
Кайдин азыб йөрерсән?!
Зифа Түләк, йәш угыл,
Зифа Түләк, йәш угыл!

Андин соң Түләк әйде:

Бер дигәндә бил алган,
Билән[2] салуб суна алган,
Канат какмай каз алган,
Агыз канлыйг бүре алган,
Айагы сибкел төлке алган,
Муйны озун торна алган,
Бога кылы кув алган.
Кош очкыры[3] чүрәкәй[4],
Канат какмай шуны алган.
Арту кошны ашурмаз
Ак шонкардин бизәйен,
Суның кызы, Сусылу,
Сәнең берлән булайын,
Атың нәдүр, Сусылу,
Атың нәдүр, Сусылу?

---

1 Бу сүз кулъязмада «белмәймән сәң» рәвешендә хаталы язылган.

2 Кулъязмада: «билне».

3 «Очкыры» сүзе кулъязмада бер мәртәбә ялгыш язылып, анысы сызылмыйча янәшәсендә яңадан дөрес итеп язылган.

4 Кулъязмада; «чүрәкле» (حورعكلي). Контекстка күрә, бу сүзнең «чүрәкәй» (حورءكاى) булуы таләп ителә. Бу сүзләрнең язылышта бер-беренә охшашлыгы буталыш китереп чыгарган булса кирәк. Ягъни, «әй» кушымчасының «әлиф» һәм «йа» хәрефләре «ләм» һәм «йа» булараk кабул ителеп, «ле» кушымчасына әверелеп киткән. Ягъни, «кош очкыры» (кошның җитезе) чүрәкәй – мәгънәви яктан дөресрәк була. Дастанның М. Гафури бастырган вариантында бу сүз «чүрәгәй» дип бирелгән (Б. 13).

Андин кыз әйде:
Атум сораб нидәрсән?
Хуш хәмаил[1], хуш йөзек.
Менә сәңа бүләгем!
Безнең йирләр катыдур,
Торалмассән, Түләгем,
Хәстә булыб үләрсән!
Мән дә сәнлек дәгүлмән,
Кайтуб киткел, Түләгем,
Кайтуб киткел, Түләгем!
Андин соң Түләк кызга әйде:
Ар[ту] кошны ашурмас
Шоңкарымдин бизәйем,
Айлыйг йирдә бер баскан,
Йыллыйг йирдә бер[2] баскан,
//(*5б кәгазь*) Киле-җалы таралган,
Түрт айагы мәрмәр алган,
Аргамакдин бизәйен!
Суның кызы Сусылу,
Сәнең берлән булайын,
Сәнең берлән булайын!
Андин соң кыз әйде:
Акча йөзем күрсәткән,
Ура[у] сачем тараткан,
Толум-буйум бизәткән
Алтун тарак, ай көзгү –
Менә сәңа бүләгем!
Шуны ал да йулың[3] ал,
Кайтуб киткел, Түләгем!
Мән дә сәнлүк дәгелмән,
Ышанмагыл, Түләгем!
Андин Түләк әйде:
Ун ай төгәл күтәргән,
Умыртгадин бөгүлгән,
Ийәле кулдин талпуткан,
Алтун тезгә ултурткан,

---

1 Кулъязмада: «җәмаил».

2 Кулъязмада: «берш». Дөресе «биш» булырга тиеш. Чөнки Түләк соңрак әйткән бер кушагында (*7а кәгазь*) шушы ук сүзләр кабатланган юлда «биш баскан» дип язылган.

3 Кулъязмада: «йулыңа».

Төн йокысун өч бүлгән,
Төнлә торуб имезгән,
Айа[к]дан коймак йидүргән,
Айр[ы] имчәкдин сөт биргән
Анайумдан бизәйүм!
Кара кешкә ураткан,
Алтун тезгә ултурткан,
Ир сакалын үстүргән
Атайумдан бизәйен!
Суның кызы Сусылу,
Сәнең берлән булайын!
Атың әйтче, Сусылу,
Атың әйтче, Сусылу?

Андин кыз әйде:

Хуш хәмаил[1], хуш йөзек
Алмадуң сән, Түләгем,
Алтун сыргам, ай көзгүм –
Йәнә бирдүм бүләгем.
Бүләк бирүб алмассән,
Нидүр сәнең теләгең?
Сүзең әйтче, Түләгем,
Сүзең әйтче, Түләгем!

Андин Түләк кызга әйде:

Хуш хәмаил[2], хуш йөзек,
Зифа буйың – теләгем.
Алтун тарак, ай көзгү –
Мән нитәйен бүләгең?
Бүләк маңа кәрәкмәз,
Зифа буйың – теләгем!
Сүзем шулдур [...][3]

// (*6а кәгазь*) Андин соң баруб әйделәр Чачлар ханга. Чачлар хан кызына катыйг ачыглануб берәгүне йибәрде, әйде: «Нә өчүн андагъ эш кыйлыб, халкын һәлак кыйла торур? Анда ул йегетне үзе кабул кыйлмаса ирде, адәмнең ничек бу йиргә килүргә нә хале бар ирде? Үзе алуб килүб торур. Имди халыкны нә өчүн һәлак кыйла торур?» – тиде. – «Ул адәмнең догасы мөстәҗаб торур. Баруб кызга әйтүңезләр: сарайның ишеген вә

[1] Кульъязмада: «җәмаил».

[2] Кульъязмада: «җәмаил».

[3] Бу урында, кульъязманың бер кәгазе җуелганлыктан, текстка өзеклек кергән. Мондагы «шулдур» сүзе кульъязманың 5б кәгазе астында кустод буларак язылган.

тәрәз[ә]сен ачсун, ул йегетне үз катыйга алсун, гозерләр кыйлыб йахшы дога үтүнсүн!», – тиб, бер кем ирсәне изеде.

Ул кем ирсә килеб атасының сүзүн әйткәч, кыз сарайның ишеген-тәрәз[ә]сен ачды. Ул заман кызның тәнегә көн төшде, күкрәгендин кереб, аркасындин чыкды. Кыз йануб-көйүб, үлгү тик булуб, булат-сарайга керде. Кызны күреб пулат-сарай казан тик кайнар булды. Шул заман Түләк сарайга керде, кызны күрде, сачендин ураб алды, күтәрүб пулат-сарайның ишегенә сукды, йәнә түренә сукды, кызның гакылы китде. Бер замандин соң кыз исен йыйуб алды. Күзүн ачды, карады, Түләкне күрде, әйде: «Әй, йегет, мән сәне сәүмәзлекдин мондагъ эш кыйлган дәгүлмән. Мән бер падишаһның кызымән, ошпу эш атамга билгүсез булмагай ирде», – тиб, «мондагъ эш кыйлдым мән», – тиб, йегетнең күңлүн бер сүз берлән алды. Йәнә әйде: «Әй, йегет, мончага тигрү эшем хата ирде, имди Хак Тәга[лә]гә // (*6б кәгазь*) шөкер, эшемез күни булды», – тиб, сөйүк-мәхәббәт берлән Түләкнең му[й]ныга кыз кулун салды. «Атамдин дәст[ү]р булуб хәбәр кәлде – сәне үз йанумга алмага», – тиде.

Түләк, кызның бу сүзләрене ишетүб, кызның башына җанын фида кыйлгу тик булды. Андагъ сөйүк-мәхәббәт берлән кыз муйныга Түләк кул салды, мәгәр дигәйсән, күкдин көн берлән ай бер йиргә кушылган[1]! Мәхәббәт-сәвекләре андагъ мәхәббәт берлән сәвешкәнен[2]». Анда кыз Түләккә әйде: «Әй, йегет, имди мәнем гайебемне кичергел», – тиб гозерләр кыйлды, үтүнде. Әйде: «Әй, йегет! Ошпу көн эсселекендин халемез мөшкел булды», – тиб. Әйде: «Имди сән Хак Тәга[лә]дин үтенүб, сез дога кыйлсаңыз, безләр «амин» дисәк, Хак Тәга[лә], шайәт, гафу кыйлыб, бу михнәте безләрдән китәргәй[3]!» – тиб, кыз Түләкнең айагына төшде, үтенде. Түләк андагъ кызга әйде: «Әй, җаным мәхәббәт, бер сагъәт сән сабыр кыйлыб ултургул, мән хәлвәт йиргә барайым, Хак Тәга[лә]дин хаҗәт теләйен, сән һәм теләкдә булгайсән!» – тиде.

Түләк сарайдин чыкуб йир йөзенә инде, хәлвәт йиргә барды, тәйәммем кыйлды, ике рәкәгъәт хаҗәт намазы кыйлды, «Исме әгъзам» догасын укыб, мөһиммә килтүрде, башыны сәҗдәгә куйды. «Илаһи, барча мөшкел эшләр сәңа асан торур», тиб, Хак Тәга[лә]гә мөнаҗәт кыйлыб, әйд[е]: «Бу кавемдин бу көн эсселеген[4] китәргел, мәслихәт бирмәк сәңа асан торур!» – тиб йалбарды ирсә, шул заман куңыз салкун йил исеб, бал дәрйасы, йәнә сөт дәрйасы, // (*7а кәгазь*) йәнә түрт су дә[р]йасы рәуван

---

[1] Кулъязмада: «кушылгай».

[2] Бу җөмләнең ахыры язылып бетмәгән. М.Ә. текстындагыча дәвам итеп бетергәндә ул «... Аллаһы Тәгаләдин гайре кем ирсә белмәгәй» рәвешендә булырга тиеш.

[3] Кулъязмада: «китәргел».

[4] Бу сүз ике мәртәбә язылган.

ага башлады. Тәмамысы иссез булуб өч көн-төн йокладылар. Өч көндин соң бер өлүше һәлак булган көн-төн[1] эсселекендән.

Андин соң Түләк кыз берлән андагъ көндин-көн мәхәббәтләре артук булды. Кыз Түләккә әйде: «Әй, җанум, мәңа дәстүр биргел», – тиде. – «Һәр иртә чыкып, сачүм тарайын, нурд[ид]әм бизәп киләйен!» – тиде. Түләк кызга дәстүр бирде. Кыз һәр иртә хәлвәт чыкып, сачен тарап, йөзүн бизәб килүр ирде.

Бер көн Түләк кызга әйде: «Әй, җанум! Нә[2] йиргә чыкып сачең тарарсән?» – тиде. Кыз Түләккә әйде: «Нә йирдә мәнем сачемдин ураб алдуң, шул йирдә тарармән», – диде. Анд[а] Түләк әйде: «Әй, җанум мәхәббәт, андагъ ирсә, мәнем атым берлән кошумны күрмәймүсән?» – тиб айды. Анда Түләккә кыз әйде: «Әй, жаным! Сән мәңа гашыйк булмышда әймәдеңмү – атымдин бизәйен, кошымдин бизәйен димәдүңмү?» Анда Түләк әйде: «Ул көн андагъ көн ирде, бу көн йәнә үзгә булды. Күрсәң, бар булса, айгыл!» – тиде.

Кыз Түләккә әйде, кушагъ әйде:

Атуң аты Йилмайа,
Имди аңа көн кайа!
Атың торур йабугуб,
Кошың торур бойугуб,
Үзең салыб киткәндин соң
Тәкъи нәчөн сорарсән,
Тәкъи нәчөн сорарсән?

Андин Түләк кызга әйде:

Атум торур ул йирдә,
Мәнем өчен зарыгуб,
Айлык йирдә бер баскан
Түрт айагы талугыб,
Йыллык йирдә биш баскан
Ике күзе карлугуб, // (*7б кәгазь*)
Атум алыб килмәгә
Дәрман итче, Сусылу?
Хәлең йитсә, атумны
Алуб килче, Сусылу[3]!
Алыб килче, Сусылу!

Андагъ кыз Түләккә әйде:

Атың, кошың бу йиргә
Килеб йитмәз, бай угълы

---

[1] Кулъязманың бу урынында «йокладылар» сүзе язылып, күчерүче тарафыннан сызылган.

[2] Бу сүз ике мәртәбә язылган.

[3] Кулъязмада «Сусылу» сүзе алдына күчерүче ялгыш «бай» сүзен язган.

Бу хезмәтең итмәгә
Халүм йитмәз, бай угълы.
Хакдин теләк теләче,
Ишетмәче, бай угълы!
Теләгеңне Хак бирүр,
Давыкмачы[1], бай угълы!
Теләгеңне Хак бирүр,
Давыкмачы, бай угълы! – тиб, кыз әйде. Андин соң Түләк торды, йәсигъ намазын кыйлды, «Исме әгъзам» догасын укуб, мөһиммә кәлтүрде. Андин соң башын сәҗдәгә куйды[2], әйде: «Илаһи, барча агырлар сәңа асан торур. Атумны, кошымны ошпу йиргә кәлтүрсәң, кодрәтеңдин кәлүр. Мән бичараның хале кем белмәгәй», – тиде. – «Рахманум, сәндин йарый!» – тиб, ул кичә кыз берлән йаттылар. Иртә таң намазы булуб ирде. Намазга торды. Ул вакытта Йилмайа кешнәб ирде, кош шаңкырлады – аваз кыйлды. Ул сагъәт Түләк пулат-сарайның тәрәзәсендин карады: Акбүзчә Йилйитмәз аргамак кәлүб торур, алтун ийәре[3] өстендә, Ак шынкар ийәр[4] кашында күрде. Ул сагъәт Хак Тәга[ләгә] шөкер кыйлыб, башын сәҗдәгә куйуб, әйде: «Илаһи, бу мөлкәт, бу гъинайәт сәндин торур», – тиб.

Атының кашына барды. Аты, кошы Түләкне күрде ирсә, аты селкенде, кошы кагунды – борынгы тик булды. Ул сагъәт Хак Тәга[лә] ул пулат-сарайның кашына үлән үстүрде[5]. Һәр кичә анлар йийәр ирде, // (*8а кәгазь*) кичәсенә йәнә үсәр ирде. Йәнә ул кош тагълар[6] тигрәсендә йөрүб кошлар йийүр ирде.

Йәнә Түләк кыз мәхәббәт[е бе]лән каса булып, йөзенә саб-сары булуб чыкды. Үз[е] белмәз ирде. Кыз һәр иртә сачен тарамага чыкыб китде. Анда Түләк кызның ай көзгүсен түшәк өстүндә калмышун күрде. Ачуб карады, үзенең йөзене күрде: саб-сарыйг койылмыш, гайәт усал булмыш иде. «Аһ, дәрига, каса булубмән, үлүм хәлегъә килебмән», – тиде.

Торды, гөлестан дигән уйун йасады, бер думбыра йасады, йәнә бер кыл[7] йасады, бер кубыз йасады, йәнә бер үртәкә йасады. Ул үртәкәнең

---

[1] Давыкмачы – даулама, кычкырма. Давык – дау сүзенең архаик формасы булса кирәк.

[2] Кулъязмада: «кубды». Бу хатаның сәбәбе: «йа» хәрефенең астында ике нокта куясы урынга бер нокта гына куелу.

[3] «Алтын ийәре» сүзтезмәсе кулъязмада «аултун ир» дип, хаталы язылган.

[4] Кулъязмада: «ир».

[5] Кулъязмада: «үшүрде» ( وشوردا ). Бу очракта күчерүче гарәп имлясындагы «син» хәрефеннән соң килә торган «тә» хәрефенең ике ноктасын өч нокта буларак кабул итеп протографтан ялгыш күчергән. Ягъни, дөресе ( وستوردا ) дип языларга тиеш иде.

[6] Кулъязмада: «тагъларга».

[7] Кулъязмада: «кыйл».

мөйезләрен алтундин төзеде, айакларын көмешдин төзеде[1], ике күзен гөлдин төзеде. Ул үртәкәне бу җиһан бизәге берлән бизәде.

Торды, тәһарәт төзеде, ике рәкәгъәт хаҗәт намазун укудин [соң], «Исме әгъзам» догасын укуб, мөһиммә кәлтүрде. Башын сәҗдәгә куйуб айды: «Илаһи, хаҗәтүмне сән рәва кыйлгыл. Ошпу төзегәнем уйунум сыйфатыны мәңа сону биргел, йәнә ошпу үртәкәгә җан биргел! Бер Ходайа, ошпу йирдә сәнең хөкемүң берлән гөрифтар булдум, шайәд ки, уйун кыйлсам, күңелүм мәлүл булмагай», – тиб, Хак Тәга[лә]гә йалбарды. Шул сагъәт Хак Тәга[лә] хаҗәтен рәва кыйлды. Уйун сыйфатын бирүб, ул үртәкәгә җан бирде. Түләк имди[2] Хак Тәга[лә]гә шөкер кыйлыб, уйун[3] уйнады, башлады гөлестанун, йәнә думбырасун, кыл[4] кубузун – өчүсүн бергә уйнар ирде. // (*8б кәгазь*) Үртәкәсе бийер[5] ирде. Барча халык йыйулдылар, сарай эченә сыймаз булдылар, һәр кичә-көндүз Түләк катундин китмәз булдылар. Сарай эчендә торур йир булмады. Тышкары чыкыб ултуруб, мәҗлес коруб, Түләкнең уйуныйга гашикъ булуб, йийәрдин-эчәрдин бизделәр. Иртә торсалар, кич булганун белмәзләр ирделәр. Түләк уйуныйга гашыйк булуб һавадагы кошлар-кортлар, йаландагы ки[йе]кләр – барчасы мондагъ йыйулуб, кичә-көндүз китмәз булдылар. Боланлар, коланла[р], ки[йе]кләр, хәшәрәтләр – барчасы Түләкнең уйуныйга гашыйк булыб, йимәкдин-эчмәкдин бизделәр.

Көнләр дә бер көн Түләк күңелендин зарыйлыг кыйлды: «Әй, Кәрим, вай, Рахим, бонча сарайлар, ки[йе]кләр, хайваннар, хәшәрәтләр берлән мәэва[6] булуб торармән. Йил кузчың тузан басып, сурәтем азыб, җенләр, пәриләр сурәтендә әверелмешмән!» – тиде. Зар-зар йыгълады.

Ул кичә кыз катыйга йатты, тәкъи кызга әйде: «Аһ, дәрига, сәнең зипа сурәтеңә алдануб, адәмләрдин айрулыб, нәсәбсез[7] булдум. Үләр булсам, кайда ата вә кайда ана?» – тиде. «Әй, йегет, гакылың киттемү? Бу гъинайәт, бу дәүләт кемдин торур, белмәзмүсән? Бу дәүләткә йиткүргән падишаһлар падишаһы Тәңре вә Тәга[лә]не онуттыңму? Әйтде: «Айырылганларны кушмак аңа асан торур», – тиб.

---

1 Кулъязмада: «төзедем». Протографта «төзеде» сүзеннән соң булган «мим»гә охшаш язылган «һәр» сүзен кулъязманы күчерүче «м» (мим) хәрефе буларак кабул иткән булуы ихтимал. Ул вакытта текстның бу урындагы дөрес варианты «...көмешдин төзеде, һәр ике күзен...» рәвешендә булыр иде.

2 Кулъязмада: «әйде».

3 Кулъязмада: «әйун».

4 Кулъязмада: «кыйл».

5 Кулъязмада: «бөйүр» (бойур).

6 Кулъязмада: «мау» ( ماو ) дип язылган бу сүзнең дөрес варианты, ахрысы, «мәэва» ( ماوا ) булгандыр. Аның гарәп телендәге «сыенып яшәү» мәгънәсе контекстка туры килә. Әлеге сүз М.Ә. текстында «сау» дип, ә М.Г. текстында «шад» дип бирелгән.

7 Кулъязмада: «сәбәбсез» ( سببسز ). Бу ялгыш, күрәсең, «нәсәбсез» ( نسبسز ) сүзенә охшашрак язылудан чыккандыр.

Бу сүз илә йегетнең күңелүндән аулады. Йаттылар. Иртә намазга тордылар ирсә, күрде – бер алтун тәхет сарайның кашында улмыш. Тәхетнең // (*9а кәгазь*) өстенә бер олуг, бийек башы һавага чыкган тагъ урынмыш. Сәкез кырлу, дүрт тарафы тимүр берлән тайаган тәхетүндә йукары калкуб сәйа булган. Ул тагъ алтун берлән коршаган, башыны ак мөрәүвәр берлән йапкан. Түгәрәк йанына агач үскән, чыпык урман булган. Барча боланлар, коланлар, айулар, төлкүләр, кошлар, кортлар анда урынмышлар. Бу эшләрне күрүб, кыз берлән Түләк Хак Тәга[лә]гә шөкерләр кыйлып, Түләк тәхеткә кәлеп, алтун тәхет үзә инүб ултурды. Уйунларын кулына алды. Купсаб-купсаб уйнай башлады. Андагъ айтеб дыбсар[1] ирде:

Гөлстаным көйләсүн,
Кыл[2] кубызум сарнасун,
Үртәкәм хуш уйнасун,
Күрмәгә килгән халайыклар
Үзүн-үзе белмәсүн!
Уйнай биргел, үртәкәм,
Уйнай биргел, үртәкәм!
Алтун тәхет урнатган,
Көмешдин[3] айак йараткан,
Тәхет-бәхет төзүткән
Хак Тәга[лә] кодрәте, –
Шөкер кирәк, Сусылу,
Шөкер кирәк, Сусылу! – тиб уйнар ирде. Анда йыйулган халайык әйделәр: «Бу кем тагы[4] торур? Бу нә атлыйг тагъ торур?» – тиделәр.

Анда Түләк анларга дыбсаб әйде:

Мәнем тауым Балкан тагъ,
Башы һавага чыкган тау,
Тимүр берлә [тайаган][5],
Алтун берлә коршаткан,
Ак мөрәүвәрдин йабкан тау! – тиб әйде. Аны ишеткән хайваннар, ки[йе]кләр, хәшәрәтләр йыйулуб килүб, башларын түбән салуб тыңлар ирделәр.

---

1 Кульъязмада: «дыбсарым».

2 Кульъязмада: «кыйл».

3 Кульъязмада: «көмесдин». Чөнки «шин» (ش) хәрефе өстенә куеласы нокталары язылмыйча, ул «син» (س) буларак калган.

4 Кульъязмада: «тагъ».

5 Кульъязмада бу сүз язылмыйча калган. Без аны М.Ә. бастырган текстка нигезләнеп өстәдек.

Т[үләк анла]рны[1] күрүб // (*9б кәгазь*) дыбсаб әйде:

Утлар уты май татур,
Мал-туар, болан сәүгән тау;
Турлавы киң, йире киң,
Төлке сәүгән Балкан тау!
Йатур[2] йире йакма алтун,
Йылан сәүгән Балкан тау!
Йийәр йимеше[3] төкәнмәз
Айу сәүгән Балкан тау!
Кабаклары кабарчык,
Кар сәүгән Балкан тау!
Күл-койусы камышлык, –
Кабан сәүгән Балкан тау!
Йире салкун, йимеше күб[4], –
Кошлар сәүгән Балкан тау!
Сөт дәрйасы су алмас,
Сукыр[5] сәүгән Балкан тау!
Башымызның өстүндә
Сайә булган Балкан тау! – тиб уйнар ирде.

Ул җырлар[6], ул эшләр кызның атасы Чачла[р] ханга ишетүлде. Чачлар хан падишаһ кызындин йыраклыгы йите көн-тө[н]лек йир ирде. Түләкне һәм уйунларыны күрмәгә андагъ гашыйк булды. Йимәкдин-эчмәкдин бизде, дийүләрне, пәриләрне Түләкне алмага йибәрде. Пәриләр кәлүб Түләкне алуб китәр булдылар. Анда кыз Түләккә әйде: «Әй, җаным, ошпу үртәкәне алуб бармагул. Ошпу газиз сурәтне җанлыйг[7] Хак Тәга[лә] сәңа биребдүр. Нагяһ атам алуб калмасун. Мондагъ нәрсә падишаһларга тансук торур. Үзгә бер үртәкә сурәтене йасаб алуб баргыйл!» – тиде. Түләк аның сүзүн хуш күрде, үзгә үртәкә сурәте йасады. Ул җанлыйг үртәкәсен кыз йанына куйуб китде.

---

[1] Кулъязманың кәгазе бу урында дефектлы (тишелгән). «Анлар» сүзенә дә ялгыш бер-бер артлы ике кушымча («-га» һәм «-ны») ялгап язылган.

[2] Кулъязмада: «батур».

[3] Кулъязмада: «йөрүе, эше». Дөрес вариантны әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләренә нигезләнеп өстәдек.

[4] Кулъязмада: «күб» сүзе алдыннан «йук» гыйбарәсе язылып аннары сызылган.

[5] Кулъязмада шулай. М.Г. текстында бу сүз «суыр» (сөркә, байбак) дип (Б. 251), ә М.Ә. текстында «сывыр» дип (Б. 25) бирелгән.

[6] Бу сүзне «хәбәрләр» дип тә укырга мөмкин. Әсәрнең башка күчермәләрендә ул шулай дип бирелгән дә.

[7] Кулъязмада: «ханлыйг» (حانليغ). Әлеге сүзне төрлечә язу әсәрнең башка күчермәләрендә дә очрый. Текстта берничә юл түбәндәрәк бу сүз «җанлыйг» (جانليغ) дип язылган.

Чачлар хан падишаһга йакын йитәр киләды бсаб әйде. Уйнай башлады. Түләкнең уйун уйнаганун ишетүб, гашыйк булуб [сабыр]...[1] торалмады. Бер таз колы бар ирде. Аны үзе урыныйга // (*10а кәгазь*) тәхет үзрә ултуртты. Үзе каршы[2] кәлеб тыңлар ирде. Кыз Түләккә атасының сурәтене әйткән ирде. Түләк дыбсаб әйде:

Гөлестанум көйләй[д]үр, –
Думбурам хуш уйнайдур!
Тәхетдә ултурган Чачлар хан
Тәхетдин төшүб тыңлайдур,
Тәхетдин төшүб тыңлайдур! – тиб.

Андин соң Чачлар хан әйде: «Валлаһи, бу Түләк бүзүрг кеше торур, белекле кеше булмак кәрәк, мәне мондагъ белде», – тиде. Тәхетенә кайтуб ултурды. Түләк килүб йит[т]е, падишаһның сарайыга төшүрделәр. Кырык көн-төн йимәк-эчмәк[3] берлән, уйун-тамаша берлән калдылар.

Андин соң Түләк кызны һәм Балкан тауны, урынуны гайәт сагынды. Чачлар хан падишаһга дыбсаб-кубсаб андагъ әйде:

Балкан тауым монда йук,
Ак ки[й]үкем монда йук,
Ултуруб уйун төзегән
Алтун тәхтем монда йук!
Җөмлә буйы[4] җофарлы,
Зифа йарым монда[5] йук, – тиб әйтүб уйнады ирсә, хан падишаһ дийүләргә, пәриләргә бойурды: «Баруңлар, Түләкнең Балкан тауыны алуб килүңләр!» – тиб йибәрде.

Дийүләр бардылар. Хак Тәга[лә] Балкан тауны анларга күргәзмәде, йир берлә төп-төз калды. Дийүләр, пәриләр ул пулат йанындагы олуг таула[р]ны бер-бере үзә куйдылар. Анда Түләк дийү пәриләрнең тауын алуб килгәнүн күрүб, дыбсаб әйде:

Мәнем тауым ул дәгел,
Алтун тәхтем [ул дәгел][6],
Тауны тауга охшатуб,
Пиленә тимүр коршатуб,

---

[1] Кулъязманың кәгазе дефектлы булганлыктан, монда бер сүз укылмый. Контекстка күрә, аның «итеп» дигән сүз булганлыгын чамаларга мөмкин. Моңарчы басылган текстларда бу урында «сабыр итә алмады» сүзләре язылган.

[2] Кулъязмада: «кыршуа».

[3] Кулъязмада: «йимәк-эҗмәк».

[4] Кулъязмада: «бийүе».

[5] Кулъязмада «монда» сүзе ике мәртәбә язылган.

[6] Кулъязманың кәгазе дефектлы булганлыктан, бу ике сүз укылмый иде. Без аларны әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләренә нигезләнеп өстәдек.

Ал[уб] килүб торурлар,
//(*10б кәгазь*) Алуб килә торурлар. – тиб Түләк әйде исә, андаг Чачлар хан әйде дыбсаб:
Тауны тауга охшатуб,
Тимүр берлә коршатуб,
Монда торгыл Түләгем
Балкан тагъга охшатуб,
Балкан тагъга охшатуб, – тиб Чачлар хан әйгач, Түләк аңа каршу әйде дыбсаб:
Бары, бары, бары тау,
Барундин[1] бийүк Балкан тау;
Майлаб салган кайушдай,
Йыланы күб Балкан тау.
Сулаб каккан казукдай,
Суыры күп Балкан тау.
Майлаб[2] салган кайушдай
Йыланы күб Балкан тау.
Айыру тойак, шеш мөйез,
Боланы күб[3] Балкан тау;
Алпан-толапан йөргән
Айу сәүгән Балкан тау;
Барундин бийүк була[4] йөргән
Бүре сәүгән Балкан тау.
Иңсә йоны нәчә алган,
Башы түбән ийүлгән,
Кабан сәүгән Балкан тау;
Кыз угландай сөзелгән,
Төлке сәүгән Балкан тау;
Күб йәшәгән карыйдай,
Карсак сәүгән Балкан тау.
Ойа табар йире хуш,
Кошлары күб Балкан тау.
Дәстүр бирсә Чачлар хан,
Күргем микән Балкан тау! – тиб Түләк әйде ирсә, анда Чачлар хан әйде: «Китәрмен [тигән][5] Түләкне мончага тикле тоткай-

---

[1] Кулъязмада «барундин» сүзе алдына «тау» сүзе язылган. Ләкин ул бу урында артык.
[2] Кулъязмада «майлаб» сүзе ялгыш ике тапкыр язылган.
[3] Кулъязма текстында «күб» сүзе һәм аннан соң ук «сәүгән» сүзе язылып, алар икесе дә вертикаль рәвештәге берәр сызык белән сызылганнар. Контекстка күрә, анда «күп» сүзе кирәклеге аңлашыла.
[4] Кулъязмада «була» сүзе ике тапкыр язылган.
[5] Бу сүзне әсәрнең моңарчы билгеле булган нөсхәләренә нигезләнеп өстәдек.

мыз?![1]» – тиде. Пәриләрегә әмер кыйлды: «Баруң[ыз! Тү]ләкне[2] сарайына илтүңезләр!» – тиде.

Анда Түләк Чачлар ханга[3] әйде: «[Сез]дин[4] дәстүр булса, кызыңыз кабул кыйлса, // (*11а кәгазь*) атамыз йортына барсак булгайму?» – тиде. Анда Чачлар хан әйде: «Ир – туган йириндә, эт – ту[й]ган йириндә газиз торур» – тиде. «Атасы йортын сагунмаган ирне – ирме тиб булур?», – тиб дәстүр бирде. Йәнә әйде: «Йортыңызны, сарайыңызны, халкыңызны нитәк кыйлурсыз?» – тиде. Түләк әйде: «Падишаһы галәм, барчаңызның теләгене биргүче Тәңре Тәга[лә] торур». Чачлар хан падишаһ әйде: «Аллаһы Тәга[лә]гә тапшурдук!» – тиб, йибәрде. Пәриләр кызга илтеб табшуруб кайт[т]ылар.

Чачлар хан падишаһның шәһәре тигрәсендә ирде. Түләк килде. Кыз берлән күрүшеб, халь-әхваль сорашдылар. Аты, кошы йабугубдур. Йәнә үртәкәсүн күрде, йабугуб торур, күз йәше, борун сулары агубдур. Шул заман Түләк үртәкәсүн кулына алуб, гөлестанун көйләп, думбурасун уйнады, кыл[5] кубызун зарнаб, үртәкәсен алдына алуб уйнай[6] башлады ирсә, үртәкәсе төзәлеб, күрекләнде, котады. Түләк анда үртәкә бийүгәндә әйтүр ирде дыбсаб:

Ай, үртәкәм, үртәкәм,
Мөйүзләре куш тәкәм,
Мивәләре буш тәкәм.
Күзең йәше агыбдур,
Борун суың агыбдур,
Гарибсен сән, үртәкәм,
Уйнай күңлүм ачылсун,
Уйнай биргел, үртәкәм,
Бии[7] биргел, үртәкәм! – тиб, төрлүк уйунлар кыйлыб, халайыкның күңелүн ачуб, вә йән[ә кийек][8] кошларың // (*11б кәгазь*) күңелләрен алды вә кинә ачды, шад булдылар.

Бер кич Түләк йәсигы намазы кыйлгандин соң ике рәкәгъәт хаҗәт намазы кыйлды, «Исме әгъзам» догасын укуб, мөһиммә кәлтүрде, башыны сәҗдә[гә] куйды: «Илаһи, барча хаҗәтүмне рәва кыйлдуң, имди бер

---

1 Кульязмада: «токтаймыз» (توقتا يمز). Ул бер-берсенә охшашрак хәрефләрнең урыннарын бутап күчерү сәбәпле, «тоткаймыз» (توتقايمى) урынына ялгыш язылган.

2 Кульязманың бу урыны дефектлы.

3 Кульязмада бу сүз алдында «хан» сүзе язылган.

4 Кульязманың бу урыны дефектлы.

5 Кульязмада: «кул».

6 Кульязмада: «уйнады».

7 Кульязмада: «бийү».

8 Кульязманың бу урыны дефектлы.

теләгемне рәва кыйлсаң, ошпу тәхетүң, бәхетүм, халкум, милкүмне йанә ошпу Балкан тауымны ки[йе]к кошлары берлән, урманы-утуны берлән, ошпу бал дәрйа, сөт дәрйасы илә атам өйүнә урнатгыйл. Сәнең кодрәтең олуг торур. Мондагъ эшләрне кыйлмага сәңа асан торур, әй, Җәббарум!» – тиб, күзүндин йәшүн сачеб, Хак Тәга[лә]гә йалбарды, күб мөнаҗәт кыйлды.

Ул кичә йатды. Иртә таң намазы кыйлдылар. Андагъ карады, булат-сарайның тәрәзәсендин көн төшде. Андин борун сарай эченә көн төшә торган дәгел ирде. Тышкару чыкды, кыз караб күрде – бер олуг шәһәр йәнәшәсендә халкы, милке, тәхете, Балкан тауы, урманы, кошы, булат-сарай, бал дәрйасы, дүрт су дәрйасы – барчасы бәйлә килүбдүр. Олуг шәһәр йанында урнамыш. Кыз кайтуб, сарайга керде, Түләккә әйде: «Әй, йегет [белермү]сән[1], бу ни йиргә кәлдүк?» – тиде. Анда Түләк әйде: «Әй, җанум мәхәббәт, мәнем й[ир]үм-йортум ошпу шәһәр торур. Атам йиренә кәлдүк», // (*12а кәгазь*)[2] – тиде. Андин кыз торды, урынларын төзәтте, күшәгәсен корды, ултурды, һичнәрсә сүз әйтмәде.

Ул вакытда ул шәһәрнең падишаһы үлгән. Ул кичәдин борынгы көн ул шәһәрнең олуглары йыйылуб иттифакъ кыйлды, әйделәр: «таң[3] төшкәч шәһәргә һәркем ирсә килсә, падишаһлыкка күтәргәймез», – тиб. Олуг-кечек, алтмыш йәшәрдин алты йәшәргә тигрү киңәш булуб, кем килсә дә, падишаһлыкта күтәргәймез тиб, көтүб торур ирделәр. Ул кичә йатуб, иртә тордылар ирсә, күрделәр: ул шәһәргә йәнәшә бер олуг тагъ урнамыш. Ул тагъ тимүр берлә коршаган да йука[ры ка]лкуб[4] урнадмыш. Ул тәхетнең айаклары көмүшдин, башы гәүһәрдин. Ул тагъны алтун берлән коршаган. Тагъның башыны ак мөрәүвәрдин йапкан. Ул тагъның каршысында[5] бер пулат-сарай торур. Ул пулат-сарайның арт йаныңдин сөтдин бер дәрйа агуб барур. Ал йанындин балдин бер дәрйа агуб барур, түрт йанындин түрт дәрйа агуб барур. Бер Акбүзчә аргамак ул тагъның төбендә утлай йөрүр ирде. Бер ак шоңкар кош тагъ тигрәсендә очуб, шаңкулаб йөрүр ирде.

Барча олуг-кечек күрделәр: таң-гъәҗәйебкә калдылар. «Бу монда пулат-сарайның ийәсен Хак [Тәгал]ә[6] падишаһлыкга бирде булгай», – тиб, гайәт сәвенделәр. Андин соң олуг // (*12б кәгазь*) вәзирләр тордылар. Ул

[1] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

[2] Кулъязманың бу битендә тагын бер мәртәбә «кәлдүк» сүзе кабатлап язылган.

[3] Кулъязмада: «таңда».

[4] Бу урында күчерүче ике сүзне ялгыш кушып, «йукалкуб» дип язган. «Йукары калкуб» сүзтезмәсе 9а кәгазьдә дә бар.

[5] Кулъязмада: «кораушысында».

[6] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

пулат-сарайга бардылар. Ул сарайның ишегендә баруб тордылар. Саклаб торган берничә йегетләрне күрделәр. Мисле ай-көн тик һәркем боларуң күрекләрүн күрделәр ирсә, гакыллары[1] заил булды. Бер замандин соң гакылларын йыйуб алдылар. Анда ул сакчы йегетләргә әйделәр: «Бу сарай кемнең торур?» – тиделәр. Йәнә: «Бу тау кемнең, аты нә торур?», – тиб сурдылар ирсә, анда ул сарайның ишеген саклаб торган йегетләр әйделәр: «Бу сарай Чачлар хан падишаһның кийәве берлән кызының сарай[ы] торур. Вә йәнә тәхет-бәхет, милек, халык аларның торур. Вә йәнә бер тауны Балкан тау тиб әйтүрләр», – тиб әйделәр ирсә, иҗазәт теләп сарайга инделәр.

Ул халайык эчендә Түләкнең атасы Мыркас би[2] һәм бар ирде. Түләк күрешә баруб, атасыйга йитте, кочаклаб күрешде. Түләкнең барча әгъзалары калтураб төште, төсе үзгәрде. Кыз Түләкдин хәфийә берлән сурды: «Ул кеше берлән күрешмәкдә нә өчүн калтураб төштүң, төсең үзгәрде?» – тиде[3]. Анда Түләк кызга әйде: «Әй, җаным мәхәббәт, шул кеше мәнем атам торур, аның берлән сәвеб күрешмәк[ди]н[4] бу[ы]нларымның хәле китде. Аның берлән аның өчен карадум вә калтурадум», – тиде. Кыз белде: кайын а[та]сы[5] имеш[6].

Вә йәнә[7] // (*13а кәгазь*) Түләкнең анасының ике имчәгенә сөт тулуб кәлде. Түләк анасы берлән күрешкәндә анасының имчәгендин сөт атылуб чыкды. Түләкнең йөзенә чәчелде. Түләкнең гакылы китде, йыглай[8] йазуб калды. Түләкнең анасы, сөт сачелүб чыкканына ойалуб, тугъры карай алмады. Шайәт угылы икәнне анда ук белде, күңелендә әйтүр ирде: «Аһ, дәрига, мәнем бу ике имчәгем сөте галиб булгандин кем, йә им[мә]гә йә кем йөкүлекмү бала[9]», – тиб, йәшүрүн йыглады.

Кыз йәнә Түләкдин хәфийә берлән сурды: «Ул сө[т] сачелгән йөзеңә нә хатун торур?» – тиде. Андин Түләк әйде: «Әй, җан мәхәббәт йулдашым, шул карый хатун мәнем анам торур», – тиде. Кыз белде: кайын

---

[1] Кулъязманың бу урынында һәм моннан соң килә торган җөмләдә бу сүз «Гакыйльләре» рәвешендә язылган. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «гакыйль» сүзе «акыллы» дигән мәгънәне белдерә, ә бу очракта ул контекстка ярашмый.

[2] Кулъязмада бу сүз хаталы итеп, «си» (سى) дип язылган.

[3] Кулъязмада «тиде» сүзе ике мәртәбә язылган.

[4] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

[5] Кулъязманың бу урыны дефектлы.

[6] М.Ә. текстында бу урында өстәмә берничә җөмлә бар.

[7] Кулъязмада «Вә йәнә» сүзләре 12б кәгазьнең аскы өлешендәге кустодта күрсәтелүенә нисбәт ителеп язылды. Ләкин күчерүче тарафыннан 13а кәгазьнең өске өлешендә 8 юл чамасы урын язылмыйча, буш калдырылган булган. Соңрак кәгазь битенең әлеге буш урынына дога язып куелган.

[8] Кулъязмада: «йыглады».

[9] Бу җөмләнең ахыры аңлаешсыз.

ана имеш. Кыз торды, сандук // (*13б кәгазь*) ачды, ике тун чыкарды – алтун-көмүш, гәүһәр берлән мөрәссәгъ кыйлмыш – Түләккә бирде: «Берсен атаңа, берсен анаңа йаб!» – тиде. Түләк бер тунны анасына йабды вә бер тунны атасына йабды.

Халайык анда таң калдылар. Әйделәр: «Әй, солтан угылы, безнең ханымыз үлүб торур. Төнәге көн барчамыз хазер йыйылуб иттифакъ кыйлдук. Ханымыздин угыл-кыз калмады ханлыкта ултуртмага. Барчамыз әйдүк: «Таңдагы көн төш вакытына тигрү һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез», – тиде[к]. «Сезне безгә Тәңре Тәга[лә] кәлтүрде», – тиделәр. – «Имди сәне тәхеткә күтәргәймез!» – тиделәр. Анда Түләк: «Сезнең кабулуңыздин нә белгәймән», – тиде.

Шул заман барча халайык, бер булуб, Түләкне ха[н]лыкга күтәрделәр.

Түләк анда өч йыл хан булуб торды. Андагъ гадел булды. Барча вәйран йортлар төзәлде. Мәгәр куйлар берлән бүреләр бергә йөрегү тик булдылар моның гадел[л]еге бәрәкәтендә. Түләкне кем ирдүкен һич кеше белмәз ирде[1].

Анларга Түләк әйде: «Анларны нә кыйлмак кәрәк?» – тиде. Барча олуглар[2] әйделәр: «Анларны убал итмәк кәрәк» – тиделәр[3]. Андин соң анлар ишет[т]еләр ирсә, качуб орыш йортына керделәр[4].

Андин Түләк ул дәүләт эчендә ултуруб алты йыл ханлык сөрде. Андин соң // (*14а кәгазь*) Сусылу дөнйадин үткәндин соң Түләкнең угылыны ханлыкга күтәрделәр[5].

Түләкнең[6] угылы дөнйадин үткәндин соң Балкан тау, алтун тәхет, пулат-сарай, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, түрт су дәрйасы – барчасы бер кичдә гаиб булды, йук булды, һич кайда киткәнен адәм белмәде, хәйран улуб калдылар. Валлаһи әгъләм бис-саваб.

***Алынды:** Түләк китабы: дастан / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. Б. 20–40. – («Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап).*

---

1 М.Ә. текстында моннан соң бер бит чамасы текст бар.

2 Кулъязмада сүздәге беренче «л» (ләм) хәрефе кыска язылган.

3 М.Ә. текстында бу урында моннан соң берничә җөмлә бар.

4 Бу җөмлә М.Ә. текстында юк.

5 Бу урында ике җөмлә кушылып киткәнгә ошый. Чөнки М.Ә. текстында Сусылу үлгәч икенче елда Түләк вафат була. Аннан соң Түләкнең улын ханлыкка күтәрәләр.

6 Кулъязмада бу сүз ике мәртәбә язылган.

# ТҮЛӘК КИТАБЫ

(*Казан варианты. Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан табылып, фәнни әйләнешкә кертелгән*)

Хикәйәти алтынчы – Бачман хан берлә Җаждар хан. Алтынчы хикәйәтини тәвабигълары[1] берлә Түләк пәһлеван кыйссасы бәйан идәр.

Әүвәл заманда Йайык сулаган[2] Бачман хан дигән бер хан, аның бер Түләк исемле угълы бар ирди. Нигъмәти[3] мул, йорты киң иди. Алтмыш йегет хезмәтчи нүкәри бар ирди. Һәрберсин кызлар тик бизәнеп йөртер ирди. Алтмыш беренчиси Мирказый би угълы Түләк ирди. Түләкни үз хезмәтинә алды. Түләк бер йалгыз угыл иди.

Бачман хан даим кош чөйә йөрер иди. Һәр кайу йегетләрниң алтмыш башка кошлары бар иди. Түләкниң кошы Ак Йабалак иди. Кошы алмакда зерә дә һиммәтли иди. Ул алтмыш йегетниң кошлары һәр ни алса, Бачман ханга килтерип сынар ирдиләр. Хан ул йегетләргә сөйургап ун тәнкә алапа[4] бирер иди.

Көнләрдә бер көн Бачман хан ауга чыкты, һәрни кошы кийек очса-калса, Түләкниң Ак Йабалакы алды. Ул йулда ханның барлык алапасын Түләк алды.

Ул алтмыш йегет Түләкни көнләп, пычакка төшеп үлгү тик булдылар, һәр даим Түләк Хак Тәгалә коллыгындин хали булмаз[5] ирди, күнли пакь иди. Кич кунар булдылар. Түләкниң менгән атын Акбүзчә Йилйитмәс дийерләр ирди. Ул кичә кател кылып[6], алтмыш йегет Түләкниң Акбүзчә Йилйитмәс атының дүрт айакының йөрәк итедин үткәрә тимер кадак суктылар, йөрмәгә дәрманы булмасын дип. Түләк бу эшни һәргиз белмәс ирди. Түләк йокыда ирди. Төш эчиндә Хозыр галәйһи-с-сәлам килди. Түләккә «Исме әгъзам» догасыны үгрәтти, әйди: «И угълым, алтмыш йегет дошманлык кылып, атның дүрт тойагын үткәрә тимер кадак суктылар. «Исме әгъзам» укып, дәм бирсәң[7], кадаклары төшеп, атың айаклары саг булгай!» Йәнә әйди: «И угълым Түләк, һәркайчан сәңа мөшкел[8] эшләр төшәр булса, ушбу «Исме әгъзам» догасын укып сорасаң һәм килтерсәң, мөшкел эш асан[9] булгай», – тиди. Ул сәгать уйганды, хәзрәти Хозырны күрмәди, торды, барды, атын күрде, дүрт айакына дүрт тимер кадак сукмышлар. «Исме әгъзам»

---

1 Тәвабигълары – иярүчеләре.
2 Йайык сулаган – Җаек елгасы буенда яшәгән.
3 Нигъмәти – байлыгы.
4 Алапа – бүләк.
5 Хали булмаз – буш булмас.
6 Кател кылып – һәлак итеп.
7 Дәм бирсәң – өрсәң.
8 Мөшкел – читен.
9 Асан – ансат.

догасын укып дәм бирди исә, кадаклары төшди, айаклары уңалды[1], саг булды, һичкем ирсәгә бу серни әйтмәди. Иртә булды, атландылар. Түләк бер күлгә кушыл[2] карый китти. Бу алтмыш йегет таңга калып әйдиләр: «Бу Түләк ни гамәл берлә атының айагын уңалды?!» тидиләр. Әйдиләр: «Безләр бу Түләкни үлтермәйенчә бәһамез булмаз!» – тидиләр. «Имди безләр өч йегет баралым, ике йегет йөгәнининң ики йанындин алып, бер йегет Акбүзчәни камчыламак кирәк, ул сәгать Йилйитмәс алып очкай, агач йә тагъ-ташка сугып үлтергәй, аның хурлыгындин котылгаймыз!» – тидиләр.

Өчени хазир кылып[3] бардылар. Икеси Акбүзчәнең йөгәнин суйдылар, берси килеп камчылады. Йилйитмәс Акбүзчә Түләкни алып иллә очды кем, алты көн, йити төн туктамады. Йитинчи иртә, көн тугар вакытда бер олуг дәрйаның йаныга килеп туктадылар. Түләкнең һичкайда китканин белгән кеши булмады. Ул сәгать Түләк карап күрди, бер су пәрисиниң падишаһы бар ирди – Җаждар хан. Аның бер кызы бар ирди, бигайәт сахибе җәмал[4] ирди. Һәркем күрсә гыйшкындин җан биргү дик булыр ирди. Җаждар хан кызы ушбу Түләкнең аты туктаган йирдә һәр иртә килеп сачин тарар ирди. Үзини, йөзини йөз мең төрлик бизәкләр берлә бизәр ирди. Ул кыз ул йирдә сачини тарай ултырыр. Түләк, кызны күреп, атындин инди. Кыз тоймады, сачиниң озынлыкы алтмыш карыш буйы бар ирди. Сачин ики йаныга ачып, йөзиндин китәреп тарап торган вакты ирди. Түләк килеп кызга сәлам бирди. Кыз сачини йөзиндин китәреп торганы берлән әйләнип карады, Түләкниң йөзини күрди. Аһ кылып әйди: «Әгәр иңсәмни биреп торган вакытым булса иди, йөзимни сәңа кайда күргәзгәй идим», – тиди. Түләкниң йөзинә карады, гайәт дә зифа йегет торыр. Түләккә кыз андагъ гашыйк булды, сүз әйдер хали калмады. Ул йардин китәр дәрманы булмады. Күңлендин әйди: «Бу йегетни бер заман алдайын, шайәт ки котылып китәйен», – тип әйди. Кызның ул сәгать Түләкни күреп тәни калтырап торыр булды, һич кузгалыр дәрманы калмады. Түләк кызга анда кушак[5] әйди:

Инеп килдим атымдин
Имди сәниң үзиңә.
Сәлам бирдем бән сәңа
Ай тик күрекли йөзиңә.
Гашыйк булдым бән сәңа –
Нәзек зифа буйыңа,
Сүзең әйтчи, Сусылу!

[1] Уңалды – төзәлде.
[2] Кушыл – (кушил) талчыбыктан яки юкәдән үреп ясалган ау.
[3] Хазир кылып – хәстәрләнеп.
[4] Бигайәт сахибе җәмал – чиксез гүзәллек иясе.
[5] Кушак – җыр.

Кыз йәнә Түләккә каршы кушак әйди:
Мән усалның үзинә,
Гашыйк булма, бай угълы!
Алтын сыргам[1] бирәйен,
Бүләк булсын, бай угълы.
Безнең йирләр катыдыр,
Түзәлмассың, бай угълы!
Госса[2] булып үләрсин,
Кайтып киткел, бай угълы!
Андин Түләк кызга кушак әйди:
Сәфәр кылдык йөз кеши,
Йөгәним суйды өч кеши.
Атым килди йарышып,
Кулым килди карышып.
Атың-йулың[3] белмәсмен,
Атың әйтчи, Сусылу!
Андин йәнә кыз Түләккә кушак әйди:
Атың килсә йарышып,
Кулың килсә карышып,
Ат-йулыңны белмәзсин,
Атың әйтеп бирәйен,
Атың үзен beләсен:
Әрмезәлик кыламын,
Сары Мирказ угълысын,
Хәйба Түләк угълысын!
Атым-йулын белмәйси,
Кайан эзләп йөрәйси?!
Андин соң Түләк кызга әйди:
Бер дигәндә бил[4] алган,
Били салып суна[5] алган,
Канат какмай каз алган,
Агъзы канлигъ бүри алган,
Айагы сипкел төлки алган,
Муйны озын торна алган,
Арту кошны очырмаз
Ак Шонкардан йазайын,

---

[1] Сыргам – алкам.

[2] Госса – кайгылы-сагышлы.

[3] Атың-йулың – исемен, нәселең.

[4] Бил – калкулык.

[5] Суна – киек.

Суның кызы, Сусылу,
Сәнең берлә булайын,
Атың әйтчи, Сусылу!

Андин кыз Түләккә әйди:

Атым сорап нидәрсин?
Куш хәмаил[1], куш йөзек –
Менә сәңа бүләгим!
Безнең йирләр катыдыр,
Торалмазсын, Түләгем,
Госса булып үләрсин!
Мән дә сәнлик түгелмен,
Кайтып киткел, Түләгем!

Андин кызга Түләк әйди:

Артык кошны очырмаз
Шонкарымдин бизәйем,
Айлык йирдә бер баскан,
Йыллык йирдә бер баскан,
Кигәй йалы таралган,
Түрт айагы каралган,
Аргамакдин бизәйем!
Суның кызы Сусылу,
Сәнең берлә булайым!

Андин Түләккә кыз әйде:

Акча йөзем күрсәткән,
Арув сачим тараткан,
Толым буйым сылаткан,
Алтын тарак, ал көзги –
Мона сәңа бүләгим!
Шуны ал да йулың ал,
Кайтып киткел, Түләгем!
Мән дә сәнлек түгелмен,
Ышанмагыл, Түләгем!

Андин кызга Түләк әйди:

Ун ай төгәл күтәргән,
Уң утакдин йөгертелгән,
Аләли[2] кулда талчыктан,
Алтын кийездә ултырткан,
Төн йокысын өч бүлән,

[1] Куш хәмаил – куш хәситә.
[2] Аләли – хәләл.

Төнлә торып имезгән,
Айадан[1] каймак йидергән,
Ирү имчәкдин сөт биргән
Инәйдәнме[2] бизәйен!
Караңгига утырткан,
Алтын кийезгә ултырткан,
Айыры сакал үстерткән
Атадин мән бизәйем!
Суның кызы Сусылу,
Сәнең белән булайым!

Андин Түләккә кыз әйди:

Куш хәмаил, куш йөзек
Алмадың сән, Түләгем.
Алтын сыргам, ал йөзкем –
Йәнә бирдем бүләгем.
Бүләк биреп алмазсың,
Нидер мәндин теләгең?
Сүзең әйтчи, Түләгем!

Андин Түләк кызга әйди:

Куш хәмаил, куш йөзек –
Зифа буйың бизәкең.
Алтын тарак, ал көзге –
Мән нитәйен бүләгиң?
Бүләк маңа кирәкмәз,
Зиба буйың – теләгим!
Сүзем шулдыр, Сусылу.

Андин Түләккә кыз әйди:

Аптырапсын, бай угълы,
Тимтерәпсен, бай угълы.
Ана, аргы йагындин
Киләдер лә биш кеши –

Күрмәймисән, бай угълы?! – тип алдап каратып, кыз үзи суга чумды, качар булды. Түләк әйләнеп карады. Кыз суга чуммыш, алтмыш карыш саченең алты карышы суга кермәгән ирди. Түләк кызның сачини урап алып, беләгинә урай барып, судин килеп чыкканча йилкәсинә йитди. Бер фәлән ай-көн күренмәз йиргә чыкты. Пер пулат сарай торыр. Сарайның алды йанындан балдин бер дәрйа агып барыр. Йәнә сарайның арт йагындан сөтдин бер дәрйа агып барыр. Сарайның дүрт йанындан

[1] Айадан – аяктан, җамыяктан.
[2] Инәйдәнмен – анамнан.

дүрт олугъ дәрйа барыр, – Түләк күрди. Түләк кызның сачиннин айырылмаз ирди. Анда Түләккә кыз әйди: «Әй, йегет, имди сән мәним, мән сәниң булдык, сачимни йибәргел. Мән сарайга инәйен түшәк салайын, андин соң чыкып алайын», – тиди ирсә, анда Түләк кызга кушак әйде:

Алты көн дә йити төн
Атым алып килепдер.
Алдамачы, Сусылу,
Ай йөзиңдин бер эчәм,
Айрылмамдыр, Сусылу.

Андин Түләккә кыз кушак әйди:

Алты көн дә йити төн
Атың алып килепдер.
Ашыкмачы, бай угълы,
Урын-түшәк салайын.
Тарыкмачы, бай угълы.
Җөмлә буйым сәнеңдер,

Сабыр кылчы, бай угълы, – тип әйтди. Дәрхаль Түләк кызның сачини йибәрди. Кыз сарайга инди, ишегендин керди, сарайның ишекени беркетти. Ул пулат сарайның бийеклеки һавага чыкмыш ирди. Кыз һәргиз[1] чыкмаз булды. Өч көн, өч төн анда калды, дәрмани булмады, дүртинчи көн иртә намазы кылгандин соң ике рәкәгать хаҗәт намазы кылды, «Исме әгъзам» догасыны укып, башыны сәҗдәгә куйып, андаг әйди: «Илаһи, бу кызны һәм кавеми-халкыны һәм барча туарыны көн эсселеги берлә дәрмансыз кылтайсын!» – тиди. Ул сәгать догасы мөстәҗаб булды[2]. Өч көнтөн һава эсселек булды. Көн кайнар булды. Ул сарай алдындин акган бал дәрйасы, артындин акган сөт дәрйасы, дүрт тарафындин акган су дәрйасы кордылар, һичбер эчим су калмады, тәкатьсиз булдылар, барчасы йанып үлү тик булдылар. Ул кызның сарай тигрәсиндә ултырган кырык эвлик хезмәтчи нүкәрләри бар ирди. Барчасын кызның үзи тик зиба гына йунлык пәриләр ирди. Барчасы кыз сарайыга килдиләр, кычкырышдылар. Һәргиз сарайның ишекин-тәрәзәсин ачып бакмады һәм аваз бирмәди. Бу җәмәгать Түләкни карап күрдиләр: бигайәт сахибҗәмал йегет торыр, белдиләр, имди ни кылмак кирәк тийү, иттифак кылып[3] әйдиләр: «Кызның атасы Җаҗдар хан падишаһта бармак кирәк, бу әхвальни аңа аймак кирәк!» – тидиләр. Гакыйбәт[4] шаһга барып әйдиләр. Җаҗдар хан падишаһ кызына катыйг ачыйгланып берәкүни йибәрди, әйди: «Ни өчен алдаг

[1] Һәргиз – һич.
[2] Мөстәҗаб булды – кабул булды.
[3] Иттифак кылып – берләшеп.
[4] Гакыйбәт – соңында.

кылып, халыкны һәлак кыла торыр. Әүвәлиндә йегетни үзи кабул кылмаса ирди, адәмниң бу йиргә килергә ни дәрманы булгай? – тиди. – Үзи алып килепдер, имди халкыны ни өчен һәлак кыладыр? – тиб. – Ул адәмниң догасы мөстәҗаб охшайыр, барып кызымга әйтеңезләр, сарай ишегин ачсын, ул йегетни үз катына алсын, гыйзулар[1] кылып, яхшы догасын үтенсин», – тип, бунлары ул бер кәс[2] илә йибәрди.

Ул кемсәнә килеп, атасының сүзин айгач[3], кыз сарайның ишегини-тәрәзәсини ачды. Ул заман кызның тәнигә көн[4] төшди, күкрәкендин кереп, аркасындин чыкды. Кыз йанып үлгү тик булды. Пулат сарай ут кебек кайнар булды. Шул заман Түләк сарайга керди, кызны күрди, сачиндин урап алып, күтәреп пулат сарайның ишегинә сукды, йәнә кайтарып түринә орды, кызның гаклы китди.

Бер замандин соң кыз исен йыйып алды, күзин ачып карады. Түләкни күрди, әйди: «Әй, йегет, мән сәни сүмәзлекдин мондаг эши кылмадым. Мән зирдә[5], бер падишаһның кызымын, ушбу эшдә атамга билгелик булсын дип, мондагъ эш кылганмын. Морадым җәдаллыкдыр, – дип, йегетниң күңлисин алды вә йәнә әйди, – әй, йегет, мончага кадәри безниң эшемиз хәтәр иди, имди Хак Тәгаләгә шөкер, эшемиз күни булды[6]. – дип сүйүг-мәхәббәт берлә Түләкниң муйныга кулын салды. – Атамдин дәстүр[7] булып хәбәр килди, сәни җефетлеккә үз йаныма алмага», – тиди, вә йәнә Түләк, кызның бу сүзләрин ишетип, кызның бу гыйшкындин башын-җанын корбан кылу тик булды. Андагъ сүйүг-мәхәббәт берлә кыз муйныга кул салды, мәгәр дигәйсән күкдин ай-көн инеп бер йиргә кушылды. Мәхәббәт сүйүкликләри андагъ булды. Аллаһе Тәгаләдин гайре кем ирсә белмәгәй.

Анда кыз Түләккә әйди: «Имди, әй йегет, бәнем гайебемне кичрү биргел», – тиди. Каты гозерләр кылды, үтенди, әйди: «Әй, йегет, ушбу көн эсселегиндин хәлемез мөшкел булды. Имди Хак Тәгаләдин теләп, сез дога кылыңыз, безләр амин дисәк, Хак тәгалә, шайәт, гафу кылтай!» – тиди. «Михнәти безләрдин китәргәй!» – тип, кыз Түләкниң айакына төшип үтенди.

Түләк анда кызга әйди: «Әй, җан мәхәббәти, бер сәгать сабыр кылгыл, мән хәлвәт йиргә барып, Хак Тәгаләдин хаҗәт теләйен, сән һәм теләкдә булгыл!» – тиди. Сарайдин чыкып йир йөзинә инди, хәлвәт йир-

---

[1] Гыйзулар – олылаулар.

[2] Бер кос – бер кеше.

[3] Айгач – әйткәч.

[4] Көн – кояш.

[5] Зирдә – аскы якта (җир астында).

[6] Күни булды – дөрес булды.

[7] Дәстүр – рөхсәт.

гә барды, тәйәммем кылды, ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды. «Исме әгъзам» догасыны укыды, башыны сәҗдәгә куйып һәм әйди: «Илаһи, барча мөшкелләр сәңа асан торыр», – тип, Хак Тәгаләгә мөнәҗәт кылды, әйди: «Бу кавемни бу көн эсселекдин китәреп, сихәт бирмәк сәңа асан торыр!» – тип йалбарды ирсә, шул заман коңгыр салкын җил исеп, ул бал дәрйасы, йәнә ул сөт дәрйасы, йәнә ул дүрт су дәрйасы ага башладылар, тәмамысы иссез булып өч кичә-көндез йокладылар. Өч көндин соңра тордылар. Малларының өч өлешдин бер өлеши һәлак булмышлар көн эсселекедин. Андин соң Түләк кыз берлә көн-бикөн мәхәббәтләри зийадә[1] улып гыйш-гыйшрәттә улдылар.

Кыз әйди: «Әй йегет, мәңа дәстүр биргел[2], һәр иртә хәлвәтә[3] чыкып, сачем тарап, йөзим бизәп киләйен!» – тиди. Түләк кызга дәстүр бирди, һәр иртә хәлвәтә чыкып, сачин тарап, йөзин бизәп килер ирди. Бер көн Түләк кызга әйди: «Ни йиргә чыкып сачиң тарарсың?» – тиди. Кыз Түләккә әйди: «Ни йирдә мәнем сачимдин урап алдың, – тиде, – шул йирдә тарармын», – тиди.

Анда Түләк әйди: «Әй җан мәхәббәте, андагъ ирсә мәнем атым берлә кошымны күрмәзмисән?» – тиди.

Кыз әйди: «Сән бәңа гашыйк булмышда аймадыңмы, атымдин, кошымдин бизәрмен димәдеңме?»

Түләк әйди: «Ул көн аның кебек ирди, бу көн йәнә үзгәдер, күрер булсаң айгыл!» – тиди.

Анда кыз Түләккә әйди:

Атың аты Йилмайа,
Аңа китәр йул кайа?
Атың торыр абыгып,
Кошың торыр йабыгып,
Үзиң салып киткәнсән.
Такый нигә сорарсән?

Андин соң кызга Түләк әйди:

Атым торса ул йанда,
Мәним өчен зарыгып,
Айлык йиргә бер баскан
Дүрт айагы талыгып,
Йыллык йирни караган
Ике күзи карыгып,
Атым алып килергә

---

[1] Зийадә – артык.
[2] Дәстүр биргел – рөхсәт бир.
[3] Хәлвәт – аулак.

Дәрман итчи, Сусылу!
Халең йитсә атымны
Алып килчи, Сусылу!

Анда кыз Түләккә әйди:

Кошың бу йиргә безниң
Килеп йитмәз, бай угълы.
Бу хезмәтиң итмәгә
Халим йитмәз, бай угълы.
Хакдин теләк теләгил,
Ашыкмачы, бай угълы!
Хак теләгиңни бирер,
Тарыкмачы, бай угълы! – дип, кыз Түләккә әйдие. Түләк торды, йәсигъ намазыны кылды, андин соң ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды, «Исме әгъзам» догасыны укып, мәһим[1] килтердие, андин соң башын сәҗдәгә куйып әйдие: «Илаһи, барча агырлар сәңа асан торыр, атымны, кошымны ушбу йиргә килтерсәң кодрәтең бар. Мән бичараның халини һичкем белмәгәй, – тиди. – Рахманым[2], сәндин йөрдәм!» – тип, ул кичә кыз берлә йатды.

Иртә таң намазы улып ирде, намазга тордыкы вакытда Йилмайа кешнәп ирди, кош шангылтаб аваз бирди. Ул сәгать Түләк пулат сарайның тәрәзәсиндин карады, Акбүзчә аргамак килеп торыр, алтын ийәре өстиндә. Карады, Ак йабалакый ийәр кашында күрде. Ул сәгать Хак Тәгаләгә шөкерләр кылып, башый сәҗдәгә куйып әйди: «Бу мөлкәт, бу гыйнайәт[3] сәндин торыр», – тип, атының, кошының катына барды.

Аты, кошы Түләкни күрдиләр ирсә, ат селкенди, кош кагынды, борынгы тик симереп күрекләндиләр. Ул сәгать Хак Тәгалә ул пулат сарай каршында ут-үлән үстереп чыкарды. Һәр кичә ул туйгу тик йәшел үлән үсәр ирди. Вә йәнә ул кош тагъ тигрәсиндә очып йөреп, кош алып ашар ирди. Гакыйбәт[4] Түләк кыз мәхәббәти берлә гасәлдә[5] булып, йөзинә сап-сарыйгъ койылды. Үзи белмәз иди. Бер иртә кыз көзгесин түшәк өстинә куйып чыкты. Бу йегетниң булмышын үзин-үзи күрсен-белсен тип, кыз сачин тарамага чыгып китти.

Анда Түләк күрди кызның көзгесин – түшәк өстиндә калмыш. Көзгесини алды, ачып карады, үзиниң йөзини күрди: сарыйгъ койылмыш, гайәт усал булмыш иди. Аһ, дәрига, гасәлик[6] булып, үлем халигә киле-

---

[1] Мәһим – нык иман.
[2] Рахманым – Аллам.
[3] Гыйнайәт – ярдәм.
[4] Гакыйбәт – ахырында.
[5] Гасәлдә – авыруда, чирдә.
[6] Гасәлик – чир.

пмен, тиди. Торды, бер гөлстан дигән уйын йасады, бер думбра йасады, бер кыл кубыз йасады, вә йәнә бер үртәкә йасады. Ул үртәкәниң мөйезләрин[1] алтындин төзди, айакларын көмешдин төзди, ики күзләрин данә гәүһәрендин[2] төзди. Ул үртәкәни бу җиһан бизәкләри берлә бизәди. Торды, ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды. «Исме әгъзам» догасыны укыды, мәһим килтерди[3], башын сәҗдәгә куйып әйди: «Илаһи, барча хаҗәтләри кабул кылгучы Падишаһсын, сән ушбу төзгәним уйын сәнгатени миңа сона биргел[4]! Йа, Рабби, ушбу үртәкәгә җан биргел! Бары, Ходайга ушбу йиргә сониң хикмәтиң берлә грифтар[5] булдым, шайәт ки уйын кылсам, күнлим мәлүй[6] булмагай», – тип Хак Тәгаләгә йалбарды.

Шул сәгать Хак Тәгалә хаҗәтин рәва[7] кылып, уйын сәнгатини биреп, ул үртәкәгә җан багышлады. Хак Тәгаләгә шөкерләр кылып, уйнын уйнамага кул орды, гөлстанның, думбрасының, кыл кубызының кондакыны[8] бер кылды. Өчисин һәм бергә уйнар ирди. Үртәкәси бийер ирди, барча халкы җыйылды, сарай эчинә йыгъмаз[9] булдылар, һәр кичә-көндез Түләк катындиз[10] китмәз булдылар. Сарайдан тышкары чыкып ултырып, уйын йасадылар. Һәр көн тышта сарай кашында ултырып, мәҗлес корып, Түләкнең уйыныга гыйшык булып җийарындин[11], эчәрендин биздиләр, иртә торсалар, кич булганын белмәз ирдиләр. Түләкниң уйыныга гыйшык булып, һавадагы кошлар, йаландагы кийекләр барчасы монда йыйылып кичә-көндез китмәз булдылар: боланлар, күп ноугы[12] хайванлар, хәшәрәтләр – барчасы Түләкнең уйыныга гашыйк булып, йиймәк-эчмәкдин калдылар.

Көнләрдә бер көн Түләк күңелендин зарилык кылды: «Кәриме рәхим, бу монча пәриләр, кошлар, кийек хайван-хәшәрәтләр берлә сау булып тора-тора, йалкыз[13] җаның тузан басып, сурәтим азып, җенләр, пәри сурәтинә әверелер ирмешмен!» – тип зар-зар йыгълады. Ул кичә кыз катына йатды, такы кызга әйди: «Аһ дәрига, сәниң зиба сурәтеңә алданып, асылларымдин айырылдым, җенессез булдым, үләр булсам, кайда ата, кайда ана? Кайда җенесем адәм?» – тиди.

---

[1] Мөезләрен – мөгезләрен.

[2] Данә гәүһәрендин – бөртекле гәүһәрдән.

[3] Мәһим килтерде – таза, нык имен күрсәтте.

[4] Сона биргел – иңдер.

[5] Грифтар – дучар.

[6] Мәлүл – кайгылы.

[7] Рәва – яраклы.

[8] Кондакыны төбен.

[9] Йыгъмаз – сыймас.

[10] Катындин – каршыннан.

[11] Җийарындин – ашаудан.

[12] Нәугы – төрле.

[13] Йалкыз – ялгыз.

Анда кыз әйди: «Әй йегет, гаклың киттими? Бу гыйнайәт бу дәүләт кемдин тиди, белмәзмисән? Бу дәүләткә тигеркүчи падишаһлар падишаһы – Тәңре Тәгаләни оныттыңмы? – тиди. – Айырылганларны куштырмак аңа асан торыр», – дийү күп үгет кылды. Бу сүзләр берлә йегетнең күңлин авытдый[1].

Йатдылар. Иртә намазыга тордылар ирсә, күрдиләр бер алтын тәхет сарай кашында корылмыш. Тәхетнең айаклары көмешдин төзелмеш. Тәхетнең башы гәүһәрдин төзелмеш. Ул тәхетнең өстинә бер олугъ бийек, башы һавага чыкган тау урнашмыш, сикез кыры, дүрт тарафы тимер берлә тайаган[2], тәхетдин йукары калкып, сайә[3] кыйлып торыр. Ул тау алтын берлә кушаган[4], башыны ак мәрвәр[5] берлә йапкан. Түрт йаны агач үскән чыбыклык урман булган. Барча боланлар, коланлар, айу-бүри, төлкиләр, кош-кортлар анда урнамышлар[6]. Бу эшләрни күреп, кыз берлә Түләк, Хак Тәгаләгә шөкерләр кылып. Түләк килеп ул алтын тәхет үзә[7] менип ултырды. Уйынлар кулына алып, дибрәб, кубсаб, сарнаб уйный башлады. Андагъ дибрәб әйтер ирди:

Гөлстаным көйләсин,
Думбрам бәнем сөйләсин,
Кыл кубызым сарнасын,
Үртәкәм хуш уйнасын,
Күрмәгә килгән халайык
Үз-үзини белмәсин!
Уйнай биргел, үртәкәм!
Бии биргел, үртәкәм!
Алтын тәхет урнаткан,
Көмешдин айак йараткан,
Тәхет-бәхет төзәткән
Хак Тәгалә кодрәте, –
Шөкер кирәк, Сусылу!

Анда ул җыйылган халайыклар әйдиләр: «Бу кемнең тауы торыр? Тау ни тигән тау булыр?» Анда Түләк айларга дыбсаб әйди:

Мәнем тауым Балкан тау,
Башы һавага чыкган тау,
Тимер берлә тайаган,

[1] Авытдый – юатты.
[2] Тайаган – коршаган.
[3] Сайә – күләгә.
[4] Кушаган – коршаган.
[5] Мәрвәр – мәрмәр.
[6] Урнамышлар – урнашканлар.
[7] Тәхет үзә – тәхеткә.

Алтын берлә коршаган,
Ак мәрмәрдән йапкан тау! – тип дыбсаган авазын ишетип, кийек-кошлар, хайван-хәшәрәтләр йыйылып килеп, башларын түбән салып дыңлар ирдиләр. Анда Түләк анларны күреп дыбсаб әйди:

Утлар уты май татыр, –
Болан сүвгән Балкантау;
Эчә суы бал татыр, –
Колан сүвгән Балкантау!
Йатыр йири йакма алтын, –
Йылан сүвгән Балкан тау!
Тулагы күп, йири киң, –
Төлки сүвгән Балкан тау!
Җийим җимеши төкәнмәз –
Айу сүвгән Балкан тау!
Кайаларый кайырчак, –
Карсак сүвгән Балкан тау!
Күл куйысы камышлык, –
Кабан сүвгән Балкан тау!
Йири салкын, йимши күп, –
Кошлар сүвгән Балкан тау!
Су дәрйасы су алмаз, –
Сывыр сүвгән Балкан тау!
Башымызның өстиндә
Сайә булган Балкан тау! – тип уйнар ирди. Ул хәбәрләр, ул эшләр кызның атасы Җаждар ханга ишетелди, Җаждар хан падишаһ кызындин йыраклыкы йити төнлик, йити көнлик йир ирди. Түләкни һәм уйынларыны күрмәгә андагъ гашыйк булды. Йимәкдин, эчмәкдин бизди, дийүләрни, пәриләрни алмага йибәрди. Түләкни пәриләр алып китәр булдылар. Анда кыз Түләккә әйди: «Әй йегет, ушбу үртәкәңи алып бармагыл, ушбу газиз сурәтни җанлыгъ кылып Хак Тәгалә сәңа бирмеш торыр. Нагяһ[1] атам алып калмасын. Мондагъ нәрсә аңа тансык торыр, үзиңә бер үртәкә сурәти йасап алып баргыл!» – тиди.

Түләк аның сүзин хуш күрди, үртәкә сурәтини йасады. Ул җанлыгъ үртәкәсин кыз йанына куйып китди. Җаждар хан падишаһга йакын йитә килди, дыбсаб-кубсаб уйнай башлады. Түләкниң уйын уйнаган авазын ишетип, уйынга гашыйк булып, шәһәргә барчасы каршы чыктылар. Җаждар хан падишаһ үзи уйын авазын гашыйк булып сабыр итәлмәди, бер таз колны үз урныга тәхет үзә[2] ултыртып, үзинә каршы килеп тыңлар ирди.

---

[1] Нагяһ – көтмәгәндә.

[2] Тәхет үзә – тәхет өстенә.

Кыз Түләккә атасының сыйфатын әйткән иди. Анда Түләк карады, ушбу килгән Җаждар хан падишаһ үзи торыр. Анда дыбсаб Түләк әйди:

Гөлстаным көйләйдер, –
Думбрам мәним сөйләйдер.
Кыл кубызым сарнайдыр,
Үртәкәм хуш уйнайдыр!
Тәхетдә ултырган Җаждар хан
Тәхетдин төшеп тыңлайдыр,
Ишектәге таз чура
Тәхетдә ултырып аңлайдыр!

Андин Җаждар хан әйди: «Бу Түләк бизәк торыр кеше булмак кирәк, мәни мондагъ белди», – тиди. Рәван кайтып[1], тәхтинә ултырды. Түләк килеп йитди, падишаһ сарайына төшди. Кырык көн-төн йиймәк-эчмәк берлә, уйын-тамаша берлә калдылар. Андин соң Түләк кызны һәм Балкан тауны, урыны-йирини гайәт сагынды.

Җаждар хан падишаһга дыбсаб-кубсаб андагъ әйди:

Балкан тауым монда йук,
Ак кийекем монда йук,
Ултырып уйын төзәргә
Алтын тәхтем монда йук!
Җөмлә буйы җопарлык[2]
Зиба йарым монда йук, – тип Түләк әйди. Җаждар хан падишаһ дийүләргә, пәриләргә бойырды: «Барыңлар, Түләкниң Балкан тауыны монда алып килеңләр!» – тип йибәрди. Дийүләр, пәриләр бардылар. Хак Тәгалә Балкан тауыны айларга күргәзмәди, йир берлә төп-төз кылды. Дийүләр, пәриләр ул пулат сарай кашында андагъ тауны тапмадылар. Ул сарай йакынындагы олугъ тауларны бер-бери үзә[3] куйдылар, тимер берлә коршадылар, күтәреп алып килделәр. Анда Түләк дийүләр, пәриләр тауны алып килә торганын күрип дыбсаб-кубсаб әйди:

Мәнем тауым ул түгел,
Алтын тәхтем ул түгел,
Тауны тауга охшатып
Алып килә торырлар, – тип Түләк ирсә, Җаждар хан каршы дыбсаб әйди:

Тауны тауга охшатып,
Тимер берлә коршатып,

[1] Рәван кайтып – кире кайтып.
[2] Җопарлык – җофар кебек.
[3] Бер-бери үзә – берсе өстенә берсен.

Торгын монда Түләким
Балкан тауга охшатып.

Җаждар хан айгач, аңар каршы Түләк дыбсаб әйди:

Бары барлы бийек тау,
Барындин бийек Балкан тау:
Сублаб какган казыкдай
Сувыры күп Балкан тау;
Майлап салган кайышдай
Йыланы күп Балкан тау;
Айрыр тойак, шеш мөйез
Боланы күп Балкан тау;
Алпан-тулпан атлаган
Айуы күп Балкан тау;
Иксә йоны санчелгән,
Башы түбән ийелгән
Кабаны күп Балкан тау;
Кыз угландай сузылган
Төлкиси күп Балкан тау;
Күп йәшәгән карый[1] тик
Карсагы[2] күп Балкан тау;
Ойа итеп йири хуш
Кошлары күп Балкан тау;
Йомры тойак, кыл койрык
Коланы күп Балкан тау;
Дәстүр бирсә Җаждар хан,
Күргем микән Балкан тау! – тип Түләк әйди ирсә, Җаждар хан падишаһ әйди:

«Китәрмен тикәнни ничәгә тикү тотармыз?!» – тиди. Пәриләргә әмер кылды: «Барың! Түләкне сарайына илтеп куйыңыз!» «Кабул кылса, атамыз йортына барсак булгаймы?» – тиди.

Анда Җаждар хан әйди: «Ир туган йирендә, эт туйган йирендә газиз торыр. Атасы йортын сагынган ирни ирме дип булыр», – дийү дәстүр[3] бирди, йәнә әйдие: «Йортыңызны, сарайыңызны, халкыңызны, малыңызны нитәк кылырсыз?» – тиди.

Анда Түләк әйди: «Әй падишаһ, барча галәмниң теләгин бирүчи Тәңре Тәгалә торыр», – тиди. Җаждар хан падишаһ әйди: «Сезне Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым!» – тип йибәрди.

---

[1] Карый – карт.

[2] Карсак – төлкенең аерым төре.

[3] Дәстүр – рөхсәт.

Пәриләр кызга тапшырып кайтдылар. Җаждар хан падишаһның шәһәри диңгез арасында ирди. Түләк килди, кыз берлә күрешди, халь-әхваль сорашдылар. Аты, кошы йамансылап йабыгып дора. Үртәкәсин күрди, йабыгыпдыр, күз йәшләре, борын сулары агып торыр. Шул заман Түләк, гөлстанын көйләп, думбрасыны уйнай, кыл кубызын сарнаб, үртәкәсин алдыга алып уйната башлады. Үртәкәси төзәлеп күрекләнди. Түләк анда үртәкәси бийегәндә әйтер ирде:

Әй, үртәкәм, үртәкәм,
Мөйезләрең куш тәкәм,
Буынларың буш тәкәм.
Күзең йәши агыпдыр,
Гарибсәб сән, үртәкәм,
Йәтимсәб сән, үртәкәм,
Уйнап күңлиң ачылсын,
Тугъ тузаның сачилсен,
Уйнай биргел, үртәкәм! – тип, күп төрлек уйынлар кылып, халайыкның күңелләрин ачып, һәм кийек кошларның күңлени ачылды, шат булдылар.

Бу кичә Түләк йасигы намазы кылгандин соң, ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды, «Исме әгъзам» догасын укып мәхкәм[1] китерди, башын сәҗдәгә куйып әйди: «Илаһи, барча хаҗәтне рәва кылдың, имди бер теләкемни рәва кылсаң, ушбу сарай, тәхет-бәхетемни сән рәхманым[2] төзип бирдең, сән җәббарга[3] шөкер имди. Ушбу тәхет-бәхет халикъ[4] милкемез, вә йәнә ушбу Балкан тауны кийек кошы берлә, урманы-утлавы берлә, вә йәнә ушбу бал, сөт, су дәрйалары берлә атам шәһәринә урнатсаң[5], кодрәтиң бар торыр. Мондагъ кылмак сәңа асан торыр, әй җәббарым», – тип күзендин йәшин сачти, Хак Тәгаләгә йалбарып күп мөнаҗат[6] кылды. Ул кичә йатды, иртә таң намазы кылдылар. Анда кыз карады, пулат сарай тәрәзәсендин көн төшди. Андин борын сарай эчинә көн төшә торды дәгел иди, тышкару чыкды. Тиз карап күрди бер олугъ шәһәр йәнәшәсиндә халкы, малик[7] тәхти-бәхти, Балкан тау, урманы, кийек-кошы, пулат-сарайы, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, су дәрйасы – барчасы буйлә килеп бер олугъ шәһәр йанында урыннамыш.

Кыз, кайтып, сарайга керди, Түләккә әйди: «Әй, йегет, сән белермисән, бу ни йиргә килдиң?» – тиди. Анда Түләк әйди: «Әй, җаным могътәбәр,

---

[1] Мәхкәм – нык, таза, биредә: иман ныклыгы.

[2] Рәхманым – Аллам.

[3] Җәббарга – бик кочлегә.

[4] Халикъ – бар кылучы.

[5] Урнатсаң – урынлатсан, урнаштырсаң.

[6] Мөнаҗат – Аллага мактау.

[7] Малик – ия.

мәним йирем-йортым ушбу шәһәр торыр. Атам йортына килдик», – тиди. Андин кыз торды, урынларын төзди, күшәкәсин корды[1], ултырды, һичнәрсә сүз әйтмәди. Ул вакытта ул шәһәрниң падишаһы үлгән ирди. Улдин борынгысы көн ул шәһәрниң олугълары йыйылып иттифак кылган идиләр: таңдагы көн бу шәһәргә төш вакытына тикрү һәркем килсә, падишаһлыкка күтәргәймез тип. Олугъ-кечек, алтмыш йәшдин алты йәшкә тикрү бер киңәштә булып, кем килсә дә падишаһлыкка күтәргәймез тип, көтеп торыр ирдиләр. Ул кичә йатып, иртә тордылар ирсә, күрдиләр, ул шәһәргә йәнәшә бер олугъ тау урыннамыш. Ул тау тимер эстиналары берлә йукары калкува урыннамыш. Ул тауның аегында бер алтын тәхет урыннамыш. Ул тәхетниң айаклары көмешдин, башы гәүһәрдин. Ул тауны алтын берлә коршаган, тугының башыны ак мәрмәрдин йапкан. Ул тауның каршысында бер пулат сарайның алдындин бардыр бер дәрйасы – балдин агып барыр, сарайның артындин сөтдин бер дәрйа агып барыр. Түрт тарафындин судин торадыр, агып барыр. Бер акбүз аргамак ул тауның төбиндә утларый йөрир. Бер ак шоңкар кошы, миңезлик кош, тау тигрәсиндә очып шаңгылтай йөрир, барча олугъ-кечек күрдиләр, таң-гаҗәйеп калдылар: бу, мондагъ пулат сарай, җиһанда һичкем күрмеши йукдыр, тидиләр: «Мәгәр безләрә пулат сарайның ийәсин Хак Тәгалә падишаһлыкка йибәрди булгай», – тип гайәт сүвенештиләр.

Андин олугъ вәзирләр вә кәбирләр[2] ни тордылар. Ул пулат-сарайга бардылар. Ул сарайның ишекиндә саклап торган берничә йегетләрни күрдиләр. Мисле ай берлән көн булгай боларның күрекләрин күрдиләр ирсә, гакыллары китти, заил булды[3].

Бер замандин соң гакылларын йыйып алдылар. Анда ул сакчы йегетләргә әйдиләр: «Бу сарай кемниң торыр, вә йәнә бу халикъ милек кемниң торыр? – тидиләр. – Вә йәнә бу тауның аты ни тип әйтерләр», – тип сорадылар ирсә, анда, ул сарай ишекиндә саклап торган йегетләр әйдиләр: «Бу сарай Җаждар хан падишаһның кийәве берлә кызының сарайы торыр, йәнә бу тәхет – бәхет халикъ милек аларның торыр, вә йәнә бу тауны Балкан тау дип әйтерләр,» – ирсә, иҗазәт[4] теләп эчкәре сарайга иңдиләр.

Ул халайык эчиндә Түләкнең атасы Мирказый би һәм бергә вар ирди. Түләк берлә һәм катындагы кешиләр күрешә башладылар. Анда күрешә килеп, Түләк кочаклашып күрдиләр: Түләкниң барча буынлары калтырап, төси үзгәрди, гяһ[5] кызарды, гяһ уңарды[6].

1 Күшәкәсен корды – кабул итү бүлмәсен тәртипкә китерде.
2 Кәбирләр – олылар.
3 Заил булды – бетте.
4 Иҗазәт – рөхсәт.
5 Гяһ – бер вакыт.
6 Уңарды – төссезләнде.

Анда кыз Түләкдин хәфия[1] сорады: «Ул кеши берлә күрешмәкдә ни өчен калтырап, төсиң үз булды?» – тиди. Анда Түләк кызга әйди: «Әй, җан мәхәббәтем, ул кеши минем атам торыр, аның берлә сәйер күрешмәкдин буынларымның зали китди, шуның өчен калтырадым», – тиди. Кыз белди: кайын атасы торыр.

Андин олугъ биләрнең, вә такый олугъ вәзирләрнең, олугъ кәбирләрнең хатынларыга хәбәр кылдылар: «Ушбу падишаһның кызына күрешергә килсинләр!» – тип. Барча олугъларның хатынлары килди. Түләк берлә һәм кызы берлә күрешдиләр. Ул би хатынлары эчиндә Түләкнең анасы һәм бар ирди. Анасының ике имчәкинә сөт тулып килди. Түләк инәси берлә күрешмәкдә, инәсиниң ике имчәкендин сөт атылып чыкды. Түләкниң йөзинә сачелди һәм агызына керди. Түләк йотды: бал һәм шикәрдин татлыйгъ ирди. Түләкниң сөт ләззәтендин, мәҗлес хушлыкыдан гаклы китеп йыглай йазды. Инәси, сөти сачелгәнгә ойалып, тугъры карый алмады, шайәт угълы иркәнин андагук белгәй ирди, күңлиндә әйтер ирди: «Аһ дәрига, мәним бу ике имчәкимә сөт тулды, булган балага йарику, бу кеми булды иркән?» – тип йәшерин йыгълар ирди.

Кыз йәнә Түләкдин хәфия сорады: «Ул сөти йөзиңә сачилган ни хатын ирди?» – тиди. Анда Түләк кызга әйди: «Әй, җаным йулдашы, шул карый хатын мәним инәм торыр!» Кыз белди: кайын анасы торыр.

Кыз торды, сандык ачды, ики тун алды, алтын-көмеш, гәүһәр-җәүһәр берлә мөрәссагъ кыйлмыш, Түләккә бирди: «Бересин атаңа, бересин анаңа йап», – тиди. Түләк бер тунны атасына, бер тунны анасына йапды. Халайык анда таңга калдылар, әмма Түләкни ата-анасы әгълә[2] белмәйләр, гайреләри[3] һәмишә[4] белмәйләр. Мәгәр йегет илән кыз үзләри генә беләләр. Танышу соңында ул шәһәр халкы йәгъни аңа әйдиләр: «Әй, солтан угълы, безләрниң – улып ханымыз үлди торыр. Түнәкөн[5] барчамыз йыйылып иттифак кылдык, ханымыздин угыл-кыз калмады, ханлыкга ултыртмага барчамыз әйдек: «Таңдагы көн төш вакытында тикрү[6] һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез», – тидек.

Имди, сезни безгә Тәңре Тәгалә килтерди торыр, безни сәңа Тәңре Тәгалә бирди торыр, кил имди, сәни тәхеткә күтәрәле!» – тидиләр. Анда Түләк әйди: «Сез кабул кылыр булсаңыз, мән риза!» – тиди. Шул заман барча халайыклар, иттифак улып, Түләкни ханлыкга күтәрдиләр.

---

1 Хәфия – серне.

2 Әгъла – бик яхшы.

3 Гайреләри – башкалары.

4 Һәмишә – һаман.

5 Түнәкөн – кичә.

6 Тикрү – кадәр, тикле.

Өч йыл хан булып ултырды. Андагъ гадел хан кылды, барча вәйран йортлар төзәлди, мәгәр куйлар-бүриләр бергә йөреки тик булды. Моның тик гаделлек бәрәкәтиндә һәм шул вакыйгача Түләкни кем ирдикин һичбер кеше белмәз иди. Әмма һәр даим Түләкниң инәси әйтер ирди: «Ушбу хан безниң гаиб булган угълымызга охшар!» – тип әйтер ирди. Мирказый би әйтер ирди: «Әй хатын, гаиб булган угълымызга мондагъ ханлык кайда булыр!» – тип әйтер ирди.

Түләк, җомга көн, Балкан тауга чыкып, алтын тәхеткә ултырып, барча халайыкны җыйып, йимәк-эчмәк биреп, гөлстанын көйләп, думбрасын уйнап, кыл кубызын сарнаб, үртәкәси бийеп, аның гыйшкындин корбан кылгу тик булып торыр ирдиләр.

Бер көн Балкан тауга чыкып йийып-эчип, уйын-тамашалар берлә ултырыр ирдиләр. Олугъ биләр, вәзирләр иттифак кылып сорадылар: «Шаһи җиһан, сән безләргә хан булдың, без сәңа халык илә көтү булдык. Өч йыл булды сорарга кыймадык, имди безләр сорармыз, кемниң нәслисән, үзиң кемниң угълысән, атыңыз ни торыр?» – тип сорадылар. Анда Түләк әйди: «Мән сезниң үз нәселеңездинмен вә йәнә үз угълыңызмын!» – тиди. Анлар әйдиләр: «Безнең барча угълымыз үз катымызда торыр, мәгәр күп йыллар булды, бер угълымыз гаиб булып[1] торыр, сәниң атың кемдер?» – тип сорадылар. Анда Түләк әйди: «Мәним атым – Түләк торыр, атам аты – Мирказый би торыр!» Сорадылар, әйди ирсә, барча халайык кочаклашып күрешдиләр, халь-әхваль сорашдылар. Түләкниң атасы берлә анасы, Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр кылып, фәкыйрьләргә күп маллар өләштерди. Алар анда Түләкдин сорадылар ни халь гаиб булып киткәнин, йәнә бу алтмыш йегет, атының йөгәнин суйып йибәргәнин, йити кичә-көндез аты алып киткәнин, атының айакына тимер кадак сукганын – барча әйди ирсә, барча биләр, вәзирләр әйдиләр: «Бу алтмыш кеши әүвәл сәңа көнләшер, дошман булып, андагъ эш кылдылар. Имди бу көн сән икәнин белдиләр, андин йаманрак дошман булыр», – тидиләр.

Анларга Түләк әйди: «Анларны ни кылмак кирәк?» – тиди.

Барча олугълар әйдиләр: «Анларны апал итеп измәк кирәк», – тидиләр. Андин соң анларны илләри берлә апал итеп, ул йыйылган халайыклар берлә иттифак әйләп изә башладылар. Әүвәл ун өйлесен Иләчте тип атага әйләдиләр, икенчи ун урыс йорты тип Эчтүкәгә, өченчи ун чит халык тип Чиркәскә әйдиләр, гүртенчи унын кыр халкы тип Кыргызга, бишенчи унын башка йорт тип Наҗарга, алтынчы унын Каныш йорты тип Кайага әйдә ирдиләр.

Андин соң Түләк, ул дәүләт эчиндә ултырып, утыз алты йыл ханлык сөрди.

---

[1] Гаиб булган – юкка чыккан.

Андин соң Сусылу дөнйадин үтди. Икенчи йыл Түләк үзи дөнйадин үтди. Түләк дөнйадин үткәндин соң Түләкниң угълы Габдулланы ханлыкга күтәрдиләр. Ике йыл хан булып торды. Андин соң Түләк угълы Габдулла дөнйадин үтди. Түләк угълы дөнйадин үткәндин соң, Балкан тау, алтын тәхет, пулат сарай, бал дәрйасы, сөт вә дәрйасы, дүрт тарафдин акган су дәрйасы, бергә килгән халкы-милке – барча бер кичдә гаиб булып, йук булды, һәм һич адәм кайда киткәнин белмәдиләр. Тәмам.

*Дастан текстын журнал өчен әзерләүче – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИның баш фәнни хезмәткәре, доцент Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова.*

## ЗАЯТҮЛӘК БЕРЛӘ СУСЫЛУ
(*Мәҗит Гафури варианты*)

### *Сүз башы*

Буннан бер ел элек мәшһүр бер затның гаиләләре берлә Бәләбәй өязендәге башкортлар арасына, Ачылы күл[1] буена барган идем. Анда барудан мәкъсудым, бер җәһәттән, тәнәззеһ вә истирахәт, матур күл буены күрмәк, икенче җәһәттән, Ачылы күл тирәсендәге күптән бирле үзләренең башкортлыкларын, гореф-гадәтләрен саклап килгән башкортларны күрү, иске, моңлы, дәртле милли көйләрене ишетү иде. Вакыйган, алар бу көнгә чаклы иске гореф-гадәтләрен, җыр-көйләрен чын көенчә саклап килә алганнар. Хәтта тирмә белән күчмә хәлендә йөрүләрне дә ун-унбиш ел мокаддәм генә ташлаганнар.

Без, Ачылы күл буена килеп төшкәч тә, тәңкә кебек күл буена, ямь-яшел үлән өстенә чатырларны кордык. Күлдән ерак түгел Канлы, Чапай[2] дигән авыллардан курайчы һәм җырчылар китерттек.

Мин, тычкан көтеп утырган песи кеби, курай уйнаган вә җырлаган башкортларның авызларына карап, башка нәрсәләрене тәмам онытып, курайга кушылган моңлы тавышны чын күңелем берлә тыңлый идем.

Башкортларым – «Кара юрга», «Өйдерәк», «Таш тугай», «Ашказар», «Тәфкиләү», «Сакмар», «Көрән юрга», «Кантуннар» дигән көйләрне берәм-берәм сыздыралар иде.

Күл буйлап яңрап киткән тавышлары мине рухани ләззәт илә ләззәтләндерә, фәкать бу матур көйләрнең башкортлар арасында тиздән югалып, алар урынына татар такмаклары урынлашуы хәтеремә килеп, мине бераз хәсрәтләндерә иде.

Алар хәл җыйган вакытта, көйләрнең исемнәрене, ни сәбәпле чыгарганлыкларыны сөйләтә идем.

Бервакытта «Заятүләк» көене уйнап җырлый башладылар. Моны уйнап беткәнче чак чыдап тордым. Беткәч тә: «Заятүләк кем соң ул?» – дидем.

Янымда утырган башкорт агай тынын җыеп, авызын ипләп сөйләй башлады. Ул, моны сөйләгән вакытта ихлас белән кулыны селтәп, сөйләгән сүзенең дөреслегенә тәмам игътикад иткәнене хәрәкәтләре берлә белдерә иде.

Кулы белән күлнең теге ягына ишарә кыйлып: «Ана анда Заятүләк ташы бар, һәм моннан унбиш чакрым җирдә, ана, күгәреп күренгән Бал-

---

[1] Ачылы күл – хәзер Башкортстан АССРның Дәүләкән районы территориясендә, мәйданы 18 кв. км. М. Гафури 1909 елның июле тирәсендә хәзерге Бүздәк районындагы Килем авылына барып бер ай чамасы яши. «Заятүләк белән Сусылу» дастанында искә алынган җирләр белән танышу шул вакытта булган булса кирәк.

[2] Канлы, Чапай – Канлы Төркәй авылы Башкортстан АССРның Бүздәк районына, Чапай авылы Дәүләкән районына керә.

кан тавында[1], аның кабере бар, бу күлнең уртасы бик тирән-фәлән, – дия сөйләп бетергәч, – «Заятүләк» дигән китап та бар», – диде.

Мин элек бу китапның Уфада мәшһүр бер зат тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, үзе вафат улуы сәбәпле бастырылмый калганын ишеткән идем. Монда да моның барлыгын ишеткәч, аны шундук эзләп таптым. Кулыма төшкән мөтәгаддид нөсхәләрне бергә китереп караганда, китапның әһәмияте мин уйлаганча булмаса да, түбәндәге сәбәпләр өчен язып алып, тугъры килсә, табгы кыйлдырырмын дип уйладым.

Сәбәпләр – «Заятүләк» көенең матур моңлы, бик иске булуы, бунның вакыйгасы хыялый булса да, башкортларның игътикадына чын төсле булып урынлашуы, монда язылган Заятүләкнең шул мин янында утырган Ачылы күл янында йөргәнлеге, күлнең күз алдымда ялтырап ятуы вә башкалардыр.

Мин монда уздырган өч-дүрт көн гомеремне гел башкортларның иске тормышларыны сөйләтү, курай уйнатып моңлы көйләрене көйләтү илә уздырдым. Алар иске тормышларын, кантуннар заманын[2] сөйләп, шуңа мөнасиб җырларын җырлап, көйләп җибәрсәләр, аларның иске тормышлары күз алдына килгән төсле булып, чыннан күңелне нечкәртә иде. Яңа тормышка өйрәнмәгән, эшне кай җиреннән башлап алып китәргә белмәгән кешенең үткән гомерене сагынып сөйләве хәкыйкатән аны кызгандырадыр.

Башкортларның бу көнге хәленә караган вакытта, аларның көйләрен, җырларын вә башка әсәрләрен югалтмый алып калырга тырышу кирәк иде. Ләкин аларның тоз кеби эреп бетүенә безгә күз салырга бу көнге тәрбиямез, һиммәт вә гайрәтемез җитми шул.

*М.Г., 1910 ел, 15 февраль.*

## ЗАЯТҮЛӘК БЕРЛӘ СУСЫЛУ

Буннан күп заманнар элек кыргыз[*] илендә «Ун сан уймат»[3] дигән йортта Сары Моркас[4] исемле бер хан бар иде.

Кул астына караган иле-халкы күп, шөһрәте шәп, байлыгы тәмам җирендә булганның өстенә, төрле мәгыйшәткә, уен-көлкегә һәвәсле иде. Бу

---

[1] Балкан тавы – Ачылы күлдән 20–30 чакрымнар ераклыкта, Дәүләкән районына керә.

[2] Кантуннар заманы – 19 гасыр ахырларына кадәр башкортлар яшәгән җирләр кантоннарга бүленгән, һәм беркадәр башкортларның үзидарә органнары сакланган.

[*] Казакълар турында сүз бара.

[3] Ун сан уймат ( ун сан кыргыз иле) – казакъ, каракалпак һәм күчмә үзбәкләрдә уймат, уймаут, ыруы билгеле; нугайларда йети сан (җиде сан) кабиләсе бар. Шул мәгълүматлардан чыгып, бу этнонимны ун сан кабиләсенең уймат ыруы дип аңларга кирәк. Сан сүзе кыргыз, казакъ, каракалпак һәм нугай телләрендә «ун мең кешелек берәмлек (шулай ук «бик күп, хәтсез») дигән мәгънәдә кулланыла.

[4] Беренче басмада: Сары Мыркыс; Моркас язылышы икенче басмадан алынды: бу язылышны икенче басманы хәзерләүчеләр ниндидер билгеле чыганактан алганнардыр дип уйларга нигез бар.

Моркас ханның яшь хатынынnан бер Заятүләк[1] исемле ир баласы дөньяга килде.

Заятүләк шул замандагы хан балалары ни эш берлә мәшгуль булса, нәрсә белән шөһрәт тапса, бу да шулар кеби тәрбия алып, һәр эштә һәркемнән өстен булды. Ягъни ул заманның һөнәрләреннән булган ат чабыштыру, ук ату, найзалар (сөңге) тоту, көрәшү кеби нәрсәләрнең һәрберендә Заятүләк беренче булып санала иде. Һәм зур, киң, чиксез сахраларда кош чөеп кош типтерү, бу юлда осталык белән мәшһүр булу зур һөнәрләрдән хисап ителә иде.

Заятүләк тә үзенең агалары – хан балалары берлә күп вакытта ат чабыштыру, ук ату, кош чөештерү белән йөри торган иде. Шул үзләренең һөнәрләрене бер-берсеннән уздыру, арттыру өчен болар арасында көнләшү, намуслanулар да булып китә – олуг хатыннардан туган балалар, бер иттифакта булып, Заятүләкне читләтеп кысалар, ничек булса да бераз сылтау табып, аны күздән төшерергә йөриләр иде. Чөнки Заятүләк теге һөнәрләрдә аларга өстен булганның өстенә, үлән (шигырь)гә[*], думбырага[**] оста, төскә-башка матур, көчлелеге белән мәшһүр вә шул сәбәпләр өчен хан иле, үзенең йорты, агай-энеләре Заятүләкне башкаларга караганда артык ярата торганнар иде. Көннәрнең берендә хан үзенең унике канатлы тирмәсенә[***] балаларыны чакыртты. Хан балалары һәрберсе бертөрле киемдә иде. Ягъни башларына шул заманның хан балалары кия торган матур җәйге эшләпәләр кигәннәр, өстләренә ефәк чапаннар киеп, билләрен буганнар, көмешле хәнҗәрләрен алтынланган кыныларга салып, билләренә такканнар иде.

Агалары (хан) янында да мәшһүр биләре (бәкләре), гакыл әһелләре утыралар иде. Балалар аталары янына барып кергәч тә сәлам бирделәр. Аталары хан аманлык-саулыкларыны сорашты. Балаларыны берәр күздән үткәреп, кылган эшләрен сорашты. Хан, балаларының матурлыкларын күргәч, шатлыгыннан, аларга чөяр өчен берәр лачын кошы биреп, аның өстенә һәрберсенә берәр ат бирмәкче булып, диде:

---

[1] *Заятүләк*: Зая (яки җая, чая) дип төрки-монгол мәҗүси аллаларының берсе – терлек-туар химаячесе аталган; яуда үлгән кешеләр рухын да зая дип атаганнар. Әсәрдә (һәм гомумән халык авыз иҗатында) Заятүләк ешрак Түләк дип кенә йөртелә; төрки телләрдә түләк «бәрән, кузый; юаш кеше» дигән сүз.

[*] Дөресе: үләң.

[**] Думбыра – ике кыл берлә генә ясалган, балалайка кеби уен коралы, бу көндә башкорт арасында исемен белүче дә аз, кыргызларда думбыра өй саен бардыр. *М. Гафури искәрмәсе.*

[***] Тирмә – киез өй – ута – җәй көнендә күчмә халыкның тора торган урыны. Кечкенәләре биш-алты канатлы була. Байларда сигез-тугыз канатлы буладыр. Унбер-унике канатлысы булганы бик байларда гына яки ханнарда гына буладыр. Борынгы башкортлар, җәйләүдә йөргәндә, тирмә берлә йөргәннәр. Бу көндә кыргызларда һаман бардыр. *М. Гафури искәрмәсе.*

– Каракларым[*], һәрберегез җылкылар янына барып, берәмләп җөгәннәрегезне шалтыратыгыз да, шул шалтыраткан вакытта нинди ат караса, шуны үзегезгә алыгыз, начар гына ат караса да, бу бик начар дип алмай калмагыз, – диде.

Балалары шатланып, кошларыны алып, аталарына карап башларыны иеп, чыгып киттеләр.

Һәрберсе, алтынлы җөгәннәрене алып, җылкылары янына бардылар, Заятүләктән башкалары җөгәннәрене шалтыратып тормый, җылкы арасыннан иң яхшыларыны сайлап алдылар. Әмма Заятүләк атасының сүзене аяк астына калдырмас өчен, аның сүзе буенча, җөгәнне шалтырата, шундук начар гына акбүз тай аңа карай, Заятүләк тә, миңа насыйп шушыдыр дип, акбүзчәне тотып алып, җөгән кидерткәч, бүзчәнең төсе, сыны (гәүдәсе начар булса да) яхшылыгыны, тулпар булуыны белдерә иде.

Бераз вакыттан соң аталары боларга дәхи берәр кош алырга кушты. Боларның бәгъзесе бөркет, бәгъзесе шонкар, бәгъзеләре карчыга алдылар. Әмма Заятүләкне читсендереп, аңа ябалак баласы кеби бер ак кош[1] баласы бирделәр.

Болар шул көн һәммәсе бергә кош чөяргә[**] чыгып, каз, үрдәк кеби кошларга үзләренең кулларындагы кошларыны җибәрделәр. Заятүләкнең агаларының кошлары бәгъзесе торна, бәгъзесе каз вә бәгъзесе үрдәк алды. Әмма Заятүләкнең кошы сигез суна[2] дигән кошны куып тотты вә, тырнагы арасына кыстырып, Заятүләк янына китерде. Болар үзләренең кошларыны аталары хан каршына алып барып бирделәр.

Хан һәрберсенә берәр алтын бирде. Заятүләк сигез сунаны атасы алдына куйгач, атасы, моны мактап, ун алтын[3] бирде.

Кош ауларга чыккан Заятүләк агаларына караганда күбрәк кош ала иде. Атасы да моның өчен Заятүләккә алтынны күбрәк бирә иде. Бервакыт ат чабыштырганда, Заятүләкнең бүз тае җил җитмәс аргамак булып, башка агаларының атларыны узды. Бу эшләрнең һәрберсенә, хосусән аталарының Заятүләкне артык яратуына агаларының эчләре поша башлады. Заятүләкне ничек тә берәр төрле һәлак итмәкче булдылар.

[*] Карак, карагым – казакъта баланы яратып сөйгән вакытта әйтелә торган мәдех вә мактау сүзедер. Бур, угры. мәгънәсендә түгел. *М. Гафури искәрмәсе.*

[1] Ак кош, ак ябалак, ак шоңкар тезмәләрендә ак «ауга өйрәтелгән, кыйммәтле» дигән мәгънәдә (гарәпчә хак «бәя, кыйммәт» сүзеннән).

[**] Кош чөю – лачын, карчыга, шонкар кеби кошлар белән үрдәк, казны типтерү, ауга чыгып кулдан кошны очырып җибәрүдер. *М. Гафури искәрмәсе.*

[2] Сигез суна (түбәндәрәк – суна) бормалы озын муенлы, зур гәүдәле (каздан дәүрәк) су кошы; русчасы – гагара; элек дала күлләрендә күп булган, хәзер урман, тайга сулыкларында гына очрый.

[3] Алтын – борынгы акча берәмлеге.

Үзара киңәш итеп, Заятүләкне үтерү касды илә алтмыш кеше бергә кош чөяргә ауга чыктылар.

Атлас кеби ямь-яшел тигез сахраларны, көмеш тәнкә кеби матур ялтырап ята торган күлләрне үтә-үтә, хан авылыннан бик еракка киттеләр. Бер күлдә кошларны җибәргәч, башка кошлар берәр кош типкәндә, Заятүләкнең кошы бер рәттән җиде аккошны кагып, тибеп төшерде.

Кайтаек дигән булып, атларыны чабыштырдылар. Заятүләкнең менгән аты җил кеби очып китте. Агалары чак-чак күреп калдылар. Бу сәфәрдә Мәкъсудларына җитә алмаганнары өчен эчләреннән яндылар. Заятүләк, алдан кайтып, атасыннан күп бүләкләр алды. Агалары моны күргәч бигрәк гарьләнделәр, ничек тә моны үтереп, моннан котылмай булмас, диделәр.

Үзләренең гадәтләре буенча янә бервакыт ауга чыктылар. Бик еракта бер зур күл янына барып кундылар. Төнлә, Заятүләк уйкулагач, аны үтерергә киңәш кыйла башладылар. Бәгъзесе күлгә ташлаек, бәгъзесе үтерәек тә ханга ат тибеп үтерде диермез, диделәр.

Араларыннан берсе: «Юк, алай күз алдында үтермәңез, атының дүрт аягына кадак кагыңыз, соңра ул аты илә йөри алмас, егылыр, үләр», – диде. Болар атның дүрт аягына кадаклар кактылар.

Агаларының бу эшеннән Заятүләкнең бер дә хәбәре юк иде. Төшендә бер кеше: «И угылым Заятүләк! Гафил булып уйкулайсың, агаларың һәм юлдашларың, сине үтерергә касд кыйлып, сине үтермәкче булдылар. Атыңның дүрт аягына кадаклар кактылар. Менә мин сиңа бер дога үгрәтәем, кайчан да башыңа берәр мөшкил эш төшсә, шуны укырсың», – диде.

Заятүләк, урыныннан торып, атны барып карады, вакыйгаң атны кадакланган, начар бер хәлдә күрде.

Теге кеше үгрәткән доганы укып, атының аягына өшкерде. Аты шундук төзәлде. Иртән торгач, иптәшләре Заятүләкне сынамакчы булып: «Бар, фәлән күлдә кошлар бар микән, карап кил», – диделәр.

Заятүләк урыныннан торып, атына менеп, тегеләр әйткән күлгә карап юнәлде. Бу алтмыш кеше моны күреп хәйранга калып: «Буның аты ничек йөри ала? Монда ни хикмәт бар? Инде буңа һөҗүм кыйлып үтермәй булмас, атамыз ханлыкны Заятүләккә биреп куяр», – диделәр. Араларыннан берсе: «Өч кеше барыңыз да атының авызлыгыны алып, өчеңез өч яктан атыны камчылап куыңыз, аты дулап Заятүләкне агачка яки ташка бәреп үтерер, менә шулай итеп, Заятүләктән котылырсыз», – диде. Болар, бу сүзне мәгъкуль күреп, өч кешене җибәрделәр; бу өч кеше Заятүләк янына барып, атының йөгәнене алып, камчылап кудылар.

Бүзчә тай Заятүләкне алып очты. Алты-җиде көн бер дә туктамай китеп, сигезенче көн кояш чыгар вакытта зур бер күлнең якасына барып туктады. Биек тауның башыннан зур күл ашъяулык кеби тип-тигез, бөтенләй күренеп ята иде. Бу олуг күл бу көндәге мәгълүм Асылы күл (яки Ачылы күл) уладыр*. Биек тау дигәнемез күлнең кыйбла тарафында Кара агач дигән ярның өстендәге олуг таудыр, моны Кашка тау дип әйтәләр. Кашка ягъни үлән үсмәгән тауның өсте, Заятүләкнең аты кимереп торганга күрә, һаман үлән үсмәенчә, такыр, ялангач булып ятадыр, диләр.

Анда торып калган Заятүләкнең иптәшләре Түләкнең кайда киткәнене һич белмәделәр.

Менә шул Асылы күлдә пәриләрдәнме, юкса башка затларданмы, – намәгълүм бер адәм ханлык кыйла иде.

Моның исеме Чачуар (сачы вар)[1] иде. Бу Чачуар ханның бигаять матур булдыкыннан һәркем күрсә гашыйк булып, гыйшкыннан хәйран калып, үз-үзен белмәс була торган бер кызы бар иде. Кыз һәр көн иртә белән күлнең читенә чыгып, сачын тарап үреп китәр иде.

Заятүләкнең аты шул кызның сачын тарап утыра торган ташның тугърысына туктаган иде. Бу таш бу көндә дә бардыр. Моны Түләк ташы дип әйтәләр. Өй зурлыгында, дүрт почмаклы, өстәлгә охшашлы, бик тигезләп юнып ясаган шикелле булып торадыр (бу ташны әле дә башкортлар Сусылуның чәч тараган ташы дип тә әйтәләр). Шул күл буендагы сәке кебек таш өстенә утырып, ап-ак аякларыны көмеш кеби саф суга салындырып, күләгәсе сузылып күлгә төшкән көенчә, бер хан кызы көндәге гадәте буенча сачын тарап, үзен төрле бизәкләргә бизәп утыра иде.

Кыз озын сачын икегә аерып ачып караем дип торганда гына, сизмәй дә калды, Заятүләк кызга сәлам бирде.

Кыз Түләкнең тавышыны ишетеп, биһуш була язып, йөзен куллары илә басып калды. Гомерендә андай адәм тавышы ишеткәне булмаганнан, ни кыйласын белмәй аһ кыйлып әйтте: «Әгәр мин сине күрә торган булсам, йөземне сиңа күргәзмәгән булыр идем», – диде.

Заятүләк бер күрү илә кызга җан-тән илә гашыйк булып, һич сүз әйтер хәле калмады.

Кызның күңелендә, ничек булса да Түләкне алдап бер якка каратып, аннан качып суга чуму иде.

---

* Башкортлар Ачылы күл һәм Асылы күл диләр. Ул күлдә әллә нинди бер куәт барлыгымы, бу вакытларда да күлдә харикыльгадә эшләр булганлыгымы сөйлиләр һәм аны шәриф, кәрамәтле күл дия игътикад итәләр. Күлнең әйләнәсе утыз биш-кырык чакрым чамасында булып, түгәрәк, көмеш кеби саф, төбе күренеп ятадыр. *М. Гафури искәрмәсе.*

[1] М. Гафуриның Чачуар, Сачы вар дип язып алганы асылда җаудар: үзбәк, төрекмән, каракалпак, телләрендә җаудар, җавдор, җодар – су асты патшасы, аждаһаның бер төре.

Түләк кызга гашыйк булып, шул бәетне[1] әйтте:

БӘЕТ

Инеп килдем атымнан
Имде синең рузыңа,
Сәлам бирдем бән сәңа –
Ай тик күрекле йөзеңә.
Гашыйк булдым бән сәңа –
Көндәй күркәм үзеңә,
Хәйран булып калыпмән
Бал-шикәрдәй сүзеңә.
Сүзең әйтче, Сусылу,
Сүзең әйтче, Сусылу!
Сәфәр кыйлдык күп кеше,
Җөгәнем суйды өч кеше,
Атым килә йир ашып,
Кошым килә кыр ашып;
Атым-юлым[2] белмәймен,
Җирем-суым белмәймен;
Атың әйтче, ай, сылу,
Җирең әйтче, Сусылу.

Кыз, Заятүләккә карап:

Атың үзең беләсән,
Җирең-суың беләсән,
Һәрамзалык кыйласың,
Заятүләк атлы сән.
Атың килсә йир ашып,
Кошың килсә кыр ашып[3];

---

[1] Әсәрнең беренче басмасында бу урында һәм арырак та шигырь, шигырьләр дип, икенче (1927 елгы) басмасында бәет, бәетләр дип бирелгән; дастаннар теленә соңгысы хас.

[2] Атым-юлым – борынгы баһадирлар очрашканда үзләренең ат-юлларын, ягъни кайсы кабилә, кайсы ырудан икәнлекләрен һәм нинди максат белән йөрүләрен әйтә булганнар; кайбер баһадирларның максаты дошман күргән ыруны кимсетү, үч алу булган һәм шуңа күрә ул ат-юлын бик әшәке сүзләр белән әйткән. Хәзерге татар телендә «аты-юлы» – әшәке сүз мәгънәсендә йөри.

[3] Беренче басмада бу урында бик аңлаешсыз язылган: атмйрашыб, кулм килә крашб (транслитерация;); икенче басмада:

Атым ярашып,
Кулым килә карышып, – дип «төзәтелгән». Башкортча басмаларда атым килә ярышып, кулым килә карышып диелгән. Әмма мондый интерпретация әсәрнең рухына һәм эчтәлегенә ярашмаганлыктан, беренчел текст бик нык үзгәртелгән дип уйларга кирәк. Нугай фольклорында йылкым килә йир асып (ашып), косым (кошым) килә кыр асып (ашып) дигән юллар очрый; безнең интерпретация шуңа нигезләнде (тәфсиллерәк аңлатманы к.: Казан утлары, № 8, 1980, 146–148 битләр).

Ун сан кыргыз илендә
Сары Моркас угълы сән.
Заятүләк – яшь угълы,
Заятүләк – яшь угълы,
Атың менеп чыгыпсән,
Кош чөяргә килепсән.
Үз илеңнән аерылып,
Безнең йиргә килепсән,
Заятүләк – бай угълы,
Заятүләк – хан угълы.

Заятүләк кызга:

Бер дигәндә бил алган[1],
Муены сынык суна алган,
Муены озын торна алган,
Кош очкыры чүрәгәй –
Канат какмай шуны алган,
Артык кошны асрамас;
Ак ябалак баласы –
Шонкарымнан бизәен,
Синең белән булаен;
Атың айтчы, Сусылу.
Суның кызы Сусылу,
Синең белән булаен.
Бер дигәндә бил алган,
Агызы канлы бүре алган;
Аягы сылтак төлке алган,
Ниндәй көчле булса аю –
Бер тибрәтмәй шуны алган
Ак шонкардан бизәен.
Атыңны айтчы, Сусылу,
Атыңны айтчы, Сусылу!

Кыз, Заятүләккә карап;

Атым сорап ни дирсән,
Җирем сорап ни дирсән?
Безнең йирләр катыдыр,
Түзәлмассың, Түләгем,
Торалмассың, Түләгем.
Безнең йирләр ташлыдыр –

---

[1] Бу урында моңарчы басмаларда белә алган дип язылган; хәлбуки кош чөючеләр телендә бил алу – корбанның җилкәсеннән эләктерү.

Госса булып үләрсән,
Хаста булып ятырсән,
Кайтып киткел, Түләгем,
Кайтып киткел, Түләгем.

Түләк кызга:

Артык кошны асрамас
Ак шонкардан бизәен,
Айлык юлга караган –
Көнлек юлга бер баскан,
Дүрт аягы маерылган
Аргамактан бизәен,
Синең берлә булаен,
Суга китеп үләен.

Кыз, Түләккә карап:

И, Түләгем, Түләгем,
Юктыр сиңа бүләгем,
Кулымдагы көмеш йөзек –
Менә сиңа бүләгем.
Куш әмәйлек, көмеш йөзек
Бүләк булсын, бай угълы;
Шуны ал да кулыңа,
Кайтып киткел, бай угълы!

Заятүләк кызга:

Көмеш йөзек, куш әмәйлек[1]
Зифа буең бизәгел,
Ул бүләгең кирәкмәй,
Зифа буең теләгем.
Сүзем кабул күрмәсәң,
Суга төшеп үләем,
Суга төшеп үләем.

Кыз, Заятүләккә карап:

Куш әмәйлек, куш йөзек
Алмадың син, Түләгем;
Бүләк бирдем, алмадың,
Нидер синең теләгең?
Көндәй[*] үзем төзәнгән,
Айдай йөзем бизәнгән,

---

[1] Әмәйлек – муенсаның бер төре; к.: Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969, 543 б. Моңарчы басмаларда бу урында эмилек дип хата басыла килгән.

[*] Көн – кояш, нитәк ки, бер бите ай, бер бите көн кеби матур диләр. *М. Гафури искәрмәсе*.

Алтын тарак, ай көзге –
Менә сиңа бүләгем,
Менә сиңа бүләгем.
Сиңа булыр дәгелмән,
Миңа булыр дәгелсән,
Өмид итмә, Түләгем,
Ышанмагыл, Түләгем!

Заятүләк, кызга карап:

Өнә тугыз[1] ай күтәргән,
Агырлыктан бөгелгән,
Аера имчәктән сөт биргән –
Анамнан да бизәен.
Төн йокысын өч бүлгән,
Төнлә торып имезгән,
Агыздан каймак җидергән
Анамнан да бизәен,
Синең белән булаен,
Суга төшеп үләен,
Атың айтчы, Сусылу,
Атың айтчы, Сусылу!

Кыз, Заятүләккә карап:

Куш әмәйлек, куш йөзек
Алмадың син, Түләгем,
Кулымдагы көмеш йөзек
Алмаймусән, Түләгем,
Бүләк биреп алмадың,
Нидер синең теләгең?
Нидер синең теләгең?

Заятүләк кызга:

Аеры сакал үстергән
Атамнан да бизәен,
Сары Моркас хан иле –
Барыннан да бизәен.
Синең белән булаен,
Суга төшеп үләен.

Кыз, Заятүләккә карап:

Аеры сакал үстергән
Атаңнан да бизмәгел,

---

[1] Өнә туг(ы)зай – тулы тугыз ай; нугайча үне, өнә «тулы, бөтен»; моңарчы басмаларда бу урында ун-тугыз (хәтта унтугыз, тугыз-ун) дип хата басыла килгән.

Сары Моркас хан иле –
Барыннан да бизмәгел,
Сүзең айтчы, Түләгем,
Сүзең айтчы, Түләгем.
Ана, аргы ягыңнан
Килә җатыр биш кеше,
Белмәймүсән, бай угълы,
Күрмәймүсән, хан угълы? – дип, Заятүләкне алдап читкә каратты да үзе суга чумып китте. Егет әйләнеп караса, кыз суга чуммыш. Кызның сачы алтмыш карыш иде. Шул озын сузылган җылан кеби кара сачының бары алты карышы су өстендә калган вакытта Заятүләк, кире борылып карап: «Аһ, харап булдым, Сусылу мине алдап кына читкә караткан икән, инде монда ялгыз калганчы, Сусылу белән су астында үлгәнем артык», – диде дә Сусылуның сачына барып ябышты. Шул ябышкан көенчә икәүләп Асылы күлнең астына төшеп киттеләр.

Бераздан соң икенче бер якты дөньяга барып чыктылар. Шул җирдә җеннәр торган шәһәрдә Сусылуның ак пыяладан сарае бар иде. Шул сарайның алдына барып туктадылар. Заятүләк кызның сачыны кулына бик нык итеп ураган иде. Кыз «Җибәрсәнә!» дип ничаклы ялынса да, кулыннан ычкындырмады.

Моннан соң кыз шул бәетне[1] әйтте:

Мин керәем сарайга,
Урын-түшәк җәяем,
Сине чыгып алаем,
Көтеп торгыл, бай угълы!
Чәчкәемне ычкындыр,
Мин чыгармын, көтеп тор,
Итәрбез бергә хозур,
Көтеп торгыл, бай угълы!

Моннан соң Түләк кызның сачыны ычкындырды. Кыз сарайга керде дә бикләнде. Түләк ишек төбендә калды.

Кыздан һичбер хәбәр юк иде. Сарайның дивары пыяладан, башлары гәүһәрдән, идәннәре мәрмәр ташыннан иде. Сарайның якынында саф көмеш кебек ялтырап яткан күлләр өстендә төрле төстәге үрдәкләр, аккошлар йөзеп йөриләр иде. Сарайның икенче ягында төрле төстәге елгалар, чишмәләр, чылтырдашып, матур ташлар арасыннан агып яталар, су эчендә сап-сары алтын, ап-ак көмеш кеби матур балыклар уйнап йөриләр иде.

Кыз, Заятүләкне монда калдырып, үз янына сарайга кертмәгәч, Заятүләк әлеге төшендәге карттан өйрәнгән догасыны укыды. Шундук

[1] Бәетне – беренче басмада бу урында назымны диелгән.

күлләр корый, чишмәләр кибә башлап, кошлар, балыклар үләргә якынлаштылар.

Бу эшне күргәч тә пәриләр, падишаһка барып: «И хөрмәтле шаһымыз! Кызның сарай ишеге төбендә бер адәми зат утыра, шул егетнең шомлыгыннан булса кирәк, күлләр, елгалар корый башладылар. Ул адәмнең кайдан килгәне, ничек итеп монда килә алганы билгесез», – [диделәр].

Падишаһ шундук кызына: «И кызым! Ул егет, әлбәттә, син күл читенә чыгып чәчең тараганда күреп калган да синең артыңнан монда килгәндер, ул яныңа керсен, аның ни эше бар, сораш, аның сиңа зарары тимәс, шуннан соң кайдан килгән – шунда китәр», – дип хат язып биреп җибәрде. Сусылу атасының хатын алып укыгач, сарайның ишегене ачты. Шул сәгать Заятүләк, сарайга кереп, ачуыннан Сусылуның сачыннан тотты.

Сусылу: «И егет! Инде мин синең, син минең булдык, минем чәчемнән җибәр», – диде.

Моннан соң Сусылу атасына хәбәр җибәрде.

Атасы, бу хәбәрне ишеткәч: «Бу эш охшар микән? Ул туфрактан яратылды, без уттан яратылдык, ул җир өстендә тора, без күл астында суда торамыз», – диде.

Вәзирләре: «И падишаһ! Инде бу кызның тәкъдире адәм баласыннандыр», – дигәч, падишаһ кызыны Заятүләккә бирмәкче булды.

Бөтен шәһәр халкы, зур туйлар ясап, Сусылуны Заятүләккә бирделәр. Болар шулай торган вакытта, беркөн Сусылу Заятүләккә: «Минем сахрага чыгып йөреп кайтасым килә, сез монда торыңыз, мин тиз кайтырмын», – дип чыгып китте.

Заятүләк, ялгыз калгач, сарайның бүлмәләрене карый башлады. Йөри торгач бер бүлмәдә булат көзге күрде. Көзгегә карап, үзенең саргайганын күргәч:

«Аһ! Ата-анамнан, Төркестан иленнән аерылып, бер кызга гашыйк булдым, бер кыз өчен йөземне сары кыйлдым», – диде.

Уйнар өчен бер думбыра ясады. Кыз кайткач та, думбыраны күреп: «Бик матур нәрсә ясаган икәнсән, уйнап карасана», – диде. Заятүләк думбыраны алып, шушы үлән (җыр)ларны әйтте:

И думбырам, думбырам,
Уйна, күңел ачылсын;
Думбырам бәнем уйнайдыр,
Кыл кубызым сәрнаудыр[1],
Тыңлай килгән адәмнәр
Үзен-үзе белмәйдер.

---

[1] Сәрнау, сарнау – моңлы-зарлы итеп көйләү; беренче басмада бу сәрнайдыр дип хата язылган (һәм бу хата башкортча басмаларда да кабатлана).

Бәгъзе вакытларда Сусылу Заятүләк яныннан әллә кайда китеп югалып тора иде. Заятүләк, бу эшкә гаҗәпсенеп: «И Сусылу, кайчакта син әллә кайда китәсең, кайда барып йөрисең?» – диде.

Сусылу: «Мин әлеге син килеп туктаган җиргә чыгып, таш өстендә утырып чәчемне тараймын, төзәнеп, бизәнеп кайтамын», – диде.

Заятүләк: «Минем атым белән чөя торган кошым шундамы?» – диде.

Сусылу: «Алар һаман шунда торалар, синең төшкән урыныңа караганнар, күзләрен шул урыннан алмыйлар, ябыгып беткәннәр», – диде.

Заятүләк (көрсенеп): «Аларны монда алып килә алмассыңмы?» – диде.

Сусылу: «Мин булгач, алар сиңа нигә кирәк? Син, атымнан да бизәем, кошымнан да бизәем, дидең», – дип, шу үләннәрне әйтте.

Атың тора әбегеп*,
Синең өчен ябыгып,
Ул хезмәтне итәргә
Хәлем килми, бай угълы.
Атың синең йелмая[1],
Аңа килер юл кая?
Ул хезмәтне итәргә
Хәлем килми, бай угълы.

Шуннан соң Заятүләк әлеге карт өйрәткән доганы укыган иде, аты белән кошы сарай ишеге төбенә килделәр. Түләк, аты белән кошыны күргәч, нишләргә белмәде. Кошы талпынып, аты кешнәп тора. Атының җал-коерыгыны сыпырып, аллага шөкер кыйлып, кайгысыз гомер итә башлады.

Бер вакытта Чачуар хан, Түләк белән кызы Сусылуны үзенең йортына чакырып: «Бу йорт һәм илем – җен йорты, җен иле. Сез монда тора алмассыз, инде җир йөзенә чыгыңыз, мин сезгә инче** итеп күп мал бирермен», – диде. Сусылу белән Түләкне пыяла арба белән күтәртеп, Ачылы күл астыннан яр читенә чыгартып ташлатты.

Заятүләк, күл читендә кайгырып, кайда барырын белми торганда, Ачылы күл – ак сакаллы карт килеп: «Әй, угълым! Бер дә кайгырма, Балкан тауга*** бар! Ходай Балкан тавыны синең өчен яраткан», – диде.

---

* Әбегү – тынычсызлану, түземсезләнү. *М. Гафури искәрмәсе.*

[1] Йелмая, җилмая, маян – кыпчак халыклары фольклорында легендар канатлы ат, канатлы дөя.

** Баланы башка чыгарганда, атасының биргән малы. *М. Гафури искәрмәсе.*

*** Балкан тавы Асылы күлдән унбиш-егерме чакрым ераклыктадыр һәм дә Чишмә стансасыннан егерме чакрым кадәре җирдә Балкан дигән кечкенәрәк бер тау бар. Балкан шибеһе җәзирәсендәге Балкан таулары белән бер исемдәге тауларның монда да булуы боларга төркиләр тарафыннан исем бирелгәнлекне аңлатадыр. *М. Гафури искәрмәсе.*

Сусылу, Заятүләккә карап: «И, җаным, тау башына менеп җитми торып, бер дә артыңа әйләнеп карама! Әгәр дә әйләнеп карасаң, безгә ияреп килә торган мал-туарны харап итәрсән», – диде. Түләк, атына менеп, кошыны кулына кундырып, Сусылу әйткәнчә, артына әйләнеп карамый, тауга карап юнәлде.

Хан Сусылуга атсыз арбалар әзерләп, асыл затлар тулган сандыклар төятеп, кол кызлары белән бергә Түләкнең артыннан җибәрде. Сусылуның артыннан су елкыларын кудырды. Кол кәнизәкләр кычкырышып, елкылар кешнәшеп әллә нинди тавышлар чыгаралар иде. Түләк Асылы күлдән Өйдерәк* баш дигән җиргә җиткәнче артына әйләнеп карамады. Балкан тауга җитәр чакта, күңеленә курку төшеп, тавыш чыккан якка әйләнеп караса, тычкан сыртлы кола елкы белән Ачылы күл берлә Өйдерәк арасы тулган, Ачылы күлне һаман чыгып бетмәгәннәр. Берсенең сыртына берсе башын салып чыгуларыны күрде. Заятүләк әйләнеп карагач та, куркышып, Ачылы күлгә кире чумдылар. Калганнары бик аз калды. Әгәр дә Заятүләк артына әйләнеп карамаса, шул төсле елкылар белән җир йөзе тулар иде. (Менә бу вакытка чаклы Сәрмәсән һәм Дим** буе башкортлары чәчән, үткер малларны Сусылуның артыннан чыккан су елкысы диләр). Калган маллары белән, Балкан тауга барып, гомер итә башладылар. Ул вакытларда Балкан тавында төрле җанвар, ягъни кыр киекләре бар иде. Заятүләк, уенга оста булганга күрә, төрле көйләр җырлый, уйный, мондагы җанварларны күреп, бу үләңнәрне әйтә иде:

Аеры койрык, елтан күз
Качкыры күп Балкан тау,
Кыска койрык, шәм колак
Куяны күп Балкан тау,
Майлап салган каештай
Җыланы күп Балкан тау,
Алпан-тулпан атлаган
Аюы күп Балкан тау,
Кыз баладай бизәнгән
Төлкесе күп Балкан тау,
Оя ясар җире күп,
Кошлары күп Балкан тау.

* Өйдерәк – елга исемедер. Мәшһүр «Өйдерәк» көе шул елгага нисбәт бирелгән. *М. Гафури искәрмәсе*.

** Сәрмәсән, Дим – мәшһүр сулар. Сәрмәсән, Дим буе мәнзарасының гүзәллеге белән мәшһүрдер. [Дим елгасы] Уфа янындагы тимер күпер янында Агыйделгә килеп кушыла. *М. Гафури искәрмәсе*.

Бераз вакытлар торгач, суның кызы Сусылу, үзенең шәһәрене, ата-анасын сагына башлагач, Заятүләк аның күңелене табар өчен түбәндәге җырларны әйтте:

Уң ягымнан терәргә
Балкан тавым бар минем,
Сул ягымнан терәргә
Сусылуым бар минем.
Бар да алла кодрәте,
Шөкер кирәк, Сусылу,
Шөкер кирәк, Сусылу.
Җаек башы – Бөер тау,
Идел башы – Ирәмәл тау.
Аннан биек Балкан тау,
Шөкер кирәк, Сусылу,
Шөкер кирәк, Сусылу.
Тәхет, бәхет яраткан
Балкан тавым бар минем,
Шөкер кирәк, Сусылу,
Шөкер кирәк, Сусылу.

Моннан соң Заятүләк шул тирәгә мәшһүр булды. Җеннәр барып падишаһка: «Бу көндә киявең мәшһүр булган Балкан тавында шаһлык итә», – диделәр.

Падишаһ киявене кунакка чакырды. Түләкне җеннәр килеп алып кайттылар. Анда баргач, аңа уен уйнарга куштылар.

Түләк, бабасы җен падишаһына каршы карап:

Уң ягымнан терәргә
Балкан тавым юк минем,
Сул ягымнан терәргә
Сусылуым юк минем,– диде.

Падишаһ, җеннәргә әмер кыйлып: «Барыгыз, Сусылу белән Балкан тавыны монда алып килегез», – диде. Җеннәр барып Сусылуны алып килделәр. Икенче рәт барып, Балкан тавыны таба алмагач, икенче бер тауны Балкан тауга охшатып, падишаһ һәм Түләк янына алып килделәр. Заятүләк, бу тауның Балкан тавы түгел икәнен аңлатып, шу сүзләрене әйтте:

Тауны тауга охшатып,
Тимер белән коршатып,
Алып килә җатырлар –
Минем тавым бу түгел.
Сулап каккан казыктай,

Суда йөргән балыктай
Киеге күп Балкан тау –
Балкан тавым бу түгел,
Балкан тавым бу түгел.
Балкан тауның биеге,
Башында уйнар киеге, –
Балкан тавым бу түгел,
Балкан тавым бу түгел.
Кыз баладай сөйсәлгән[1]
Төлкесе күп Балкан тау,–
Балкан тавым бу түгел,
Балкан тавым бу түгел.
Майлап салган каештай
Җыланы күп Балкан тау, –
Балкан тавым бу түгел,
Балкан тавым бу түгел.
Шеш аяклы, шеш мүгезле
Боланы күп Балкан тау, –
Балкан тавым бу түгел,
Балкан тавым бу түгел.
Алпан-тулпан атлаган
Аюы күп Балкан тау, –
Балкан тавым бу түгел,
Балкан тавым бу түгел.
Тауны тауга охшатып,
Тимер белән коршатып,
Алып монда килсәләр дә,
Балкан тавым бу түгел, – дип әйтте дә уен уйнамады.

Падишаһ, моны күргәч, Заятүләк берлә Сусылуны җир өстенә чыгартты. Алар, кире шул Балкан тавы өстенә барып, күп еллар гомер иттеләр. Иң ахырда шул тауда вафат булдылар.

Заятүләк белән Сусылуның каберләре шундадыр. Заятүләк, үз иле Төркестаннан киткәч, кире анда урап кайта алмады. Сусылуга[2] гашыйк

[1] Сөйсәлгән – моңарчы басмаларда бу урында сөйләшкән дип языла килгән. Ләкин төлкеләр сөйләшми. Шуңа күрә монда каракалпак, кыргыз телләрендәге суйсалу, сүйсәлү (ыспай, җитез һәм матур хәрәкәт итү) сүзе булгандыр дип уйланылды һәм бу сүзнең татарча закончалыклы яңгырашы сөйсәлү алынды.

[2] Беренче басмада бу урында Айсылу дип язылган. М. Гафури үзе әйткәнчә, ул ушбу дастанны «Заятүләк белән Сусылу»ның күп кенә кульязма вариантлары нигезендә төзегән һәм шуларның берсендә Сусылуның исеме Айсылу булган булса кирәк (чаг.: Болгар кызы Айсылу – асылда шул ук Сусылу).

булу сәбәбеннән, Ачылы тирәсендә Балкан тавында йөреп гомерене үткәрде, иң ахырда Балкан тавы өстендә вафат булып, шунда күмелде.

*Вөҗданән могаззәб булып* – вөҗданы белән газапланып.

*Тәнәззеһ вә истирахәт* – күңел ачу һәм ял итү.

*Вакыйган* – чыннан да.

*Игътикад итү* – ышану, инану.

*Мөтәгаддид* – күп кенә; берничә.

*Табгы кыйлу* – бастырып чыгару.

*Мөнасиб* – караган, нисбәт иткән.

*Мәгыйшәт* – яшәү кызыгы.

*Бер иттифакта* – бер сүздә.

*Хосусән* – аеруча.

*Касды* – теләге.

*Ачылы* – сазлы дигән сүз; татар, башкорт диалектларында: ачы, асы – сазлык.

*Харикыльгадә* – гадәттән тыш.

*Шәриф* – изге.

*Кәрамәтле* – могҗизалы.

*Игътикад итә* – ышана.

*Намәгълүм* – билгесез.

*Бигаять* – чиктән тыш.

*Ину* – төшү, иңү, керү.

*Рузыңа* – биредә: бәхетеңә, язмышыңа.

*Бән* – мин.

*Суйды* – тартып алды, салдырды.

*Һәрамзалык* (хәрамзалык) – хәрәмләшү.

*Госса* – кайгы-сагышлы.

*Маерылган* – як-ягына каерылган, аерып баскан.

*Җидергән* – ашаткан.

*Үлән, үләң* – җыр.

*Шибеһе җәзирә* – ярымутрау,

*Чәчән, үткер* – елгыр, темпераментлы.

*Качкыр* (кашкыр) – бүре.

***Заятүләк берлә Сусылу***. Беренче тапкыр аерым китап булып Уфаның «Шәрекъ» мәтбагасендә (нашире – «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе»), 1910 елда, икенче тапкыр Казанда «Яңалиф» нәшриятында 1927 елда чыккан (монысында авторның портреты бирелеп, текстны әзерләүче күрсәтелмәгән).

СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында «Заятүләк белән Сусылу»ның унга якын фольклор

варианты саклана. Алар төрле вакытларда курайчылардан язып алынганнар. М. Гафури «Заятүләк белән Сусылу»ны 1910 елгы басмада «башкорт хикәясеннән» дип тәкъдим иткән, ә 1927 елгысында «башкорт хикәясе» диелгән. Дастанның татарлар арасыннан язып алынган вариантлары да билгеле һәм аның сюжетында, телендә һ.б. элементларында аеруча башкортчалык сизелми, ә нугай һәм каракалпак тел һәм фольклор элементлары нык сизелеп тора (аерым искәрмәләрне карагыз).

*Текст 1910 елгы басма буенча алынды. Гафуриның 1937 елдан соңгы җыентыкларында беренче мәртәбә басыла.*

*Әсәрнең тексты, искәрмә һәм аңлатмалары филология фәннәре кандидаты Рифкать Әхмәтҗанов тарафыннан әзерләнде. М. Гафури файдаланган нөсхәләрдә, вариантларда, заманында нугай һәм каракалпак телләрен белмәгән кешеләр тарафыннан язып алынганлыктан, күрәсең, хаталар да киткән. Алар төзәтелеп басыла.*

***Алынды:*** *Мәҗит Гафури. Әсәрләр: Дүрт томда. III том. Проза һәм публицистика (1902–1917). Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1983. Б. 139–155.*

# КРАЕВЕДЕНИЕ В НАУЧНО-ПОПУЛЯРНЫХ ПУБЛИКАЦИЯХ

*Дамир Таҗи*

## ӘЛМӘТ АВЫЛЫ МӘХӘЛЛӘЛӘРЕНДӘ МӘЧЕТЛӘР ҺӘМ ИМАМНАР

(*Дәвамы. Башын карагыз: №1, 2022; №1,2,4, 2023; №3,4, 2024; №1, 2025*)

### Кечкенә поселокларда дини йортлар

Бөгелмә өязенең Әлмәт төбәгендә XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында, большевиклар хакимлеге чорында дистәдән артык кечкенә генә татар авылларына нигез салынган. Патша заманындагылары зур татар авылларында җир җитмәүдән һәм башка сәбәпләр аркасында да, милләтәшләребезнең иркенлек эзләве нәтиҗәсендә дә, шулай ук Столыпин реформалары белән дә пәйда булган. Болар Бикмораз, Бикәсаз, Мөгезле Елга, Гыйльман кебек кечкенә авыллар. Совет елларында оешканнары Гөлбакча, Ак Чишмә, Дәүләт, Бакалы, Аксу, Салкын Чишмә, Ирекле, Камы Елга, Кызыл Көч, Нариман, Сәмарканд, Юкәле, Наратлы, Баланлы Чишмә. Байлар, Бахчасарай, Болгар, Сабанчы, Иштирәк, Туктар, Кызыл игенче, Кызыл Кичү һ.б. Шул ук Азнакай районында гына да Наратлы Елга, Камышлы, Байкал, Бакчалы, Баланлы, Бүләк, Кызыл Сукачы, Таллы-Бүләк, Мәнәвез кебек дистәләгән кечкенә авыллар барлыкка килгән. Хәзерге Лениногорск районында 1895 елда Яңа Елховой, 1910 елда Аккүл, 1921–1928 елларда Карагай, Керкәле Тукмагы, Тактакуш, Урта Чишмә, Үрнәк, Сарабиккол Тукмагы, Бохар, Болгар исемле авыллар пәйда булган. Болары безгә билгеле булганнары гына. Бүген кайберләренең нигезе дә юк инде. Аларның мәчетләре юк дигәннәрендә дә, дини эшләр гөрләп алып барылган. Гает намазларын укый торган, дини-гыйльми мәҗлесләр һәм Коръән ашлары уздырылучы йортлар булган. Ягъни кайбер диндар кешеләр гает бәйрәмнәрендә, ураза аенда бергә җыелып җәмәгать намазлары уку өчен үзләренең йортларын мәчет иткәннәр. Бу инсаннар догаларда бүген дә зур хөрмәт белән искә алына. Мәрхүмнәрне искә алып дога кылу, шунда Корьән уку, балага исем куштыру, милли татар ризыклары белән сыйлану гасырлар дәвамында матур бер гадәт булып яши. Поселокларда мулла кебек укыган кеше булмаганда, күршедә-

ге зур авылларга барып яхшы укый белгән өлкән яшьтәге берәр кешене эзләп тапканнар. Без мөмкин булганча бу кечкенә авыллардагы дин йортлары, имамнар турында белергә тырышып, эзләнеп карадык.

Әлмәт волостендагы Бикмораз авылы (Бикмурас) 1910 елларда нигезләнеп 1980 еллар ахырында юкка чыккан. Баштан ул Бөгелмә өязе Варваринская волосте Җиһангир ширкәте буларак тарихка кергән. 1910 елда монда 119 ир-ат, 129 хатын-кыз яшәгән, 1010 дисәтинә файдалы һәм 47 дисәтинә файдасыз җирләре, чишмәләре булган (Самара губернасының халык яши торган урыннары исемлеге. Самара, 1910 ел). Мәчет тә төзегәннәр. Самара архивында шул мәчетнең 1914 елгы проект сызым рәсеме сакланган (Ф. 1, Оп. 12, Д. 5414). Монда Нуретдин Миңлебаев 1913 елдан имам, Мөшәрәфҗан Кәлимуллин (1907 елдан указы булган) 1921 елдан имам һәм мәзин, Шәйхелислам Гатауллин Нигъмәтуллин 1913 елдан хатыйп. Тагын бер имам Барый Гатауллин (1883) 1930 елга кадәр үк үз вазыйфасын калдырган. Бикмораз совет чорында Кичүчат авылы Советына караган, анда «Җәйләү» исемле колхоз оешкан. Мәчет бинасыннан файдалану өчен 1926 елда төзелгән килешүдә дин башлыгы күрсәтелмәгән. Мәчетләре 1939 елда рәсми ябылып балалар бакчасы ачылган. Хөкүмәт указлары белән танышканлыкка Шәйхетдин Хөснетдинов кул куйган.

Бөгелмә кантоны буенча үз вазыйфаларыннан 1930 елга кадәр китүче имамнар исемлегенә күз салыйк. Болар Камы Елгадан Харис Шаһиев, намаз уку йортыннан (молитвенный дом) файдалану өчен 1929 елда Совет белән килешү төзеп караганнар, ләкин «халык соравы» җыены буенча бина совет мәктәбенә бирелгән. Гөлбакча поселогында да шул ук хәл, дин йортын совет алгач Ярулла Хәмидуллин үз эшеннән туктаган. Гөлбакчада һәм башка авылларда да «ак мулла» һәм «кара мулла» кушаматлы ике дин әһеле Коръән укып йөргән. Поселокта намаз уку бинасыннан файдалану өчен 1926 елда совет белән килешү төзегәннәр. 1929 елда мәхәллә мәчете эшен туктаткан. Төбәктә ике Гөлбакча поселогы булган, монда кайсы турында сүз барганын ачыклап булмады. Ак Чишмәдән (мәчетләре 1922 елда төзелгән) Габдрахман Хәмитов (азанчы), Миннегали Нурмөхәммәтов, Гыйльманнан Хафиз Шәмсетдинов, Тарлаудан (Кәшер авылының бер өлеше) Хаҗимөхәммәт Нургалиев, Болгардан Хаҗимөхәммәт Нәдеров, Иркеннән Кашап Таһиров (хәзер Бөгелмә районы) үз теләкләре белән вазыйфаларыннан баш тартканнар дип язылып калган совет кәнсәләре җыеп барган мәгълүматларда. Кечкенә торлакларда муллалары булгач аның биш вакыт намаз уку йорты яки мәчете дә булган. Районда ике Болгар, ике Ак Чишмә поселогы булуын да әйтик. Ак Чишмәнең берсендә Нурмөхәммәт Шәмселхәмматов имамәтчелек кылган. Ул сөргендә дә җәфа чиккән. Харис хәзрәт Зарипов та Ак Чишмә

мулласы, мәчет салдыручыларның берсе. Соңыннан гаиләсе белән авылдан куып җибәргәннәр.

Болгар мөселманнар җәмгыяте мәчет бинасыннан файдалану өчен 1927 елның март аенда совет белән килешү төзегәннәр. Имамы булмаган. Әлмәт волостендагы Тарлауда килешү 1927 елда төзелгән. Бина 1928 елда ябылып мәктәпкә бирелгән.

Бөгелмә өязенең Бөгелмә волостендагы Ак-Күл авылыннан Зәки Ризванов, Алма-Ата поселогыннан Габделбарый Галимов имамлыкларын калдырып мәчеттән киткәннәр. Соңгысында 1929 елда намаз йорты халык соравы белән совет мәктәбенә бирелгән. Зәки хәзрәтнең гаиләсе 1930 елда барлык мөлкәтләреннән мәхрүм ителгән.

Әлкәй волостенда торган Ак-Түбә поселогы намаз йорты 1929 елдан совет карамагына күчкән, имамы куылган. Красный пахаръ поселогыннан имам Зәйнулла Галиуллин шул елда намаз укытмый башлаган. Наратлы Елга поселогында дин йорты 1929 елдан эшчәнлеген туктаткан, бинаны совет үзләштергән, азанчысы Сәхабетдин Шәрәфетдинов.

Элек Габдрахман волостенда саналган Чыршылы поселогыннан Зыятдинов Габделбарый, Вәли хуторыннан (Лениногорск районында булган дип фараз кылына) Гариф Зарипов 1926 елда имамлыктан киткән. Алар булмагач дин йортларын да җиңел генә ябып куйганнар. Гариф хәзрәт һәм хатыны Фатыйма абыстайдан совет йорт-җирләрен тартып ала.

Тымытык волостендагы Каен-Күл авылындагы мәчет 1929 елдан эшләмәгән.

Азнакай волостендагы Карамалы-Елга поселогында имам Сәлахетдин Кәримов, азанчы Габдулла Хәйруллин куркытылып намаз йортыннан читләштерелә, бинасы 1929 елда советка күчә. Октябрь Бүләге поселогы 1929 елдан дини йортсыз кала.

Бәйрәкә волостендагы Гыйльмановка поселогы имамы Ризван Әхмәтҗанов 1929 елда диннән киткән.

Баулы волостендагы Чатры һәм Габдерәзәк поселокларыннан азанчы Габдулла Ибатуллин, имам Хафиз Сәхабетдинов, Зирекле Елгадан Арслан Вәлиев 1930 елга кадәр мәчеткә йөрүдән туктаган.

Шөгер волостендагы Тукмак поселогында азанчы Әхмәтвәли Шаһивәлиевка һәм Карагай поселогында имам Сәлим Кәримовка намаз укытуларны туктатырга әйтелгән һ.б.

## Куакбаш авылы мәчете

Авылга 1730 елларда нигез салына. Билгеле булган беренче имамы Габделмәннаф хәзрәт. Җәмәгате Мөслимә абыстай исеме галим М.Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» китабында (1995 ел) кенәз Бигеш шәҗәрәсендә күренә. Күршедәге Түбән Чыршылыда изге чишмә – Мән-

наф чишмәсе бар. Бу исем бәлки Куакбаш мулласы исеменә бәйледер? 1853 елда авылда җәмигъ мәчет төзелгән. Әлеге авыл хәзерге Лениногорск районына керә. Төбәк тарихчысы Җ. Рәхимов фаразлары буенча: «Манарасыз мәчетләр (гыйбадәт йортлары) исә, П.С. Паллас, И.И. Лепехин, П.И. Рычков һ.б. язып калдырганча, безнең төбәк авылларында аларның башлангыч чорларында ук була. Авылда мәчет бар икән, димәк, анда башлангыч мәктәп тә бар.» Бөек фикер иясе, шагыйрь һәм галим, сәяхәтче суфый Габдерәхим Утыз Имәни (1754–1834) монда 1822–1823 елларда мәдрәсә салдыра, үзе дә шунда укыта, указы булмаса да имамәтчелек итә, борынгы кульъязмаларны җыю һәм эшкәртү белән шөгыльләнә. Аның күз буу (гипноз) осталыгы да булган диләр. Ул хәзерге Чирмешән районы Утыз Имән авылында (Яңа Кади) туган һәм Тимәш авылында җирләнгән. Безнең көннәрдә каберлеген табуда һәм анда истәлек төрбә куюны шагыйрь һәм композитор Разим Вәлиуллин (1942–2010) башлап җибәргән иде. Разим әфәнде сөйләгәннәрдән: «Утыз Имәнинең Лениногорск районындагы Тимәш авылы зиратындагы каберен яңартуда язучы Җәмит Рәхимовның (1935–1996), шәхсән үземнең, ул чорда Татарстан мәдәният министры урынбасары Габбас Мөхәммәтшинның һәм Лениногорск мәдәният бүлеге мөдире Гакыйль Вәлетдиновның хезмәте зур булды. Ун еллар (1984–1994) барган тырышлыкның нәтиҗәсе булып, изге кабер өстендә төрбә калыкты.» Дөрес, бу эшне соңыннан без башкардык дип, үзләренә «әҗер» җыючылар да күбәйде. Габдерәхим хәзрәт Оренбург Каргалысында, Бохарада укый. Хорезм, Сәмәрканд, Бәлех, Һират, Кабул, Мәзаре Шаһимәрдан кебек шәһәрләрдә яши, күп галимнәр белән аралаша. Мәгак шәһәрендә имам булып тора. Мәгърифәтче Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфәдел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында бу хәзрәтнең галим генә түгел, бик үзсүзле, тискәре кеше булуы турында да әйтелә: «Бохарада һәм Сәмәркандта чагында аның: «Имамнарның кыйраәтләре начар, үзләре наданнар», – дип, җәмәгать намазына чыкмавы әмир Шаһиморад бигә ишетелә. Әмир: «Ник намазга йөрмисең?» – дип сорагач: «Азан ишеткәнем юк», – дип җавап бирә. «Мөәзиннәр һәркөн намаз вакытларында ничә урында азан әйтәләр», – дигәч: «Мин ул тавышларны ишеттем, ләкин ишәк тавышы дип белдем» – ди.» Шулай ук Мәрҗани язуынча: «Җомга һәм гает укыр өчен Мисыр булу шарт, безнең илебездә Мисыр юк», – дип, җомга һәм гает укуларны, ә мәчет тәрәзәләре рамнарын «тәре» дип һәм мәчетне «чиркәү» дип, анда йөрүне ташлый». Шөгер мулласы Могыйнетдин бине Габдеррәшид моның «начар» гамәлләре турында дини идарәгә хат язган. Китапта шул сәбәбле указын алганнар диелә. «Заман сулышы» газетасында (7 март, 2008 ел) Р. Шәйхетдинов бик изге мәсьәләне кузгатып болай дип яза: «Аксакаллар Утыз Имәни

төзеткән мәдрәсә урынын ачыклады. Нигезе Мәдәният йорты бакчасындагы котельный урынында. Ул эшләми. Киләчәктә сүтеп алыначак. Әлеге тарихи нигезне мәңгеләштерүне күздә тотып, мин Татарстан республикасы мәдәният министры Зилә Вәлиевага хат юлладым. Министрлыкта минем тәкъдимне хуплаганнар. Министр урынбасары А. Җаббаровтан берничә җавап хаты килде. 2007 ел барышында мәсъәләне хәл итү юллары каралды, әмма кайбер каршылыклар килеп туды. Соңгы хатта Татарстанда 2008–2009 елларда монументаль сәнгать әсәрләрен төзү планы инде расланган, киләчәктә бу тәкъдим исәпкә алыначак, диелгән. Сүз Куакбашта шагыйрьгә бюст яисә истәлек ташы кую турында бара.» Моңа өстәп шуны әйтәсе килә. Казанга өмет итүнең ышанычы бик аз. Миңлебай авылы мисалында (Фатих Кәримигә багышланган монументаль истәлек такта) җирле халык, җитәкче авылдашлар үзләре тотынмаса, бу эшнең мәңге чынга ашасы юк. Иң беренче чиратта авыл зиратындагы борынгы ташларның язуларын күчереп алырга, аларны чүп-чардан, куаклыклардан тазартырга, ватылудан сакларга, аны авылга килгән кунакларга күрсәтерлек дәрәҗәгә китерергә. Кызганыч, без әлегә шунысын да эшли алмыйбыз бит. Сүз сөйләп кенә ерак китеп булмый шул!

Габдерәхим хәзрәт үзе ачкан мәдрәсәгә Гыймадетдин исемле сәләтле шәкертен хәлфә һәм мөдәррис итеп куя. Башкортстандагы үзәк тарих архивы буенча (Ф. 295, Оп. 3, Д. 5662) Гыймадетдин Котлыбаев 1847 елның 12 декабрендә имам җәмигъ, хатип һәм мөгаллим булып расланган. Аның улы Җамалетдин Гыймадетдинов 1860 елның 10 нчы февраленнән имам җәмигъ һәм мөгаллим. Гыймадетдин укытучысының фикерләрен, өйрәтмәләрен таратып аның эшен дәвам итә, китапларын күчереп күбәйтә. Утыз Имәниненең кызы Бибиҗамалга өйләнә. Дин галиме, мөфти Ризаэддин Фәхреддин «Асар» әсәрендә күрше Түбән Чыршылы мәдрәсәсендә укыганда Куакбаш мулласы Гыймадетдин Котлыбаевны күрүе, аларның нәселе турында бик кызыклы хәбәрләр язган. Үзебез ачыклаганча Гыймадетдин хәзрәтнең иң кече улы Мөхәммәтфазыл (1870–1950) Р. Фәхреддиннең шәкерте. Мөхәммәтфазыл аның киңәшен тотып, тирәнрәк дини гыйлем алу өчен Оренбург ягындагы мәдрәсәләргә чыгып китә. Тамак өчен казах байларына ялланып, салкын суларда йон юып, аякларына салкын тидереп, ничек булса да гыйлем туплап туган авылына олы дәрәҗәле указлы мулла булып кайта. Күршедәге Керкәле авылыннан Фәгыйлә исемле кызга өйләнеп Миннегаян, Сәгыйдә, Мөхәммәт исемле балалар үстерәләр. Ләкин бәхетле тормышлары бик тиз җимерелә. Авыл коммунистлары аны Бөгелмә төрмәсенә озата. Имештер ул анда болай дип әйткән: «Рәхмәт Совет властенә, барыбызны да тигезләде. Корбанга чалынган тәкә тиресе өчен ызгышып ята идек, менә хәзер барыбыз алдында

да өч бәрәңге». Бу сүзләрдән төрмәчеләрнең кәефе күтәрелеп аны өенә кайтарып җибәрәләр. Ләкин озакка түгел. 1930 елда аны йортыннан куып гаиләсе белән Златоуст ягына сөрәләр. Бу вакытта кызы Сәгыйдә Мәмәт авылы мулласы Габсаттар улы Габделвәлигә кияүгә киткән була. Соңыннан авылдашлары хәзрәтне сөргенгә барып алып кайта. Улы белән бергә йорт күтәрәләр. Хатыны, кызлары бер-бер артлы мәрхүм була. Мөхәммәт сугышта югала. Бабайның сөргендә туган оныгы, Миннегаян кызы Рафыйка гына кала. Рафыйка апа Әлмәттәге Бигәш мәчете имамы Әбүзәр хаҗи җәмәгате. Ә Сәгыйдәнең улы Әбүбәкер хаҗи Габсаттаров Мәмәттә мәчет салуны оештыручы. Ул Куакбашта күмелгән бабасы Мөхәммәтфазыл мулла каберлегенә куакбашлылылар ярдәме белән таш куйдырды. Гыймадетдин хәзрәтнең уллары Мөхәммәтзакир, Мөхәммәтсәлим, Мөхәммәтфазыл һәм Гыймадетдиннең оныклары, Җәләлетдин мулла уллары Мөхәммәтсәгыйть (1846–1921) белән Шиһабетдин (1856–?) Җәләлетдиновларның шул авыл имам-мөгаллимнәре булуын өлкән буын әле дә хәтерли. Җәләлетдиннең кызы Маһирә (1863–1930) абыстай күрше Түбән Чыршылы ишаны Мөхәммәтхәниф (1852–1930) бине Габделкаюм җәмәгате. 1930 елда 80 яшьлек ишанны кулга алып киткәч абыстай урынга егылган. Беренче мәхәлләдә борынгы Югары оч мәчетендә ике бертуган – 1896 елдан имам булып Шиһабетдин, 1885 елдан мәзин булып Мөхәммәтсәгыйть хезмәт иткәннәр. Алардан соң Мөхәммәтфазыл Гыймадетдин улы имам. Шул мәчет каршындагы мәдрәсәдә абыйлары Мөхәммәтзакир Гыймадетдин улы Котлыбаев мөгаллим. Мөхәммәтсәгыйть авылда җимеш агачлары, яшелчә үстерү белән дә дан казанган. Бакчасын сугару өчен Куак инешеннән кечкенә ермаклар ясап су үткәргән. Улы Әхмәтгатаның җәмәгате Туймәт авылыннан (Чирмешән районы) Рәшидә остабикә Куакбашта дин мәгърифәте таратучыларның берсе. Балалары Харис (1915–1944), Харрас (1914–2003) сугышта катнашканнар. Харрас яшли бик күп җәбер-золым татып яши. Бөгелмәдәге балалар интернатыннан «монда мулла калдыкларына урын юк» дип урамга куып чыгаралар, соңыннан туган авылында гомере буе укытучы булып эшли.

1903 елда Куакбаш авылыннан Самара губерна идарәсе төзелеш бүлегенә икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт сорап проект сызымнары керә. Аны бараз үзгәртергә яки яхшыртырга дигән таләп куела. Дөресләнгән проект 1904 елның 22 гыйнварендა раслау үтә (Самара өлкәсе архивы: Ф. 1. Оп. 12. ДД. 5698. Л. 5.). Мәчет шул ук елны төзелеп тә бетә.

Куакбаш волостенда 1910 елда 421 йорт, 1137 ир-ат, 1041 хатын-кыз, 3224 дисәтинә уңайлы һәм 235 дисәтинә уңайсыз җирләр, земский станция, волость идарәсе, урядник, һәр сишәмбе базар, Куак елгасы булган,

бередән почта юлы узган (Самара губернасының халык яши торган урыннар исемлеге. Самара, 1910 ел).

Икенче мәчеттә 1905 елдан Мөхәммәтзакир Гыймадетдин улы Котлыбаев имамәтчелек иткән. Улы Габделбарый да дини, дөньяви фәннәр остасы, шәкертләр укыта. Совет йортыннан куып чыгаргач, таш келәтен өй ясап тимерчелек һөнәрен үзләштерә. Авылдашларының кыерсытуларына түзә алмыйча һәм кулга алынудан шикләнеп төнлә гаиләсен алып авылдан чыгып кача. Алмалык дигән шәһәрдә яшәгәннәр дип сөйлиләр. Ташкент университетында бераз эшләгән дигән хәбәрләр дә бар. Мөхәммәтсәлим Гыймадетдин улы авылда ун еллап имамәтчелек кылган. 1908 елда Кустар тыкырыгында түбән оч мәчет-мәдрәсәсен төзеттерә. Мәчетнең юан, таза бүрәнәләрен хәзрәтнең хатынына мәһәр бүләге итеп бирәләр. Мәдрәсә төзергә дә хәзрәтнең кодалары булыша. Мөхәммәтсәлим хәзрәт 1920 елда сәнәкчеләр фетнәсе вакытында эзсез югала. Аннан соң имамлык Сәлимгәрәй Әсәдуллинга күчә. Гыймадетдин хәзрәтнең бердәнбер кызы Сафия Керкәле кешесенә кияүгә чыккан була. Куллары бозылып авырып киткәч ире, хатынын ике кызы Һәдия белән Вәсиләне Куакбашка аерып җибәрә. Вәсиләне Карабаш мулласы Габсәләм хатынлыкка ала, ә Һәдия әле беркадәр туганлык җепләре дә булган Мөхәммәтсафа Котлыбаевның улы Хәсәнгә кияүгә килә. Һәдия абыстай авылда гомере буена үз йортларында кыз балалар укыта. Бүгенге көндә Хәсән улы Гомәр кызы Кәүсәр апада (1934 елгы) бер изге Коръән китабы саклана. Ул аңа бабасыннан әмәнәт булып күчкән. Анда китап тышлыгының эчке ягында татарча түгел, ә саф гарәп телендә берничә юл язылган. Аны безгә Әлмәт мулласы Җәмил Халирахманов болай дип тәрҗемә итте: «Бу китапны Аллаһының Кәлим шәрифен сатып алды Ногман бин Бикмәт һәм үлгәннән соң аны алды Ногман бин Бәдигыльҗамал, аның кызына әмәнәт илә ирештерергә һәм безгә күчерергә Бәдигыльҗамалның васыяте белән 1832 елда рамазан шәриф аенда... Йә рабби, бу хатынны җәннәттә урнаштыр.» Шуннан чыгып әлеге китап Утыз Имәнинең икенче хатыны Бәдигыльҗамал абыстайда яки аның туганнарында сакланган дип әйтергә мөмкин. Утыз Имәнинең бер кызының исеме дә Бәдигыльҗамал, анысы Яңа Кадидагы Әхмәджан бине Фәзлуллага кияүгә китә. Кәүсәр апа изге китапны балаларына васыят итә. Үзе һәм ире сугыш ветераны Әнәс Җиһаншин (1926 елгы) авылда дини гореф гадәтләрне үтәүдә авылдашларыннан һәрдаим рәхмәт сүзләре ишетеп тора. Авылның элекеге мәчетләренә килсәк, Югары оч мәчете бүгенге мәктәп тирәсендә, Урта мәчет – мәдәният йорты урынында, Түбән оч мәчете – Кустар тыкырыгында урнашкан булган. Югары оч мәчетендә мәктәп, пионер бүлмәсе, китапханә ачылган. Манарасын 1938 елда җимергәннәр. Бинасы 1962 елда янган. Урта

мәчетнең манарасы киселмәгән. Ул склад буларак файдаланылган. 1970 елларда сүтелгән. Түбән оч мәчетенең манарасын яшен ташы сукканнан соң балта остасы Мөхәммәтша төзәткән. Манарсы 1938 елда киселә. Манара җимерүне авыл халкы бик авыр кичергән. Аны аудара алмый азапланганнар. Манара ае белән җиргә егылмыйча, аскы өлеше белән шуып төшеп мәчет кырына утырган. Узган гасыр башында таштан салынган мәдрәсә бинасы корылмасының ташларын, авылдашлар әле күптән түгел генә борынгы заман бабалары истәлеге итеп, бик тырышып хуҗалык максатларына ташып бетерделәр. Бу мәчетләрдә Сәлимгәрәй Әсәдуллин (1868 елгы), Мөхәммәтфазыл Котлыбаев, азанчы Мифтахетдин Хәсәнов, Мөхәммәтзакир Котлыбаев, өчбертуган Сәгыйть, Шиһабетдин, Мәхмүт Җәләлетдиновлар, мөгаллим Габделбарый Закиров һәм башка без белмәгән имамнар, мәзиннәр һәм укытучылар халыкка хезмәт иткән. Шиһабетдин хәзрәтнең улы Әнәс Мирасов (Мөрәс баба) Чупай авылында беркадәр муллалык иткәннән соң 1924 елдан Әлмәт авылының (хәзер шәһәр) өченче мәхәлләсенә имам хатыйплыкка указ алган. Бертуганы Мөгавия Мирасовны, «райколхоз» идарәсе эш башкаручысын «кулак бандитлар төркеменә катнашучы» дип 1931 елда 8 елга хөкем иткәннәр. Сәлимгәрәй хәзрәтне 1930 елда кулга алып 5 елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Ул шунда эзсез югала. 1990 елда акланган. Мөтәвәлли Сәлман мулла Галимов 1937 елда кулга алынып 5 елга хөкем ителә, шуннан туган иленә кайталмаган. 1992 елда акланган. Мәхмүт мулла Җәләлетдинов 1931 елда Себергә сөрелгән. Азанчы Мифтахның таларлык әйбере булмаган, мунчадан да кечкенә өтек бер йортта яшәгән. Гомере буе тимәсәләр ярар иде дип куркып, йөрәге авыртып яшәгән. Заманында бу авыл кешеләре 1920 елларда сәнәкчеләр хәрәкәтенә тулаем кушылып совет талауларына каршы чыкканнар, кызылларны авылга кертмәс өчен кара-каршы атышканнар. Ике яктан да күп кешеләр рәхимсез кырыла. Кызылларның җәза отрядлары өйләргә кереп, утырып торган кешеләргә кадәр атып йөргәннәр. Халыкның күбесе ачлыктан кырыла. Элекеге гөнаһларын да истә тотып 1930–1937 елларда большевиклар рекорд куеп Куакбаштан 60 лап кешене «кулак-бандитлар группировкасы» дип репрессиялиләр, халыкны дәүләт салымы белән изәләр, мәчетләрне ябып куялар, кем шул тирәдә йөрсә советка каршы баш күтәрүче булып саналган. Әлбәттә, монда совет чорында дин эшләре сүрелсә дә ул туктамаган. Мөхәммәтфазыл, Нух, Ходайфә бабайлар озак еллар дин сагында торганнар. Сугыш ветераны Ходайфә Гамилевнең (1905–1995) бабасы Җәләлетдин Гыймадетдинов. Гыймадетдин хәзрәт нәселе Куакбашта бер гасыр дәвамында Ислам мәгърифәтен сүндермичә бүгенге көннәргә китереп җиткергән. Аларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре булса иде.

1990 елларда бер мәҗлестә Гомәр Сәлманов белән Ходайфә бабай авылга мәчет кирәк дигән мөрәҗәгать белән чыгалар. Авылда кирпечтән ике катлы мәктәп төзелеп ята. Картлар иске мәктәп бинасының бурасы мәчеткә бик тә ярап куяр иде дип кызыгалар.Мәчет төзелешенә авылдашлар күмәкләшеп акча туплыйлар. Төзелешкә аеруча күп өлеш кертүчеләр Мөкатдәс Закиров, Гомәр Сәлманов, Әзһәр Галиев, Нәбиулла Шәйдуллин, авыл Советы рәисе Маһир Хәсәнов, колхоз рәисе Наил Галимов, Нәҗип Нуриев, Әдһәм Гарипов, Рәфкать Бәдриев, Данис Мансуров, Рөстәм Әхмәдиев, Рафис Закиров, Насыйх Зыятдинов, Гали Гәрәев, Камил Сөләйманов, Исмәгыйль Галимов, КПССның ул чактагы Лениногорск шәһәр комитеты секретаре Шәфәгать Тәхаутдинов, «Лениногорск нефть» идарәсе җитәкчесе Рафаил Нурмөхәмmәтов, Түбән Чыршылы урманчылыгы мөдире Вакказ Шәрифуллин, ЦДНГ-3 начальнигы Әгъдәс Исхаков һ.б.

Куакбаш мәчете союз таркалганнан соң районда иң беренче төзелгән гыйбадәтханәләрнең берсе. Бәлки шул сәбәпледер, ул вакытта әле әзер мәчет проектлары да булмый, архитекторлар да мондый мәсьәлә белән беренче генә очрашалар, урыны отышлы булса да мәчетнең манарасы бинаның бөтенлегенә, тигезлегенә тәңгәл килеп бетми. Ни генә әйтсәң дә, борынгы бабалары төзегән Куакбаш мәчетләренең матурлыгын, аларның илаһилыгын, узган заманның мәгъмари истәлеген ул әз генә дә чагылдыра алмаган. Хәтта, үрнәк өчен Ходайфа мулла улы Рәфкать ага Гамиловта Урта мәчетнең фотосурәте сакланса да. Хәер, моңа авылдашлар әллә ни гаҗәпләнми, иң мөһиме гыйбадәт кылырга урын бар ич. Бу авылдан бик күп бай түрәләр, җәмәгать эшлеклеләре чыккан. Аларның да моңа исе китми. Хәтта Гыймадетдин хәзрәтнең ерак оныклары булсалар да. Кайберләре Париж һәм Берлин урамнарында банан чәйнәп, туңдырма суырып йөрүләрен, шул илләрнең гүзәл архитектурасын күрүләрен мактанып, зур дәрәҗә итеп сөйләргә ярата. Урыс халкының «Увидеть Париж – и умереть» дигән әйтеме искә төшә. Андагы матурлыкка мөкиббән китеп үләргә кирәкми, ә үзләренең газиз бабалары истәлегенә дип, йөзгә кызыллык китерми торган бер манара, бәлки яңа мәчет салсалар ни була?

Куакбаш мәчетенең беренче имамы Мифтах Вафин, мәзине – Мөкатдәс Закиров, казначы Салих Җиһаншин. Бүгенге имамнары 2006 елдан Җәмил хәзрәт Сәхапов. Мәкаләне әзерләгәндә укытучы Мәмдүдә Вәлиуллинадан алынган мәгълүматлар, Минневәли Гомәр улы Хәсәнов әңгәмәләре, Харрас Сәгыйтов төзегән шәҗәрә, Самара архивы язулары, төрле чыганаклар файдаланылды.

Түбәндәге истәлек Минневәли Хәсәнов (1946–2009) сөйләгәннәрдән күчереп алынды: «Әтием Гомәр Хәсәнов 1900 елда туса да, аның кызыл-

армияче кенәгәсендә туган елы 1897 ел дип язылган иде. Ул Архангельскида акларга каршы зур бәрелешләрдә катнашкан ватандашлар сугышы каһарманы. Үземне дә язмыш җилләре шул якларга ташлады. Әтиемнең кызылармияче кенәгәсен Архангельск туган төбәк музеена тапшырдым.

Әтиемнең хәтерле һәм зирәк кеше булуына авылдашлар таң кала иде. Коръән китабын яттан белеп кенә калмыйча, авыл тормышының бик күп мизгелләрен ялгышмыйча сөйли. Аны тыңларга да күңелле, һәр сүзе киңәш, сабак. Сугышта күргән михнәтләрен ишетеп күзләр яшь белән тула. Ул ватандашлар һәм Ватан өчен сугышларда җиде ел үлем белән янәшә йөргән.

Чит җирләрдән ялга кайткан саен мин үзебезнең нәсел төбе турында сүз кузгата идем. «Зимагур» малаеның нәсел шәҗәрәсе белән кызыксынуы әтинең күңеленә хуш килде. Язмача тарихи истәлекләрнең, документларның яки кульязмаларның сакланмавы гына кызганыч. Ул чорлардагы гарәп графикасындагы бөтен язулар да юкка чыгарылды. «Искечә» язу-аралашу, чын тарихны белү катгый тыелды. Мәктәптә берәрсендә гарәпчә язылган дәфтәр яки китап табылса, гаилә башлыкларын гына түгел, ә бөтен укытучылар коллективына каты шелтә бирелә, куркытыла. Ата-бабадан калган язма мирасны укый да һәм саклый да алмадык. Буыннар арасын әнә шулай махсус өзеп куйдылар. Әмма соңлап булса да тарихны беләсе килә, күңел шулай куша. Гаиләбездә тугыз бала үстек. Әти мәдрәсәдә укыган кеше, безгә дә гыйлем бирергә тырышты. Әбием Һәдия (әтинең әнисе) узган гасыр башында үз өендә кыз балаларны укырга-язарга, Ислам дине кагыйдәләренә өйрәткән. Һәр укучы кыз түләү шартыннан бер утын күтәреп килә торган булган. Балалар шулай бервакыт караңгыда күрмичә утын дип белеп, кемнеңдер келәтеннән туңган тана ите – бот күтәреп килеп әбинең ишек алдында калдыралар. Әби ботның хуҗасын табу өчен ярты авылны урап кайта. Һәдия әби мәшһүр шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең оныгы. Шул әдип китапханәсеннәндер мөгаен, Коръән китабы апам Кәүсәрдә саклана.

Әтинең әтисе Хәсән бабай Мөхәммәтсафа Котлыбай улы гаиләсендә 1868 елда соңгы бала булып туа. Бик яшьли ятим калып иң олы бертуганы, кырыс холыклы, әмма гадел булган Мәгъсүм абзыйсында тәрбияләнә. Мәгъсүм Котлыбаев Самара губернасы Бөгелмә өязе Кузай волостенда урман хуҗалыгында хезмәт итә. Алар гаиләләре белән «казенный» йортта Кузайда яшәделәр. Бу авылда мордва халкы көн күргән. Хәсән бабай алар телендә яхшы сөйләшә дә белгән. Бабай янына Кузайдан дусты Илья бабай бик еш килгәли иде. Без малай-шалайлар, аның зур сакалына, авызыннан ап-ак куе төтен чыгаруына исебез китеп карап тора идек. Татар авылында тәмәке тартучылар юк иде бит.

Хәсән бабайның әтисе Мөхәммәтсафа алдынгы карашлы фикер иясе булгандыр дип уйлыйбыз. Олы улы Мәгъсүмгә урысча белем алырга булышып, унтугызынчы гасыр урталарында дәүләт хезмәтенә лесничий итеп урнаштыра алган. Мөхәммәтсафаның әтисе Котлыбай исемле. Миңа өч бертуганның исеме билгеле: Котлыбай, Бикмөхәммәт, Ишмөхәммәт. Алар барысы да Мөрәс баба балалары. Куакбаш авылында безнең нәсел агачы аннан башлана. Бу унсигезенче гасыр. Әле авылның нигезләнеп кенә килгән еллары. Мөрәс бабай урман кисеп чәчүлек җирләре ясаган, иген иккән, балаларны һәм өлкәннәрне Исламга өйрәткән. Мөрәс үзенең ир туганнары белән озак еллар Бохарада укыган. Бәлки Бохарада укыганда Мөрәс белән Утыз Имәни яхшы таныш булганнардыр. Аларның икесенең дә Куакбаш авылына килеп чыгулары, мөгаен, очраклы хәл түгелдер.

Мөрәснең әтисе Морат морза. Аңа морзалык дәрәҗәсен әби патша Екатерина икенче Пугачев фетнәсе вакытында хөкүмәт гаскәрләренә кешеләр һәм икмәк белән ярдәм иткәне өчен биргәннәр дип сөйлиләр. Кешеләре һәм бирерлек печәне, икмәге булгач, бәлки ул аңа кадәр үк инде морза дәрәҗәсендә йөргәндер. Морзаның хәзер Әлмәт районы Колшәрип һәм Мәмәт авыллары янәшәсендә утары булып шактый җирләр биләгән. Шул тирәдәге Мәмәт авылындамы Морат инеше яки чишмәсе бар икән. Бу исем әлеге морза исеменә бәйледер мөгаен. (Д. Таҗи искәрмәсе: Әмма, икенче бер шәҗәрәдә Морат исеме юк. Бабалар исеме: Акташ–Бикташ–Үкташ–Мөрәс–Котлыбай–Гыймадетдин. Чын дөреслекне Мәскәү архивларында эзләп карарга кирәк).

Морат морза балаларын Бохарага укырга җибәрә. Күп тә үтми хатыны үлеп, яшь бичәгә өйләнә. Морзаның кәләше тән сакчысы белән бер-берсен яратышалар. Тән сакчысы хуҗасын үтерә. Мәрхүмнең гәүдәсен уртасы улак булып черегән калын усак эченә яшерәләр дә хуҗа сәүдә эшләре белән кайдадыр китеп барды дип ялган хәбәр тараталар. Җинаять берничә айдан ачыклана. Үтерүче гәүдәнең кайда яшерелгәнен күрсәтә. Ни гаҗәп, гәүдә аз гына да таркала башламаган икән. Моратны шәригатьчә олылап җирлиләр. Ә гашыйкларны Себергә олактыралар. Имештер шул шомлы вакыйгалар тынарга да өлгерми, татарларны янә чукындыру хәрәкәте башлана. Җир өчен алданып чукынган крәстиәннәргә әз-әзләп морзаның җирләрен бүлеп бирәләр. Чукынучыларны ислам динендә калган кардәшләреннән аерып Кәләй авылына күчерәләр. Моратның улы Мөрәс, оныгы Бохарадан укып кайткач атасының җирләренә хокукын яклап патшага, сенатка хатлар язып карый. Тик җавап бер генә була: «Закон обратной силы не имеет, земли у новокрещенов отобраны быть не могут». Нәкъ шул сәбәпледер, Мөрәс Колшәрипкә яки Мәмәткә урнашмыйча Куакбашка китәргә мәҗбүр була».

Минневәли абый сөйләгән тарихи вакыйга гасырдан гасырга күчеп бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән. Морат морзага кагылышлы берәр мәгълүмат табып булмасмы дип бөек якташыбыз Ризаэддин Фәхреддиннең мәшһүр «Асар» китабын кат-кат укып чыгам. Галимнең ерак бабасы Юлдаш бине Ишкәй дә истәлектә телгә алынган җирләргә чукындырудан качып килеп хәзерге Кичүчат авылына нигез салган. Аның Морат исемле улы да булган. Минневәли абый истәлегендә шул Морат турында сүз барса да, әллә ни гаҗәп булмас. Чөнки телгә алынган ике Морат та истәлекләрдән күренгәнчә бер үк географик урыннарда яшәгәннәр бит. Юлдаш бабай шәҗәрәсендә дәрәҗәле исемнәр күрсәтелгән. Кайбер тарихчыларның китапларында шәҗәрәдәге Юлдаш бабайның ерак бабасы Кайбуллага (Хәбибулла) Казан патшабикәсе Сөенбикәнең кызы (исеме билгесез) кияүгә чыккан дигән хәбәрләр очрый. Шул ук шәҗәрәдә Кармыш бине әл-Болгари бине Тансар исеме бар. Бу Кармыш баба 1551 елда хыянәтче Шаһ Гали хан тарафыннан үтерелгән 71 күренекле кешеләр исәбендәге яугир милли каһарман Карамыш оглан түгел микән? Иншалла, галимнәр бу сорауга җавап табарлар дип ышанасы килә.

## Югары Чыршылы (Чәшеле) мәчете

Бу авыл 1785 елдан билгеле. Авыл тарихы китабында 1724 ел күрсәтелә. Беренчесе дөреслеккә якынрак дип фараз кылына. Авылны хәзерге Чирмешән районы Утыз Имән, Кәминкә авылыннан, шулай ук башкорт ягыннан килгән гаиләләр нигезләве турында «Чәшелем – асыл илем» китабында (З. Насыйбуллин, Ә. Ямаева) әйтелә. Монда башкорт һәм мишәр зиратлары булуы да шуңа ишарә.

Авылда 1860 елдан мәчет булуы мәгълүм. Самара дәүләт архивы мәгълүматлары буенча (Ф. 1. Оп. 12. Д. 4480.) беренче җәмигъ мәчет 1878 елда ачылган, мәдрәсә эшләгән. Бу мәчет искерү сәбәпле аның урынына яңасын төзү өчен Самара губерна төзелеш идарәсе 1906 елда бинаның яңа проектын раслый. Шул ук елны мәчет төзелеп бетә. Монда 1853 елдан Гыйльман Мөхәммәткәримов имам мөгаллим, 1903 елдан Ризаэддин Низаметдин улы Ярмәкәев имамәтчелек итә. Шул ук кеше булса кирәк Уфа губернасының 1912 елгы адрес календаренда (1912 елда Уфада басылган) ул Минзәлә өязендәге Әлмәтмулла волостенда старшина. Бөгелмә өязендә ахун дәрәҗәсендәге шәхес. Соңыннан Үзбәкстанда дин эшләре идарәсендә эшләгән дип ишеткәнебез бар. Самара губернасының 1914 елгы Истәлек кенәгәсендә (1914 елда Самарада басылган) аның улы «Зыятдин Низаметдин улы Ярмәкәев Түбән Чыршылыда «кредитныя товарищества» идарәсе рәисе» диелгән. Бабалары Самара ягындагы атаклы Иске Ярмәк авылыннан. Әлеге мәчеткә 1925 елда мәзинлеккә Габделбарый Сабирҗанов билгеләнгән. Икенче җәмигъ мәчет 1911 елда ачыл-

ган, мәдрәсәсе 1912 елдан эшләгән. Мәчетне Кичүчат авылыннан балта остасы Магыйҗан бабай салган. Ул елларда дәүләт кәнсәләрендә кайбер мәдрәсәләрнең вакытында яки бөтенләй теркәлмәвен дә танырга туры килә. Бу мәчеткә Мәхмүт Кәшәфетдинов (1880) имамлыкка билгеләнгән. 1901 елдан указы булган. Мәчетләр «түбән очныкы», «югары очныкы», беренче яки икенче мәхәлләнеке дип аталып йөртелгән. Түбән оч мәчете бик матур булган диләр, ул 1926 елда янган. Имештер, нигезендә снаряд шартлаган. Заманында авылның тау итәгендә Пугачев фетнәчеләренең (1773–1775) корал склады булган, снаряд нигез ташы куйганда ялгышлык белән эләккән булырга тиеш диләр. Дөреслеккә иң якыны, мәчетне махсус яндырганнар дип әйтеп була. Югары оч мәчете безнең көннәргә кадәр манарасы киселмичә сакланган. Искереп черүе сәбәпле сүтелгән.

Түбән Чыршылы волостена кергән Югары Чыршылыда 1910 елда 237 йорт, 618 ир-ат, 621 хатын-кыз, 1034 дисәтинә уңайлы һәм 82 дисәтинә уңайсыз җирләр, 1 мәктәп, 2 су тегермәне, Чыршылы инеше булган (Самара губернасының халык яши торган урыннары исемлеге. Самара, 1910 ел).

Исемнәре ачыкланган дин әһелләре. Монда 1841 елда булачак ахун Гыйльман Ибраһим улы туган. Түбән Чыршылы, Чистай мәдрәсәләрендә укыган. Кичүчат мулласы Фәхреддин хәзрәтнең кызы Мәгъсүмә белән никахланган. Бераз үз авылында имамлык иткәннән соң әнисе Фатыйма абыстайның туган авылы Миңлебайга 1870 елда указлы имам хатыйп булып урнаша. 1902 елда Оренбургта мәрхүм. Улы танылган галим, репрессия корбаны Фатыйх Кәрими (1870–1937). Кайбер мәгълүматлар буенча Гыйльман ахунның әтисе Ибраһим Мөхәммәдкәримов бертуганының исеме дә Гыйльман исемле, ул да Мөхәммәдкәрим улы. Мөхәммәдкәрим хәзрәтнең Иштирәк авылында имам булып торуы «Асар» китабында әйтелә. «Фатыйх Кәрими» фәнни-биографик җыентыкта (2000 ел) Ибраһимның әтисе Юмәт, аның әтисе Габделкәрим диелгән. Юмәтнең Ибраһим, Ихсан, Габдерәхим исемле уллары булган. Чыршылы мулласы Гыйльман турында бер сүз юк.

Югары Чыршылыда Бәдретдин бине Могыйнетдиннең (Иске Шөгердән дип уйлыйбыз) яшәве мәгълүм. Могыйнетдин хәзрәтнең Бәдретдин исемле ике улы булган булса кирәк, бәлки башка никахтандыр, исемнәрнең охшаш булуын да инкаръ итәргә ярамыйдыр. «Асар» китабы буенча Бәдретдин ир туганы Шиһабетдин белән Казанда Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә укыганнар. Шиһабетдин атасы Могыйнетдин вафатыннан соң Шөгердә имам, Бәдретдин исә Истанбулга кадәр китеп барган, 1890 елда Басра шәһәрендә үлгән. Икенче Бәдретдин турында китапта сүз юк. Монысы хакында метрикә дәфтәрләреннән күчереп алын-

ган язмаларда күрәбез (Р. Сәлмановадан алдык): «Никахлашалар Югары Чыршылы авылының Бәдретдин Могыйнетдин улының 19 яшьлек кызы Миңлезифа (1885) һәм Түбән Чыршылы авылының 24 яшьлек Мөхәммәтшаһ (1880) Хәсәншаһ улы. Кыз ягыннан вәли вәкил Бәдретдин Могыйнетдин улы. Кыз ягыннан вәли вәкил Хәсәншаһ Габделгалләм улы. Ризалык шаһитләре Гайса Могыйнетдин улы, Миңлехәер Могыйнетдин улы, Хәбибетдин Нәҗметдин улы. Вакыты 16.02.1904. Мәһәр күләме 80 сум көмеш. Никахны Ризаэтдин Низаметдин улы Ярмәкәев укыды». Икенче язмада Бәдретдин күршедәге Куакбаш авылында итеп күрсәтелә. Кызы Гайникамалны Кирлегәч егете Афзалетдингә кияүгә биргәннәр. Вакыты 03.03.1910. Никахны шул ук мулла укыган. Мулла абзый никах укырга дип Чыршылыдан Куакбашка килгән булып чыга. Шөгер мулласы Могыйнеддин хәзрәт Түбән Чыршылыда Гыйсмәтулла мулла кызы Фәхриҗамал белән 1822 елда никахланган. Могыйнеддин (1803–1874) бине Габдерәшитнең Куакбаш авылында яшәгән мәгърифәтче Габдерәхим Утыз Имәни (1754–1834) өстеннән, аның «сәер гадәтләрен» тәнкыйтьләп жалу язганнар, хәзрәтнең указы алынып урыныннан куылган. Могыйнетдиннең бертуганы Гыйсаметдин Шөгернең икенче мәчетендә имам, икенче бертуганы Фәридетдин (1808–1886) 1836 елдан Бигәш авылы имамы.

Авылда икенче мәхәлләдә Минһаҗетдин Фәхретдинов та (1843–1930) бераз имамәтчелек кылган диләр. Ул 1866 елдан Мәмәт авылы имамы. Улы Гаязетдин 1928–1930 елларда Югары Чәшеле имамы. Гаиләсе: кызы Маһинур (1924), кызы Мөкәрәмә (1927) һәм тагын 4 гаилә әгъзасы. Гаилә 1930 елда Шөгер РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 1998 елда акланганнар. Соңыннан үзе кулга алынган дигән хәбәрләр бар, гаиләсе Карабаш бистәсенә күчеп киткән. Өстә телгә алынган Мәмәт авылы мулласы Кәшәфетдин (1853–1894) хәзрәтнең улы Мәхмүт икенче мәхәлләдә имамлык иткән дидек. Минһаҗетдин һәм Кәшшәфетдин хәзрәтләр мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең (1859–1936) абыйлары. Мәхмүт хәзрәт соңгы көннәрен Төрекмәнстан илендә яшәгән.

Югары оч мәхәлләсендә инкыйлап алдыннан Шахгаттар Садретдин улы Габделгазизов хезмәт итә. Түбән Чыршылыдан Мөхәммәтхәниф ишан кызы Рәшидәгә никахланган. Совет җаһалияте елларында яше сиксәнгә җитеп килүче Хәниф ишанны кулга алу аңа тетерәндергеч тәэсир ясый. Шахгаттар кулга алынудан куркып гаиләсе белән Самара, Барнаул якларында йөреп Төрекмәнстанда яши. Соңгы көннәрендә Ашхабадта балалары тәрбиясендә яшәп 66 яшендә 1957 елда мәрхүм.

Авыл коммунистлары Югары оч мәчетен ничек кенә булса да мөселманнардан тартып алырга, анда склад ясарга яисә утынга сүтәргә тырыш-

каннар. Авылның элекеге старостасы мулла Әхмәтҗан бабай Иксанов халыкны бердәм оештырып мәчет манарасын җимертүдән саклый. Бабайны төрлечә мәсхәрәләп берничә мәртәбә кулга алып, Бөгелмә зинданында ач тотып кыйнап кайтаралар. Ватан сугышында биш улы да һәлак була. Бу хәсрәтне ул күтәрә алмый, паралич сугып тугыз ел урын өстендә ята. Шул 1930–1931 елларда гына да «динне яклап йөрүчеләр, колхозга каршы баручылар» дип, бер төркем авылдашларга, Шәяхмәт Гыйльмановка (1889), Мөбарәкша Гаделшинга (1900), Мөхәммәди Латыйповка (1868), Ризаэтдин Ризвановка (1880), Сахап Ризвановка (1894), Нуретдин Зәйниевка, Рамазан Хәсәншинга, Закир Баһмановка (1880) гаепләү белдерелгән. Икенче мәхәллә имамы Самат Кашапов (1879) 1930 елга кадәр үк үз вазыйфасын ташларга мәҗбүр ителгән, йортын талап алганнар. Мәмәт авылында да имам булып торган. Архив документлары буенча бу кешенең Габделсамат Кәшәфетдинов Фәхретдинов булуы ачыкланды. Ул Кәшәфетдин мулла улы.

Өстә телгә алынган авыл имамы Гыйльман Мөхәммәдкәрим улы алдынгы карашлы мәгърифәтчеләрнең берсе булган. 1902 елда 76 яшендә вафат. Самара ягындагы Келәүле районы Камышлы авылыннан 1885 елда килгән диләр. Шулай ук нәсел тамырлары Ютазы районы Бәйрәкә авылына да барып тоташа. Хәзрәтнең уллары Хаҗип белән Сабирҗан да (җәмәгате Маһирә остабикә) муллалык эшендә йөргәннәр. Сабирҗанның уллары мәзин Габделбарый (җәмәгате Бәрия абыстай) белән Зөфәр хәзрәтләрне авыл халкы әле дә онытмаган. Хаҗип мулла 1927 елда вафат. Улы Миңлеһади шулай ук совет чорында дин сагында торып 1963 елда вафат. Авылдашлар күңелендә мәңгелек бер истәлек саклана: «Сугыштан соңгы авыр елларда Һади бабай авылдашын күмәргә бара. Өйдә ике ятим бала, ач, ялангач, елашып почмакта туңып утыралар. Мәрхүмнең ике тuганы, аннан калган тунны бүлешә алмыйча тарткалашалар икән. Мулла абзый моны күреп аларны туктата да, мәрхүмнең хатынына, җыелган халыкка әйтә: – Мин җеназа укыйм, миңа гүр сәдакасы тиеш, бу тунны сәдака итеп алам, – ди. Шулардан тунны ала да мәрхүмнең балаларына бирә».

Һади бабайның улы Рәшит Хаҗипов (2001 елда мәрхүм) оештыруында 1995 елда авылда агач йортта, калай манаралы мәчет ачылды. Бүгенге имамнары Мифтах Сәгъдиев.

Хәзерге Ютазының имам хатыйбы – Фатыйх Зәйнуллин Югары Чыршылыда туган. Шунда мәчет салдырган.

Узган гасыр башында авыл мулласы Солтангали бабай («Хаҗи бабай») Заһидуллин (1854) хаҗга барган. 1933 елда кулга алынып шартлы рәвештә 5 елга хезмәт белән төзәтү лагерына җибәрелүгә хөкем ителгән.

1989 елда акланган. Улы Габдрахман Солтанов Түбән Чыршылыда муллалык иткән. Габделгани бай 1904 елда хаҗга чыгып киткән.

Мәкалә өчен архив материаллары, табылган истәлекләр, «Асар» китабы, Р. Абзалова-Сәлманованың кулъязмасы файдаланылды (матбугатта басылмаган).

Безнең көннәргә кадәр йөз елдан артык торган мәчет урынына шушы авыл кызы «Иманлы төбәк җәүһәрләре» китабы авторы Роза Абзалова-Сәлманова (1950) авылдашлары ярдәме белән 2004 елда тимер баганага беркетелгән истәлек тактасы (3\2) яки хитапнамә куйдырды. Әмма аны рухы зәгыйфь бәхетсез бер бәндә җимереп ташлаган. Бу изге урын киләчәктә рәшәткәләр белән тотып алынса яхшы булыр иде.

*(Дәвамы бар)*

*Р.А. Бушков*

*Традиционный чай по-татарски не представляется без самовара. Этот уникальный водонагревательный прибор являлся символом чаепития не только в Татарстане, но и в России в целом. Первые самовары в ней появились на Урале – крупнейшем металлургическом центре империи, где их стали изготовлять вместе с другой медной посудой с 1740-х гг. Отсюда он попал в тесно связанную с Уралом и Сибирью Казань. В другие города Европейской России самовар проник уже после основания в 1778 г. первого самоварного завода в Туле. Превратившись в самоварную столицу России она снабжала им пол страны. Однако, спросом у казанцев в конце XIX в. пользовались также самовары, изготовленные местными мастерами. Известность у них получили отмеченные за свою продукцию медалями различных промышленных выставок кукморская и две казанские самоварные мастерские. Об этом и рассказывает историк народной кухни, этнограф, кандидат исторических наук.*

## У ПОЮЩЕГО САМОВАРА



*Фоторепродукция натюрморта с самоваром Резиды Юсуповой.*

Шумно худжуш закипает,
Чай заварить призывает,

*(Перевод Р. Бушкова)*

– отозвался о распространившемся с конца XVIII века приготовлении татарами чая в баите «Чәй бәйете» («Баите о чае») татарский поэт и религиозный деятель Мухаммадшариф. Заваривался чай кипятком из особого чайного прибора с внутренней топкой, прозванного русскими самоваром. Стихотворцу казалось, что правильнее было бы назвать его на восточный манер «худжушем», переводящемся с персидского как «самокипец». Ведь воду в нём кипятили, а не варили, как еду.

Издревле сосудом для приготовления еды и питья для многих народов был котел. Благодаря ему китайцы открыли чай, когда в кипящуюся в нем воду видимо случайно упал чайный лист. В железном котле варили еду и кипятили воду предки казанских татар – волжские булгары. По преданьям, именно по оброненному в реку дорожному котлу получила свое название Казань.

Уронила девушка
в речку золотой казан,
и поднялся город высоко – Казань, –

скажет об этом столетия спустя казанский поэт Рустем Кутуй. Котел, по легенде, был зарыт под первую постройку Казани, в знак ее будущего изобилия и богатства.

Не представлялась без котла и татарская подовая печь, служившая одновременно для отопления жилья, приготовления горячей пищи и выпечки хлеба. В отличие от нее русская духовая печь обходилась без котла. Еду и питье готовили в ней в специальных глиняных горшках. В этом кухонном сосуде-водогрее, если верить шуточной народной песне, даже заваривали чай.

Раз послал мне барин чаю
И велел его сварить,
А я отроду не знаю,
Как проклятый чай варить.

Взял я чай, на скоро руку
Весь я высыпал в горшок.
Для приправы – перца, луку
И петрушки корешок,

На таган я чай поставил,
Раза три прокипятил,
А потом для украшенья
Крошку маслица подлил.

«Чай готов, извольте кушать»,–
Тут я барину сказал.
«Молодец, такой послушный,
Ты всегда так исполняй!
А на праздничек, понятно,
Подарю рублишек пять».

Пять рублей – ведь это много!
С ними можно погулять,
И Акулька – недотрога
Меня будет уважать.

Слышу, барин расходился,
Меня в горницу позвал,
В волоса мои вцепился
И таскал меня, таскал.

Долго думал, удивлялся:
Чем не мог унаровить?
А потом уж догадался –
Чай забыл я посолить! –

рассказывалось в ней устами дворового слуги о его первом опыте приготовления этого заморского диковинного напитка.

Горшки были разных размеров – от огромной корчаги до маленького горшочка. На железоделательных заводах на богатом на железную руду Урале и в Сибири горшок начали производить из чугуна, дав ему наименование чугунника, чугунца и чугуна. Первые такие мануфактуры появились при участии думного дьяка Андрея Андреевича Виниуса, сына заложившего в 1632 г. под Тулой первого в России железоделательного завода голландского купца А. Виниуса. На основанном им Невьянском заводе на Урале 15 декабря 1701 г. состоялась первая выплавка чугуна в России.

Невьянский завод перешел потом в руки Акинфия Демидова – потомка предприимчивого тульского ружейного мастера Никиты Демидыча Анту-

фьева. Он выдвинулся при царе Петре I. Демидовы в 1720 г. получили дворянство, стали владельцами десятков железоделательных и медеплавильных мануфактур. В них и появившихся следом других таких заводах на Урале делали «железо разных рук». Производимые ими литые чугунные горшки стали принадлежностью домашних подовых печей и главной поваренной посудой, в которой теперь приготовляли еду. В них при желании можно было греть и кипятить воду от печного огня и жара и даже заваривать чай. Этой утварью награждал за труды рудоискателей из татар и башкир В.Н. Татищев, будучи в 1720–1722 гг. горным начальником над казенными уральскими и сибирскими металлургическими заводами.

Помимо чугунных горшков на уральских железоделательных заводах освоили производство домашней посуды из красной меди, прежде всего дорожного плоского сосуда с двумя ушками баклаги, большого медного чайника для нагрева и кипячения воды, чайного котелка и чайничка для заваривания чая. Водогрейный большой чайник и баклага нашли спрос у сбитенщиков, торгующих на городских площадях, базарах кипятком и горячим сбитенем – старинным русским напитком. Он приготовлялся из меда с лечебными травами и пряностями. Его готовили в громоздком котле или чане, куда по трубам подводился жар от железного короба с углём. Варил сбитень кипятильщик или варец в сбитенном шалаше – курени. Готовое питье разливали в большие чайники и баклаги, и сбитеньщики шли продавать из них сбитень на базаре и городских площадях. Наиболее бойко торговля сбитнем шла зимой, особенно в праздничные дни. Дабы дольше сохранить его горячим, сбитеньщики закутывали чайник и баклагу в холщёвую материю или тряпье. На уральских заводах додумались делать самогрейные баклаги и чайники с топкой и трубой извнутри. Топка закладывалась по трубе горячим углем, и жар от нее нагревал и кипятил налитый в сосуд сбитень. А потом заводские мастера произвели новую поваренную водонагревательную утварь – самоварец, металлический четырехугольный или круглый сосуд на ножках с топкой и трубой посредине. Схожий по устройству с самогрейными баклагой и чайником он унаследовал от них внутреннюю трубу для угля и поддувало с подставкой. А внешне самоварец принял форму листового котла, короба-кипятильника и кувшина.

Самовараец породил еще один «самоварящий» прибор – самовар. Главной в самоваре стала прозванная кувшином топка – кипятильник, обеспечивающий жаром температуру для кипячения воды. Его закрепляли по центру резервуара – тулова и заканчивали снизу решеткой. Внизу тулова для усиления тяги устраивалось поддувало, опиравшееся на поддон и покоившееся на ножках – опорах. На тулове устанавливали подвижные ручки-вертлюги и кран с веткой-ключом в виде отходящего в сторо-

ну изогнутого стебля. Место его крепления обрамляла пластинка-репеёк. Тулово закрывали крышкой с двумя шишками-захватами и паровичками на отверстиях на ней для выхода пара. Венчала самовар прикрывающая кувшин крышка-колпачок. Варом из самовара, то есть вскипяченной в нем водой, чай заваривался в заварочном чайнике. Сибиряки определяли его количество щепоткой и в шутку прозвали «варькой». Самовар стал первой русской домашней принадлежностью на фоне перенимаемой из Европы модной кухонной наплитной утвари.

Впервые письменно самовар упомянули приказные служители Екатеринбургской таможни в составленном ими донесении от 7 февраля 1740 г. о задержании на Уткинской пристани шести «незаконных» подвод. Они следовали из Верхне-Иргинского завода без уплаты пошлины в обход Сибирской дороги. При их досмотре и обнаружился «самовар с прибором медный, луженый, весом 16 фунтов заводской, собственной работы». Через пять лет самовар попал в «*Реестр, какое число сделано и отдано господину Григорию Акинфовичу брату Никиты Акинфовича разных званием медной посуды в 1745 г. и по какой цене в продажу производится*», а еще год спустя – в «Опись имущества Онежского второклассного монастыря», где были упомянуты «два самовара с трубами зеленой меди». Самовары вместе с производимой на уральских заводах хозяйственной посудой продавались в основном на Ирбитской ярмарке. Отсюда они расходилась по Уралу и Сибири.

В Европейскую Россию самовар проник не сразу. Не считая Казани, куда железоделательные заводы Урала поставляли якоря для учрежденного в 1718 г. по указу Петра I Казанского адмиралтейства. Здесь хорошо расходилась и другая медная посуда, особенно медные чайники с заводов Строгановых и балахнинского купца Петра Гавриловича Осокина. Его родная сестра Федосья Гавриловна была замужем за И.Ф. Дрябловым, унаследовавшим Микляевскую мануфактуру. Она перешла после его смерти записанному казанским купцом его племяннику и сыну брата жены Ивану Петровичу Осокину.

Возможность увидеть самовар представилась курьеру Коллегии иностранных дел китаеведу А.Л. Леонтьеву во время поездки в Пекин в 1763 г. Маршрут его проходил через приграничную торговую слободу Кяхту, куда уже проник этот нагревательный прибор и получил признание в купеческой среде. Как человек, десять лет пребывавший в свое время в составе Российской духовной миссии в китайской столице, он находил в нем сходство с китайской чашей хо-го с трубой, поддувалом и поддоном, в которой приготовляли бульон и суп. Он напоминал также монгольський латунный «огненный горшок» с трубой в центре, а еще больше – появившуюся в Европе кухню – самовар, используемый при приготовлении пищи.

Но свое знакомство с русским самоваром А.Л. Леонтьев оставил без последствий. Он посчитал его скорее забавой, чем необходимым чайным прибором. К тому же относил себя к сторонникам классического китайского чаепития с соответсвующим набором чайных приборов и посуды отнюдь не из меди. Потому без упоминания о самоваре вышла в свет подготовленная им ученая брошюра на русском языке «Уведомление о чае и шёлке», изданная в 1775 г. в типографии Императорской АН в Санкт-Петербурге. В ней на основе китайской литературы излагались общие правила приготовления чая с использованием необходимой для этого посуды. «Чайник с водою во-время на жар поставить, как уже уголье вовсе покраснели, постановя чайник, тотчас раздувать уголье махавкою, помахивая полегоньку, и при том скоренько; а как скоро в чайнике от закипания звук слышен, то помахивать махавку прытче, до того времени, как пора придет чайник долой снять, – разъяснял он в разделе брошюре «Как на чай воду варить?». – Жар надобен прежде умеренный, а по тому по малу увеличенный, ради того, чтобы вода свою (для чая) посредственную силу возимела; ибо, когда жар очень мал, то вода будет слаба (хотя кипела) и может от чаю побеждена быть, а когда жар велик, будет очень сильна, и победительница над чаем, а нам надобно, чтобы как вода, так чай своих умеренных действий не лишились, чобы было между ими согласное средство».

К выходу его брошюры любители чая уже уяснили, что качество заварки – горечь чая, вкус и аромат – напрямую зависят не только заварки, но и воды, даже от точек кипения вара. Это говорило уже об определенной культуре чаепития. Потому А.Л. Леонтьев включил в неё раздел «Как кипучую воду распознать?», где советовал определять это «по виду: когда на воде появились пузырьки подобные рыбьим или раковым глазам, в то время начинает закипать, а когда показались струи, волны, быстрой разлить, то знать надобно, что вода совершенно поспела и всей своей скорости лишилась», «по звуку: когда слышно подобие трескучего стука или бегучего топота, закипать начинает, а по сем, как уже ничего не слышно, то совершенно поспела» и «по пару: когда от воды в верх поднялся пар лоскутьями, по одному, по два и более, закипает, а как пар в-верх прямо столбом пошел, совершенно поспела».

Эти сведения, по признанию А.Л. Леонтьева, были почерпнуты им из «китайской книги, Вань боу Кюань называемой». Но в ней легко угадывались лежащие в ее основе выписки из первой китайской чайной энциклопедии «Ча-цзинь» («Канон чая»), составленной поэтом и философом Лу-Юйем еще в VIII в. А разделы «Как на чай воду варить?», «Как кипучую воду распознать?» и «Из чего чай пить?» представляли по сути извлечения из этого знаменитого сочинения.

Находясь под впечатлением от них А.Л. Леонтьев рекомендовал в главе «Чайник, в коем воду греть?» «употреблять серебреной или оловянной, или глиняной, а медный и железный к сему не годятся». По его мнению, металл может легко испортить вкус воды при кипячении. Потому он предлагал заваривать чай в фарфоровых чашках-гаванях, как китайцы, которые «положа щепоть листьев в чашку чайную, наливают на чай кипучую воду, а наливши, покрывают чашку крышкою, чтобы немного поустоялся».

В заваривании чая и чаепитии А.Л. Леонтьев давал предпочтение фарфоровой чайной посуде, заявив в главе «Из чего чай пить?»: «Чайник и чашки употреблять фафоровые, самые чистые белыя, на коих цветов нет, а вытирать оныя льняным чистым холстом». Использование при этом медной посуды им не приветствовалось. Понятно, так он оказался в оппозиции к самовару и медному чайнику. И в его брошюре они были проигнорированы.

Именно в это время слово «самовар» всплыло неожиданно в материалах дела Емельяна Ивановича Пугачева, предводителя охватившей всё Заволжье до Сибири Крестьянской войны 1773–1775 гг. и привлёкшего на свою сторону казаков и крестьян, представителей народов Поволжья. В походной канцелярии его сподвижника старшины Бахтияра Канкаева, командовавшего отрядом в три тысячи повстанцев и обеспечивавшим пугачевцев продовольствием и фуражом, среди писем и распоряжений отыскался написанный на старотатарском список конфискованных у богатых людей и содержателей постоялых дворов по Сибирской и Казанской дорогам вещей, включая кухонную и столовую посуду. Составителем значился войсковой писарь Абубакир Тилячев. Перевести бумагу на русский язык в следственном комитете попросили переводчика Казанского адмиралтейства и учителя татарского класса Казанской гимназии при Московском университете Сагита Айтугановича Хальфина. Он и указал, что в ней среди прочего значились «чайник оловянный, чайник медный, медный кипятильник чая, медная сахарница, самовар из зеленой меди, черный чайник». Эта посуда ему была хорошо знакома, ею до Пугачевских событий торговали приезжие сибирские купцы в Гостином дворе нарду с водогрейным большим чайником, чайником-самогреем, кувшином-самогреем, заварочным чайником, медным достаканом для питья, а также шарообразным самоваром и самоваром-сбитенником. Ими промышляли на заказ также местные кузнецы, медники и оловянники на Кузнечном раду. Находились среди них и татары – императрица Екатерина II сняла с них установленные после покорения Казани запреты заниматься связанным с металлом ремеслом.

Уже после Пугачевских событий в Казани в продаже появились и самовары, изготовленные на самоварной фабрике в Туле. Её основал в 1778 г. Назар Федорович Лисицын, бывший слесарь-оружейник, сумев-

ший выбиться в люди и стать владельцем собственного предприятия. Среди первых казанских покупателей тульских самоваров были конечно же сбитенщики, уже знакомые с этим водонагревательным прибором для подогрева воды. За ними последовали владельцы и содержатели постоялых дворов и ям, сообразившие, что с самоваром отпадает необходимость лишний раз топить печку. К ним присоединились станционные смотрители почтовых станций, располагавшихся по почтовым дорогам и трактам. Самовар появился и в казанском почтмейстерском доме, устроенном с учреждением в империи почтового департамента.

Среди содержателей почтовых станций на Урале, в Сибири и Поволжье было немало татар. Они с удовольствием приобщали к самоварному чаепитию несведущих сородичей. Не обходилось и без курьезов. Один из таких случаев запечатлел и татарский народный баит:

Рано утром на рассвете вышел человек.
В окнах дома свет заметил, слабый тусклый свет.
В дом вошел, открывши двери как бы невзначай,
Поздоровался и видит – двое пьют из чашек чай.
Пригласил один учтиво: «Заходи, садись,
К самовару будь поближе, пить не откажись».
Подошел гость, удивился: «Что же там внутри?
Есть открытие отверстье, не видать воды…»
Два глотка успел он сделать – сильно рот обжег,
Закричал: «О, боже! Что же! Что за яд таков?
Мне плевать на чай ваш (плохо сталу мужику –
Черт же дернул заглянуть к вам рано поутру!»

*(Перевод Л. Киваевой)*

И все же, на деле горячий самовар с дороги оказывался незаменимым для останавливавшихся на почтовых станциях на ночлег путников и разнородных проезжающих – извозчиков, обозных мужиков, купеческих приказчиков и торговцев. И они невольно способствовали его популярности в народе. Как уже о хорошо знакомом своим читателям кухонном приборе, о «самовар»е впервые упомянули в своей публикации в июле 1788 г. «Еженедельные известия Вольного экономического общества» – научно-популярный журнал первого в России научного общества. «Когда пожелаешь пить чай, то дай вскипеть той подслащенной воде, в чайном котле или самоваре по обыкновению, и налей ея на чай», – давался совет в разделе полезных наставлений выпуска о заваривании чая в подслащенной мёдом кипятке.

Но вот в изданный через шесть лет первый научный толковый словарь «славенороссийского языка» – «Словарь Академии Российской, по азбуч-

ному порядку расположенный», подговленный учрежденной в 1783 г. Российской академией наук и художеств, слово «самовар» не попало. Хотя в нем отразились слова по чаю и чаепитию. В качестве «сосуда, в котором варят или греют воду для чаю» в словаре приводился чайник. Определение же самовара поместили уже во втором издании словаря, сделанном в 1806–1822 гг. «Самовар-самоварец, – металлический круглой или четырехугольный сосуд на ножках и с рукоятками, у коего в средине труба с решеткою внизу, под которою находится пустота, имеющая по сторонам скважины; в трубу сию кладут горящие угли, раздуваемые проходным снизу воздухом, а в остальное между боками и трубою пространство наливают воду для согрения», – разъяснялось в нём значение этого слова.

Прослышал о самоваре от своего окружения, а затем и заимел его вступивший на престол после Екатерины II в 1796 г. император Павел I. Ему был подарен личный серебряный самовар, изготовленный для него на первой Тульской самоварной фабрике Назара Федоровича Лисицына. Он стремился противостоять «пагубной» политике своей матери императрицы Екатерины II и в противовес ей – поклоннице кофе – сделался большим чаевником. Император приручил к чаю и своих сыновей Александра и Костантина. Самовар вмиг превратился в модный прибор для столичной аристократии, и самоварное чаепитие превратилось в моду. После него в императорском доме Романовых самоварное чаепитие вошло в традицию и поддерживалось вплоть до Николая II.

С походным самоваром в 1798 г. Павел I путешествовал по Волге. В его маршрут вошла Казань, где император устроил проверку Оренбургской военной инспекции, включающей воинские части Казанской, Оренбургской, Уфимской и Пермской губерний. Он пробыл в ней неделю, и остался весьма довольным от ее посещения. Им было сделано распоряжение о восстановлении сгоревшего Гостиного двора и выделении на это беспроцентной ссуды в 200 тыс. рублей из губернских доходов с рассрочкою на десять лет. Во время пребывания в городе Павел I проживал в одноэтажном доме генерала Лецкого. Рядом был сад, где император принимал представителей казанского дворянства, купечества и местного мусульманства. Здесь же вечерами у него собирались сопровождавшие его сыновья Александр и Константин, и они вместе пили чай за походным самоваром.

На посещение родного города Казани императором Павлом I знаменитый поэт Г.Р. Державин откликнулся стихотворением «Арфа»:

Звучи, о арфа! Ты всё о Казани мне!
Звучи, как Павел в ней явился благодатен!
Мила нам добра весть о нашей стороне:
Отечества и дым нам сладок и приятен.

Он адресовал его П.М. Бакуниной – казанской родственнице по второй жене Д.А. Дьяконовой. Строку из него «Отечества и дым нам сладок и приятен» можно было легко воспринять как намёк на чаепития в саду дома генерала Лецкого, где остановился император. А дымовой завесой от костра из «мозглых и курящихся дров» тогда спасались от вечерней мошкары. Не гнушился этим и Павел I. Включал ли сам Г.Р. Державин в рожденный им поэтической образ Дыма Отечества такой конкретный контекст, осталось загадкой. Но державинская строка о нем сделалась эпиграфом стихотворения поэта П.А. Вяземского «Самовар», первого посвящения этому прибору в русской поэзии:

Поэт сказал – и стих его для нас понятен:
«Отечества и дым нам сладок и приятен!»
Не самоваром ли – сомненья в этом нет –
Был вдохновлен тогда великий наш поэт, – обратился он к российскому посланнику во Франкфурте-на-Майне Петру Яковлевичу Убри, посещенному им 29 декабря 1838 г. Вяземский призвал дипломата завести по примеру Державина русский самовар.

В последние годы жизни Г.Р. Державину полюбилось устраивать семейные самоварные чаепития в своем летнем имении Званка. Зачастую они проходили, по его признанию в стихотворении «Евгению. Жизнь Званская», на природе и с разведением «огня дымистого» от мошек. Самовар у него, как и у императора Павла I, был тульский.

В Туле вслед за Н.Ф. Лисицыным обзавелись своими самоварными фабриками и другие купцы. В 1785 г. открылось самоварное заведение А.М. Морозова, в 1787 – Ф.М. Попова, 1796 – М. Медведева. К 1808 г. их в городе имелось уже 8. В них делали весовые самовары простых форм и поштучные, или «ценовые», а также самовары-кофейники и дорожные самовары. Каждая из фабрик старалась придумать свои, не похожие на другие, самовары самых разных форм – конических, граненных, шарообразных. Помимо Тулы самоварные фабрики появились в Москве, Санкт-Петербурге, Архангельске, а также на Урале. Их продукция расходилась по Макарьевской, Ярославской, Тверской, Пермской и Ирбитской ярмаркам. Она переправлялась также на Лаишевскую и Бугульминскую ярмарки, получившие известность торгами железными и медными изделиями.

В Казань тульские самовары попадали в основном через Макарьевскую ярмарку, где имелись специальные самоварные ряды. Большая часть их переправлялась сюда из Тулы в период с 25 мая по 10 июня. Самовары перед этим упаковывались в ящики и коробы с соломой, причем разных размеров, сортности и стоимости. В ящик, который могли поднять два грузчика, входила дюжина обыкновенных самоваров весом

немногим более четырех пудов. Самоварный груз везли на лошадях до Алексина, где его переваливали на баржи, плывущие на ярмарку в Макарьев. Здесь самовары раскупались для всей России.

Без Адисада 18 көн тордык. Кара диңгездә 18 мәртәбә су коендык. Инде Кара дингез парахудына утрыб иртәгә Владивостукка китәргә диб, бар нәрсәне парухудка төйәдек. 18 нче агустда иртә сәгать 6 да пулкга парахудка барырга хәбәр бирелде. Ләкин төнге сәгать 4 дә безгә пархудка бармаска, кире Аршауга кайтырга хәбәр бирелде. Чөнки түркләр урыс парахудларын Дарданил бугазындан чыгармый башладылар. Әйләнеб баргач, озак барасы булганга безне Чинстахуфка кире кайтардылар. Кире кайтканда безне

1 Поляклар һәм еврейлар.
2 Костёл.
3 Крестьянда.
4 Киев.
5 Одесса.
6 Чернигов.

сыйлаучы юк. Бәлки киресенчә астансларда сатыб алырга да икмәк булмады. Аршаугa кадәрле ач кайтдык. Аршауда төн сәгать 2 дә берәр кадак икмәк бирделәр. Шулай итеп без Чинстахуфка кайтыб җитдек.

Без 1900 нчы ел көзен бер Шаукн дигән хахул салдат берлән вольный эшкә Чинстахуфдан 18 чакрым җыракда чуен заудында эшләдек. Көн дә 60 тиен иде. Кичен төн сәгать 2 дә йә 3 дә заудга пуиз берлән таш, ком йәки кухс[1] килә. Без вагундан ком бушата идек, йәки кухс бушата идек. Бер вагун 1 сум 60 тиендән. Тулки бу эш безгә бик сирәк очрый торган иде. Без бу заутдан 18 сум акча эшләб кайтдык. Шул акчага кирәк әйберләр барладык һәм дә киләсе көзгә кайтасы булганга өйгә киеб кайтырга мундир, чалбар һәм күн итек алдык. Чөнки патша хөкүмәте өйгә кайтган салдатга иске шинел генә бирә иде.

1901 нче ел көзендә синтәбрдә мин өйгә кайтдым. Әти мине Тәтешдән ат берлән килеб алды. Ләкин салдат мундирын салыб, өскә авыл киемеп кимичә күрешмәде. Ул өйдән авыл киеме алыб килгән иде. Мин салдатдан кайткач 2 айдан соң хатын алдым. Авылның Мөхәммәдгали кызы Маһикамалны. Бер көн миңа мәсҗеддә Касим салдат очраб күрешде һәм исән-саулык сорашкандан соң, үзенең кече улы Гыйзатулланың салдатка киткәнен сөйләде. Мин анарга «Сәләмәт булса кайтыр, син үзең дә салдат» дидем. Ул бу сүзгә каршы: «Салдат булдың – бук булдың, әгәр дә син укыганда үлсәң, бу Риза шәкерт кабере диб әйтерләр иде. Хәзер инде Риза салдат кабере диб әйтерләр. Менә озакламый сугышка куарлар» диде. «Безне өйгә кайткач Түрк сугышына кудылар. Сезгә дә шул булыр» диде. Һәм Касим салдат сүзе дөрес тә булыб чкды. Мин кайтыб дүрт җыл торгач безне йапун сугышына кудылар.

***5. Урыс-япон сугышы***

**Порт-Артур**[2]

*Татар халык җыры*

*1905 нче ел*

Порт-Артур дигән таш кала
Күп калага баш кала.
Сары диңгез ярларында
Зур калага санала.
Әй, Порт-Артур,
Була идең син матур ла,
Була идең син матур.
Порт-Артур дигән калага
Японлар туп аталар.

[1] Кокс.

[2] Хәзерге Инчхон. Нәрсә кирәк булган анда урыс патшасына?

Аямый дошман, аямый,
Таш каланы ваталар.
Әй, Порт-Артур,
Була идең син матур ла,
Була идең син матур.
Каланы дошманнан яклап
Күп ирләр башын сала.
Ирләр үлә, җанлар оча,
Балалар ятим кала.
Әй, Порт-Артур,
Була идең син матур ла,
Була идең син матур.
Диңгез өсте кып-кызыл кан,
Өркелеп үлек ага.
Ирләр үлә, башын сала,
Данлары илдә кала.
Әй, Порт-Артур,
Була идең син матур ла,
Була идең син матур.
Порт-Артур дигән таш кала
Күп калага баш кала.
Сары диңгез ярларында
Зур калага санала.
Әй, Порт-Артур,
Була идең син матур ла,
Булган идең син матур.

1904 нче ел көз көне ноибр аенда безне уездный гуртка чакырдылар. Салдатлар җыелыб беткәч, әүвәл салдатда икмәк пшереб торучыларны аерыб алдылар да Сенбергә ибәрергә булдылар. Икенче – итек тегүчеләрне аерыб Казан шәһәренә ибәрергә булдылар. Өченче – кием тегүчеләрне аерыб Сенбергә ибәрергә булдылар. Дүртенче – салдатта пулкавый кучер булыб торган салдатларны һәм дә аерыб алдылар. Менә миңа иң авыр вакыт шушы сәгать иде, чөнки мин салдатда вакыт Паулуф дигән хахул пулкавый жуалнига[1] бик күб мәртәбә чакырган иде. Мин бармадым. Йәнә бер итекче итек тегәргә чакырган иде. Мин анда да бармадым. Йәнә Агишин дигән Пинза татар салдат палкавый кучерга чакырган иде. Анда да бармадым. Менә бүген бу һөнәрчеләр бары да сугышка бармый икән. Һәм дә бу һөнәрләр өйгә кайткач да бик кирәк икән. Мин бу һөнәрләргә өйрәнмәгәнгә 60 йәшемә кадәр үкендем. Һәркемгә һөнәр өйрәнергә кирәк.

[1] Нииндидер хәрби вазыйфа(?)

Безне Тәтешдән 800 кешене Разан дигән шәһәргә кудылар. Без Тәтешдән чкканда дикабр башлары иде. Бик салкын һәм җил, буран иде. Без иртә сәгать 10 нарда казна тарафындан хәзерләнгән олавларга утрыб Тәтешдән чгыб китдек. Йулда Тархан дигән татар авылына барыб кундык. Җулда без бик каты туңыб бардык. Тарханда без бер карчык өенә тугры килдек. Монығ өендә йаңа гына чагыб куелган плитә бар иде. Мин күн табан киез итекне шул плитә өстенә куеб, табанын көйдереб, җандырыб алдым. Икенче көн без кич берлән Сенбергә барыб кердек. Сенбердә озак тормадык. Безне шалунга[1] утртыб Разан дигән шәһәргә ибәрделәр. Безнең рута[2] Ризанда Ананин дигән бай йортында торды. Бу Ананин дигән байның бер озын урам ике йаклаб салыб киткән өйләре һәм таш йортлары күб иде. Разанда татар салдатлар җыелыб-җыелыб намаз укый иде. Укымышлы салдатлар аларны мула-мөэмин булыб бер казармага җыеб укыта. Бу укымышлы салдатларга акмаса да тама, көнендә 30–40 тиен булыб тора. Без Разанда татарлар да эзләб табдык. Разанда тау астында Бәдреддин Алтынбаеф дигән картның 3 өе бар икән. Шунда татарлар үзел берлән йөреб сату итеб торалар иде.

Бәдреддин бабай карчыгы берлән икәү генә. Анарда 15 кеше сату итеб тора һәм дә бер йортында Гарифулла исемле кеше тора. Монарда 12 кеше фатирда тора. Бары да сенберләр[3]. Йәнә Гарифулла бабай. Монарда 8 кеше тора сәүдә итеб. Йәнә бу җирдә Ногман дигән эшче бар иде. Йарлы, 8 баласы бар. Менә без бу бабайларга атнасына икешәр барыб, чәй эчеб, сыйланыб кайта идек. Намаз укытыб, Коръән укыгач, берәр сум йәки артык акча да була иде. Шулай итеб без Разанда май башына кадәр тордык. Май башында безне Манжуриага сугышка озатдылар. Без сугышка китәр алдындан Разанда бар татар салдат җыелыб плушатда көндез өйлә намазы укыдык. Безнең намаз укыганны карарга бар афисрлар һәм дә Разан халкындан ике меңгә йакын халык җыелган иде. Без намаз укыб бетереб, дога кылыб утырганда өч дунгыз баласы безнең намаз укыган җиргә чаба башлады. Ул дунгыз балаларын саф арасына кертмәскә дежурный салдатлар куыб тотыб алдылар. Миңа монда 9 сум җыелган иде. Мондан соң без шалунга утрыб Манжуриага таба караб гуртдан чгыб китдек. Без һәр көн төшке аш ашарга җул өстендәге шәһәрләргә туктый идек. Әүвәл көн Рузаиуфка астансына тукдадык. Монда абидга барыб ашадык.

Икенче көн Самарга барыб туктадык. Без монда Тудманың Мәүлүд дигән ибдәш берлән татар арасына китдек. Самарның татар мәктәбенә бардык. Шулай йөреб кайтканда шалунга китәр вакыт җиткән иде. Мон-

---

[1] Эшелон.

[2] Рота.

[3] Сенбер кешеләре.

дан соң Абдулин астансасында абид булды. Без Абдулин авылына барыб бер бик җарлы мәзиндә чәй эчдек. Бу кеше үзе итекләр җамаб тамак туйдыра икән. Үлек булса мәзин булыб күмә. Мулла жук. Бу кешенең бик шад көненә тугры килдек. Чөнки моның улы йапун сугышына алыныб Мугдин сугышында бармагын өздереб, бер ай дигәндә әйләнеб кайткан. Менә без шул көнгә тугры килеб, зур кадерле кунак булдык. Бу кешенең килене кайандыр ике кадак күмәч алыб кайтды да безгә чәй эчерде.

Безгә инде иртәгә Уфа шәһәренә барырга иде. Без төне тиз җөри торган пуизга утрыб шалунны ташлаб Уфага китдек. Без Уфага тиз житдек. Шәһәрне караб җөрдек. Казандан килеб сату итүчеләрнең кибетләрен караб җөрдек һәм бу көн җомга булыб, мөфти мәсҗиденә җомга намазына бардык. Минем өстә мундир, айакда читек, резинка, башта Бохар кәләпүше чолгаб чалма иде. Без җомгада мөфти берлән күрешә алмадык. Мөфти безне борылыб караб чгыб китде. Салтаноф дигән кеше иде. Мондан шалун көтеб алыб ибдәшләр берлән йәнә китдек. Зултауз[1] шәһәренә барыб булмады. Ул астансадан җырак, өч чакрым, тау башында һәм Муиаз[2] дигән заудга кереб булмады. Ул да астансадан җырак икән. Мондан соң без Чиләбегә барыб җөрдек һәм Питропавл шәһәренә бардык. Йәнә Омскига кердек. Бу шәһәрләрдә йакташлар, авылдашлар бар иде. Мондан соң без Уркут[3] шәһәренә креб җөрдек. Бөтен шәһәрне караб, мәдрәсәләренә барыб җөрдек. Һәм дә Шафигуллин Шәйхулла дигән кешедә кунак булдык. Ул безгә өч сум акча һәм бер кадак чәй, 5 кадак шикәр бирде. Бу Шәйхулла дигән кешеләр үзләре мәктәб караб, мөгалим җаллаб ысул җәдид берлән укыталар иде. Боларны ысулы кадимче карт муллалар кәфер диләр иде. Мондан соң без Байкал күле тирәле әйләнеб йөреб, тау башына менеб китдек. Вирхни Удинскига Байкал күле тирәли өч йөз алтмыш чакрым бара чуен йул. Вирхни Удинскины узгач зур шәһәрләр жук иде ул заманда.

Без 1905 нче елның май ахрында Харбинга барыб кердек. Андан 75 нче раиздига[4] барыб шалундан төшдек иртә берлән сәгатъ 8 дә. Шундан без җәйәүләб Гунжилун дигән кытай шәһәренә бардык. Арасы 18 чакрым. Көн бик җилле иде, хәттә зур балчыклар күзгә, биткә бәреләә. Җилгә каршы барыб булмый иде. Җулда кытайлар йөреб тора. Кайсы көйәндә берлән күтәреб, бер башына әйбер таккан, бер башына корҗинкага бер карчык утырткан, кайадыр алыб бара. Һәм дә салдатлар да җөри. Салдатлар айакларына чабата киенгән иде. Инде без барганда арбаларының көпчәкләре

[1] Златоуст.
[2] Миасс.
[3] Иркутск.
[4] Разъездка.

дә бик начар, атлар да, кайсы ишәк, кайсы качыр иде. Без моны күреб, бик гаҗәбләнә идек. Чабата киеб, ишәкләр җигеб сугышу ничек була диб. Бу бер дә сугышка охшамый. Бәлки бер хәерче тормышы иде. Без Гунжилунга көндез сәгатъ 1 дә генә барыб җитдек. Чөнки җил тиз барырга бирмәде. Безгә Гунжилунда абид булды. Монда салдатлар кытай хнҗасы да табтылар. Хнҗа эчеб исерүче дә булгалады. Гунжилун кытай шәһәре тирәли балчыкдан гирпеч[1] әйләнгән, ике йакта гына кабкасы бар. Шул кабкалардан гына йөриләр. Йортлар бар да балчыкдан йасалган. Түбә йук, башы балчык берлән җабкан. Тәрәзәләр күбесе кәгазьдән корган. Пыйала кибет тәрәзәләрендә генә йәисә байлар йортында гына күренә иде.

Гунжилун шәһәре зур түгел, бәлки бер авыл гына. Бездәгечә үзе – җауса баткак, корыда тузан. Үзендә кибетләр бар. Без мондан төшдән соң, сәгать 3дә чгыб китдек дә, озак да бармыйча бер зур су аша чкдык. Тирәннеге тездән йугары, иңе 8 саженлар бар иде. Бу суны чккач, югарыда без барасы 61нче Митаваски пулкның кансларисе урнашкан фанзалар – өйләр бар иде. Без дә шунда туктадык. Без монда торганда бер болыт килеб, иагмур җава башлады да, без фанзага кердек. Анда керсәк, йугарыдан иагмур суы берлән балчык ага башлады, чөнки фанзаның түбәсе йук. Башына камыш тезеб балчык берлән җабкан. Монда безне рутка аердылар. Без 6 нчы рутка тугры килдек дә канселәрдән 3 чакрым җиргә рутка китдек. Инде төн, карангы иде. Безне бер фитфибл алыб барды. Айак асты бик баткак иде. Айак тубыктан бата. Без 3 чакрым җирне 3 сәгать бардык. Безнең барыб кергән җирдә бер кытай фанзасы – ызбасы булды. Без монда чәй кайнатыб эчеб, салам җәйгән җиргә җатыб рәхәтләнеб җокладык, дунгызлар шикелле. Икенче көн без палатка корыб, алты кеше бер палаткада тора башладык. Без монда җәй буе акуп һәм волчий йама казыб йөрдек. Акупның киңнеге ике аршын, тирәнлеге аршын йарым; волчий йама түгәрәк, авызы ике аршын, тирәнлеге ике аршын, төбе бер аршын, уртасында бик очлы казык каккан була. Волчий йамага төшеп шул казыкга кадала.

1905 нче елның агустның 15 ләрендә безне печән чабарга диб пулкдан икенче баталиун аердылар. Безгә дүрт көн җәйәү барырга кирәк иде. Безгә 4 көнгә чәй, шикәр, бер көнгә ике кадак сохари, өч көнгә 9 кадак икмәк бирделәр. Китәсе көн безнең баталиун берлән камандир пулка исәнләшкәндә афисерларга «Дай буг крис пулучит» диб үбештеләр. Мин моны ишеткәч ибдәшләргә әйтдем: «Бу безне печән чабарга диб алдыйлар, монда бер хәйлә бар булырга кирәк». «Без сугышка барабыз булыр» диб уйладым.

Без агустның 14 ндә пулкдан чгыб китдек. Күб салдат икмәкләрен алмадылар. Мин өч икмәк алдым, һәр икмәк тугыз кадак. Бу икмәкләрне

[1] Кирпеч.

җулда мин арбага куйдым. Чөнки арбада ат башында Сәүтекнең Мөхәммәдша дигән таныш кеше бара иде. Менә мин аның арбасына башга әйберләрне дә салдым. Хәттә млтыкны да куйдым. Ике көн баргач минем әйберләрсез барганымны фитфибилгә әйтделәр. Ул мине төшке ашка туктагач каравылга куйды. Мин бер ун минут торгач дневалнига әйтеб алышындым. Ул вакыт инде салдатлар аш алыб киләләр иде.

Икенче көн барганда төш вактында минем җанга Самар губернасының Габдрахман ибдәш килеб: «Ибдәш, тиз мир булыр, мин гзиттә бүген укыдым, тиз кайтырбыз» диб куаныб сөйләб китде. Бу кеше йахшы гына грамутни иде. Үзенең дүрт баласы, хатыны бар. Ул мир булыб кайтырга ашыга иде. Менә без кичен бер кытай авылына кунарга туктадык. Без туктагач бик каты йагмур җавыб узды. Без тыныч урын итеб бер бүлмәгә кердек. Ике бүлмәле фанза булыб, бер җагына афсрлар кергән, бер җагына без урнашдык. Ибдәшләр Мөхәммәтша Камали углы, Сәгыйтулла Гайнулла углы – барыбыз өчәү идек. Төн сәгать 11 дә афисрлар җанына 6нчы рутаның фитфибиле килеб Габдрахманны фанза ачтинасы ишелеб зур таш күкрәген басты, диде. Афиср бик абтраб китте дә: «Нишләргә инде, монда мулла бар иде түгелме?» диде. Фитфибл: «Мулла бар, ләкин кайда урнашканан белеб булмый, үзе бик карангы, җава, җөреб булмый» диде. Афиср анарга: «Табарга кирәк, мөселманлар үзләренчә укыйлар, булыр» диде.

Мулла дигән мин идем. Мин бу сүзләрне ишеткәч фитфибл җанына чыгыб: «6нчы рутада йәсин укый белә торган Салаватулла Бикмуллин» әйтеб җибәрдем. «Әгәр дә үлсә, үземез күмәрбез» дидем. Фитфибл рутага кайтыб Салаватулланы йәсин укырга кушкан икән, ләкин Габдрахман озакламый үлгән. Өченче (икенче) көн иртә белән фитфибл рутнига килеб Габдрахман үлде диде. Афисрның тавышы җылау тавыш иде. Ул аптраб: «Инде нишлибез, мулла кайда икән, чакрырга кирәк» диде. Мин шул минут анын җанына кердем. Мин кергәндә афисрның күзендә йәш иде. Инде рутный минем берлән исәнләшеб: «Инде нишлибез, пулкга ибәрәмезме, монда күмәбезме?» диб киңәште. Мин: «Шушы җирдә күмәбез, өч сәгатьтә эш бетәр» дидем. «Тулке кәфен кирәк булыр» дидем. Афср акча бирде, «Менә кәфеннек табыгыз» диб. Мин Мөхәммәдшәне кушдым салдатлардан киндер җыеб кәфеннек хәзерләргә. Үзем ибдәшләрне чакрыб кабер казый башладык. Кытай зур тирәк агачы төбе кабер урны күргәзде һәм ләхед авызына куерга зур такта бирде. Без шул көн иртә сәгать 9 да күмеб бтердек дә җулга китдек.

Без бу көн җулда барганда зур шәһәр күрдек. Барыб җидешкә шәһәр булмады. Салдатлар өчен икмәк хәзерли торган җир. Антидатскуа[1] дигән склад булыб чкды. Мин монда бер ибдәш берлән өч икмәк сораб алдым.

---

[1] Интендантский.

Без 18 нче агустда җулда барганда безне гинрал Мишачнк[1] куыб җитеб исәннәшеб узыб китдe. Без гинрал узгач бераз баргач бер су буена барыб туктадык. Чөнки су аркылы чыгарга күпер өлгермәгән иде. Без монда төшке ашны пшереб ашадык. Шул вакытда өч атлы казаклар килеб: «Ура, мир, ибдәшләр, сугыш бетә, мир, ура» диб кчкырыб җөрделәр. Бу бик җаңа җыр булганга афсрлар мунар абдрадылар. Казакларга «Ни кчкырасыз булмаган эшне» диб сүгенә башлаганлар иде. Казаклар камчы күргәзеб: «Дөрес, мир, гинрал Мишчнкга тилфун булды, ул хазер генә Линиуч[2] йанындан кайткан иде, сугышырга рөхсәт сураб. Сез анарга пумчка 75 баталиун чакырылган идегез. Хәзер бәхет, мир булды» диделәр. Без аларга «Безне печән чабарга җибәрделәр» дидек. Алар бу сүзгә каршы: «Ничек чабылган булыр идегез, мир булмаса» диделәр. «Мондан 30 чакрым җирдә йапунларның 30 мең гаскәрләре бар. Моны каршыларга барган иде. Безгә инде бүген мир, ура» диб кчкырдылар да, чабыб кайтыб киткеләр. Безгә шадлык, Габдрахман ибдәш генә үлде.

Без шул көн сәгать 5 ләр җылга аша чгыб бер зур йорт каршына барыб торыр өчен палаткалар кордык да шунда урнашдык. Ул көн кич бу лагирдан без бер нәрсә дә карый алмадык. Икенче көн иртә берлән койаш чыкканчыга кадәре мин торыб палаткадан чыккан идем, менә бер салдат бер зур икмәк күтәреб килә. «Икмәк кайдан алдың» диб сораугa: «Менә бу зур җортта пикарнә бар, шундагы салдатлар сата» диде. «Хакы 30 тиен» диб палаткасына креб китдe. Мин дә пикарнәгә таба китдем. Кабка төбендә бер салдат тора иде. Мин анардан: «Икмәк сатасыңмы?» диб сорадым. Ул салдат: «Сатам, шушында торыб тор, хәзер алыб чыгармын» диб креб китдe. Байтак торгач бер салдат икмәк күтәреб ишек алдында йөргән күреб: «Зимләк, бер икмәк кенә, менә акча» дигән идем, ул миңа каты сүгеб куыб җибәрде. Ул миңа икмәк сатырга алыб килә торган салдатны тоткан дижурна булыб чыкды. Мин бераздан йәнә пикарнә җанына барыб бер салдатдан икмәк сатарга сорадым. Ул миңа: «Койаш чыккач кил, мин капчыклар кибдерергә чыгам, шунда сатрмын» диде. Мин койаш чыккач кычытканлар арасыннан койма буена бардым. Әүвәлге салдат капчыклар күтәреб чгыб кибергә әвәли башлады. Мин аның җанына бардым. Ул «Бир акчаңны» диб ул акчаны алды да капчыкдан кчкенә генә бер икмәк ташлады. Ике кадак кадәр булыр иде, 32 тиен. Мин бу икмәк булгач да куаныб палаткага кайтыб ибдәшем Бәшир берлән бик тәмнеләб чәй эчдек. Бу көн безгә бер аш да җук иде. Төшдән соң безгә баталиундан да икмәк бешерергә салдатлар сорадылар. Бездән ике башкырт салдат икмәк бешерергә пикарнага керделәр. Боларның пикарнага керүе минем

[1] Мищенко (?).

[2] Линевич – Ерак Көнчыгыштагы Рәсәй гаскәрләренең башчысы (командующий).

өчен зур шатлык иде. Чөнки болар минем дуслар. Болар аша икмәк алыб булачак иде. Төшдән соң мин йәнә пикарнига таба китдем. Менә җулда өстенә күн тужрка кигән бер салдат безнең баталиун салдатлары берлән сүзләшеб тора. Мин крыйдан гына караб тордым. Күн кием кигән салдат урысча сүзләшде. Үзенең башкырт-татар икәнен белдереб тора иде.

Мин бу ибдәш берлән танышырга теләб җанындагы салдатлар киткәнен көтеб тордым һәм үзе генә калгач татарча: «Исәнме, туган» диб моның берлән күрешдем. Бу кеше үзенең сорашмыйча татар икәнен белүгә гаҗәбләнде, чөнки ул үзен урысчага бик оста диб уйлый икән. Ләкин эш киресенчә иде. Бу салдатдан сораша торгач шушы пикарнаның башлыгы булган афисрның диншге булыб чыкды. Бу да минем өчен шадлык иде. Чөнки бу салдат шул сәгатьдә мине үзенең фатирына алыб керде. Ак күмәч берлән чәй эчерде. Боларның тора торган бүлмәләрендә чәй, шикәр күб иде. Чөнки пикарнада йөзгә йакын кеше ашы, шуларга бирелә торган чәй, шикәр болар кулында икән. Мин чәй эчкәч әлеге ибдәш миңа чирек такта чәй, бер кесәгә шикәр тутырды. Һәм дә ике кадак кадерле күмәч дә бирде. Мин шул нәрсәләрне алыб чгыб ибдәшем Бәшир берлән кич тагы чәй эчеб җибәрдем. Бу салдат Самар губернасы Бузаулык өйәзенең дисвитлни службада иде. Манжуриада безгә кадәре ике ел йөргән, Мукдин сугышларында булган иде. Ул миңа пикарнидан икмәк сатыб алмаска кушды. Чөнки тотсалар эш начар. Ваини[1] сут булачак диде. Әгәр дә икмәк кирәк булса, йарты йәки андан кимрәк кенә алыб чгарга кушды. Шундан соң мин вакыт барда тугыз көн бу ибдәш җанына керә идем. Күб вакытны итле аш булгалый иде. Пикарнага кергән үзебезнең икмәк пешерүчеләрдән икмәк ала идем.

Бу җирдә без бер атна торгач печән дә чабдык. Мир булгач, сугыш булмагач безне пулкга барырга кушдылар. Без мондан синтабрның ахрында күчеб китдек.

Без пулкка кайткач озакламыйча кыш чыгар өчен Павда Панфан исемле кытай авыл җанына барыб зимланклар йасадык һәм шунда кышладык. Мамакай дигән гуртдан 18 чакрым җирдә Павда Панфан авылы шактый зур авыл. Һәр җортның тирәсен балчыкдан крипеч йасаб әйләнгән. Балчык ишелмәсен өчен башына камыш тезеб әйбәтләб йасаганлар кытайлар. Менә монда инде кыш чәй кайнатырга кирәкле утын жук. Утын җага җуклык сәбәбле салдатлар күргән җирдән камыш җолка йәисә кытайларның җагарга дигән утынга хәзерләб куйган камышларын һәм саламларын урлаб җага иде.

1905 нче йылның дикабр аинда Линиучның приказында әгәр дә салдатлар сугышка кадәрле Сибридә хезмәт иткән булса һәм дә шул хужа-

[1] Военный.

сы ул салдатны әүвәлге урнына эшкә чакырса, Расигә кайтмау шарт берлән әүвәл баена кайтарыб җибәрелә. Ләкин Чиләбедән узмаска тиеш дигән хәбәр чыкды. Шул хәбәрне укыгач без дә Питрпавлда байда тордык диб зивлин[1] бирдек. Һәм дә байдан килгән итеб хат да йазыб бирдек. Безнең бу зивлин дикабрнең 29 нда хәл кылыныб безгә Питрпавлга кайтырга рөхсәт ителде. Без шул хәбәрне белгәч бар кажуни[2] әйберләрне: млтык, балта, көрәк, патрунларны һәрберсен каптинармуска илтеб бирдек. 1906 нчы елның 1 нче кичәсендә без көнге сәгать 12 дә пулкдан чгыб астансага китдек. Барыбыз 8 кеше идек. Без 75 нче нумер райзизда вагунга утрыб Харбинга бардык. Харбинда 11 нче нумер пуизга утрыб Манжуриа каласына таба Раси йагына кайтыб китдек. Ләкин Харбиндан бераз киткәч дә безнең пуиздан параузны алыб безне бик кчкенә бер астансада калдырдылар. Бу хикмәт Манжуриа җулында чуен йул эшчеләрнең забазтуфка башлавындан килеб чыкган икән.

Без ике көн паравуз көтеб торсак да, безгә паравуз килмәде. Ике көндән соң безнең артда калган Харбиндагы синатарни пуиз аурулар һәм рани[3] салдатлар төйәб куыб җитде. Менә бу синатарни пуизның машинасын безнең пуизга алыб без бу астансадан кузгалыб китдек. Безнең урынга синатарни пуиз машинасыз калды. Инде артда пуизда машина да җук. Расиадан да пуиз килмәй иде. Менә без әкренләб 3 нче гинуарда кичке сәгать 4 дә Манжуриа астансасына килеб туктадык. Бу астансада эш бөтенләйгә башка. Менә 19 шалун салдат машинасыз калганлар. Кайсы ун көн, кайсы 5–8 көн торган салдатлар ачыкканлар. Әммә машина кайчан буласы билгеге түгел. Без пуиздан төшкәч вакзалга барыб кердек. Анда бер меңдән артык кеше пуиз көтә икән. Басыб торырга да урын җук. 5 йөзләб афисрлар абдыраб пуиз көтәләр. Ләкин пуиз җук, машиналарының күбесен эшчеләр катрыб куйганлар. Без туктагач бер сагәтьдән соң Манжуриа астансасында булган тимер җул эшчеләре кзыл флаг күтәреб Интернитинал җырлаб тимер күпер аша чгыб китделәр. Салдатлар эшчеләрнең 4 сен тотыб кыйнаб үтерделәләр. Бер эшче җаны чыкканчы: «Алла җук, Никалай патша түгел» диб кчкырыб үлде. Эшчеләр салдатларга «Бергә булыгыз, безнең берлән берләшегез, без сезне хәзер Расига озатабыз» диб йазу таратсалар да, салдатлар катышмадылар.

Манжуриа астансасндa безне алыб килгән парауз машина бар, ләкин ул бер машинага 20 дән артык кешенең күзәтендә иде. Бу машина 19 шалунның берсен алыб китә, йәисә бу бер йаңа састаф алыб китәме, моны менә белеб булмый иде. Инде кич булды. Көндез ликтрик астансасы

[1] Заявление.
[2] Казённый.
[3] Яраланган (раненный).

эшләми, дипа[1] җабык, кич караңгы, сирәк-сирәк млтык атылган тавыш да булыб куйа иде. Эшчеләрдә 70 кә җакын вайни млтык да бар имеш.

Мин кичке сәгать 10 ларда вгзалдан тышка чкдым. Платфурмада ике кандухтр сүләшеб баралар иде. Старши кандухтр хәзер китәбез ди. «Менә машина хәзер вагунлар тага, ләкин бер кеше дә мондан утртмыйбыз. Башка астансада булсалар утрырлар» диде. Мин шуны ишеткәч әкрен генә вакзалга креб ибдәшләремә әйтдем дә без берәм-берәм әйберләрне алыб вакзалдан тышка чкдык. Без чыккач озак да тормады, машина вагунлар тагыб вакзал җанына килә башлады. Шул арада салдатлар афисрлар берлән вгунлар тулыб да өлгерде. Ләкин эш барыб чыкмады. Машина күте берлән чигеб пуизны запаснуй путка бик каты этеб җибәрде дә үзен ычкындырыб ибәрделәр. Вагунлар бер җакга, машина икенче җулга кереб китде. Халык тагын вагзулга җөгерде. Чөнки бик салкын иде. Без вакзалга кермәдек. Бер ватылган вгунга креб утырдык. Ләкин монда да куркыныч иде. Млтык тавыш һаман сирәк-сирәк иштелеб тора иде. Бераздан соң байагы кандухтурлар йәнә узыб китделәр. «Хәзер китәбез, вагунларны бара-бара гына тагабыз, 8–9 вагун булса йарый» диб сүзләшкән тавышны иштеб без ничек дә утрырга трышырга кирәк диб җул буенда саклаб тордык. Менә машина әкрен генә җулга чыга. Бер кандухтр вагунлар тага. Шулай итеб машина килгәндә без 8 кеше бер вагунга креб вагун ишекләрен бикләб дә куйдык. Машина әкрен генә килә торгач кинәтдән пулный хут кузгалыб китде дә, Манжур вкзал артда калды. Без бераз баргач ишек ачыб карасак, барсы 8 вгун таккан иде. Без хәзер җулда. 19 шалун һәм меңдән артык вкзалда кала бирделәр. Без әкренләб барылса да, Расигә таба барабыз. Менә бер көн төнге сәгать 2 ләрдә крык градус салкында бер салдат вагун саен кчкырыб җөри: «Ибдәшләр, машина туктый, машинис җук, төшеб качкан. Качагар булыб эшләгән кеше җукмы?» диб. Озакламады, качагар да машинис да салдатдан табылды. Шулай итеб без Чита дигән астансага килеб җитдек. Монда 4 йөз эшчене дипага җабып бикләб өч көн-төнләр дипага кражин[2] сибеб эшчеләрне җандырырга хәзерләнгән булганлар. Ләкин без барыб туктаганда эшчеләр патшага итагать кылырга, йахшы эшләргә разый булыб кул куиб дипадан чыкдылар. Бу булды һәрбер астансада: кеше җук, началник астансада җук. Безнең пуизны да каршы алучы җук иде. Без шулай итеб Байкал күл тирәли үтеб Уркут шәһәренә килеб җитдек. Монда бераз җулда тәртиб бар иде инде. Шундан соң без бер көн Чиләбе вакзалына килеб җитдек. Монда инде эш тагы начар. Пуиз килеб җитүгә каминдант астанса ганирал уза. Каршы алыб һәркемне йаздырыб тора. Бу көн пуиздан төшкән кешене бәлки

[1] Депо.

[2] Керосин.

15 көндән соң китәргә туры килер диләр. Без йазылмича качыб вкзалга кердек.

Ләкин вакзалда басыб торырга да урын жук иде. Кеше белән тулган, җылашу, кчкырышулар гына иштелә, чөнки җөрүче кешегә басыб уза, балаларны табтый иде. Бу вакзалда 22 салдат шалуны машина көтеб торалар. Менә мин вакзалдан чгыб бераз тикшеренеб йөргәч безне алыб килгән машина бер шалун алыб китәсе беленде. Мин тиз генә ибдәшләркә әйтдем дә без бер вагунның башына менеб утырдык. Ләкин түзеб булмый, бик салкын. Икенчедән, каминдант күрсә төшереб калдыра. Менә мин бер вгндагы салдатдан сорадым: «Сезнең вгунга утруб бер астанса барырга мөмкин булмасмы?» диб. Ул миңа: «Старши вагун хәзер килер, анардан сорарсыз» диде. Менә старши ундрафиср[1] күмәч алыб килеб вакунга керде. Мин анардан рөхсәт сорадым. Ул безгә: «4 кеше, сезнең берлән 40, кереңез» диде.

Без өч салдат кердек: Мөхәммәдша Камали углы, Сөнгатулла Минали углы һәм мин үзем. Без бу шалун берлән Чиләбедән 18 чакрым бер кчкенә астансага төшеб калдык. Бу вагзал буш, беркем дә жук иде. Без монда төн марҗаларны уйатыб сөт, күмәч сатыб алдык һәм чәй эчдек бик иркенләб. Иртәгесен сәгать 4 дә тиз йөри торган пуиз килде. Без дә шунар утрыб китдек. Ләкин безнең Расига кайтырга бер дукумент да һәм билет да жук иде.

Безгә бик кыен кайту Чиләбене узгач булды. Бездә хәзер инде салдат билитндан башка һич бер йазу жук. Чөнки без докуминтларны Питрпаулда здавайт итдек. Андан йазу алмадык. Үзебез 3 нче нумер пуиз берлән кайтабыз. Бу пуизга салдатлар билит берлән дә утрырга йарамый иде. Без Чиләбедән киткәч алдагы астансиаларда безнең пуизны афисрлар салдатлар берлән каршылый. Салдат жукмы диб вгун саен креб җөриләр. Без качыб кына калабыз. Вакзалга җитүгә без вагундан төшеб китәбез дә пуиз кузгалгач кына барганда утрабыз.

Менә шулай азабланыб Уфа вакзалына җитдек. Төн берлән без җоклаган булганбыз. Безнең пуизны салдатлар тикшереб йөргән күреб мине бер марҗа уйата. Мин чалбар да кимичә ак штан берлән өскә ак тун киеб вгундан чгыб китдем. Төн бик салкын иде. Вакзалга да креб булмый. Чалбар жук. Вгунга да крергә куркыныч. Шулай итеб 2 сәгать вкунлар арасында җөреб уздырдым. Мөхәммәдша Камали углы вагун сартирына креб җоклаган. Мондан соң астанса саен качыб йөреб Самарга килеб җитдек. Көндез сәгать 12 дә монда инде вагун саен 4 тәр салдат куйдылар. Һич бер салдат булмасын диб тикшереб караб җөрде афисрлар. Без вакзал эченә кереб качыб йөри идек.

Менә өченче званук булды да вакзал ишеген бикләб дә куйдылар. Без эчдә калдык. Арт җак ишеккә җөгереб барсак, анда салдат караулаб чы-

[1] Унтер-офицер.

гармаска саклаб тора икән. Сөнгатулла Гайнулла углы салдатны сугыб җыкды да без бик тиз җөгреб чгыб пуиз алдында җөгердек. Машина бик әкрен бара иде. Безне машинис күреб, безгә «утрасызмы?» диб кчкырды да машинаны тагы да әкренәтде һәм вагунлар буйлаб пар җибәрде. Без дә утрдык һәм әйберләрне исән табдык.

Мондан соң Сизран астансага килеб җитдек. Монда пуиз алышынды. Монда салдатлар күб жук, ләкин креб утыруга кандухтр бездән билет сораб куыб чыгарды. Без икенче вгунга китдек. Андан да куыб чыгардылар. Без әйберләрне күтәреб жул буйлаб алга китдек. Ике чакрым баргач бер кчкенә генә буткга креб утырдык. Анда тимер мичкә ут да җаккан иде. Бераздан пуиз килә башлады Без әйберләрне күтәреб чкдык. Машинист безне күргәч пуизны әкренләтеб пар җибәрде ашкыма[1] таба. Бөтен буиз парга күмелде. Без дә менеб утрдык. Бер 6 чакрым киткәч йәнә блит тикшерә башладылар. Без инде кантрулне[2] сугыб җибәрдек. Байа безне куыб чыгарган кандухтр кантрул җанында иде. Кантрул анарга: «Буларны ник утыртдык?» дигәч «Райззда[3] ултырдык, ул безне сездән дә куыб чыгарды» дидек. Соңра әлеге кандухтр безнең җанга килеб: «Ибдәшләр, сезнең өчен менә эт итеб сугалар. Бераз чәплек[4] бирегез» диде. Без анарга 50 тиен бирдек дә тыныч кына Инзага[5] килеб җитдек. Монда безгә присадка иде. Без мондан Сенбергә (хәзерге Улиануск) шәһәренә китәбез. Без килгән пуиз Мәскәүгә китде. Без монда рәхәтләнеб бер вагунда алты гына кеше Сенбергә китдек. Менә шулай итеб Сенбергә дә җитдек. Сенбердән ат җаллаб Тәтешкә кайтдык. Тәтешдән Борханеддин Гайнеддин белән утрыб өйгә кайтдым. Без авылга кайтыб кергәндә февралнең 5 се иде. Димәк Харбин берлән Сенбер арасын 33 көн кайтдык.

*(Дәвамы бар)*

---

[1] Тубыгыма (диалект.).

[2] Контролёрны.

[3] Разъездда.

[4] Сугылган кешегә компенсация(?).

[5] Хәзерге Ульян өлкәсендә.

# ИРЕК МӘЙДАНЫ: БӘХӘС КЛУБЫ

# ПЛОЩАДЬ СВОБОДЫ: ДИСКУССИОННЫЙ КЛУБ

## ПРОФЕССОР ДАМИР МУХЕТДИНОВ: О КАЖДОМ НАРОДЕ НУЖНО ГОВОРИТЬ С УВАЖЕНИЕМ, ЭТО ЧАСТЬ НАШЕЙ ИСТОРИИ

Как и почему нужно переписать школьные учебники по истории, для чего в книги нужно вернуть Киевскую Русь, а также Хазарский каганат и Золотую Орду, о чем говорят ДНК-анализы современных татар – на вопросы пресс-службы ДУМ РФ ответил первый заместитель председателя, доктор Дамир Мухетдинов.

***– Дамир хазрат, Ваше выступление на конференции «Пути и страны: цивилизации Востока в исторической динамике» во многом опирается на современную российскую историческую науку. Чтобы убедиться в том, достаточно обратиться к работам ведущего научного сотрудника Отдела Востока Государственного Эрмитажа, начальника Старокрымской (Золотоордынской) археологической экспедиции М.Г. Крамаровского (см., например, «Золотая Орда. История и культура», 2005). Или выступлениям главного научного сотрудника Института российской истории РАН В.В. Трепавлова (см. Материалы Международной научно-практической конференции XIII Фаизхановские чтения, 2016). Вы считаете себя продолжателем их традиций?***

– Спасибо за вопрос. Действительно, я не открыл Америку и даже не планировал ее открывать. Ученых, имена которых Вы назвали, я считаю своими учителями, работы которых изучаю на протяжении 20 лет, в том числе имел практический опыт общения с ними, публиковал их научные работы и выступления. В той или иной степени я нахожусь в рамках их школы, которая сформировалась в позднесоветский и постсоветский период в российском востоковедении. К этой плеяде можно отнести и доктора исторических наук Р.Г. Ланду, автора книги «Ислам в истории России», и доктора философских наук Э.С. Кульпина с его исследованиями российской ментальности, российской цивилизации. Они переосмысляли традиции Л. Гумилева, Г. Вернадского и других евразийцев и развили свои теории, обозначив некие тренды. Конечно, нужно назвать и директора Государственного Эрмитажа М.Б. Пиотровского, который, организуя выставки, посвященные исламскому искусству, в России и за рубежом, всегда подчеркивал многорелигиозный характер нашего государства на всем протяжении его существования.

Опираясь на академический подход, я обобщил в докладе взгляды этих ученых. Их идеи сегодня подтверждаются и современным научным инструментарием. Палеогенетики, например, убедительно доказывают, что российское Поволжье, Южный Урал, Причерноморские степи, то есть территории современной России вне исторической Руси, являлись в древности очагами цивилизации, то есть их вклад в развитие человечества имеет мировое значение.

Совсем недавно сотрудники Института археологии РАН нашли в Великом Новгороде крупнейший в истории города клад последней четверти X в. В нем около 1,9 тыс. предметов, большая часть которых – целые и фрагментированные серебряные дирхамы Арабского халифата, отчеканенные на Ближнем Востоке и в Центральной Азии. Наиболее поздняя из монет датируется 974–975 гг. К этому времени волжские булгары уже приняли ислам на государственном уровне. Это произошло на 66 лет раньше, чем великий князь Владимир крестил Киевскую Русь, что признает сегодня и Русская Православная церковь, и патриарх Кирилл. Через Волжскую Булгарию, через Итиль арабы, персы, тюрки шли с юга на север. Это был огромной протяженности торговый путь, который доходил до Хорезма (средневекового государства на территории современного Туркменистана, Узбекистана и Казахстана – прим. ред). Найденный клад проливает свет на многие аспекты внутренней миграции, торговли, межгосударственных отношений на огромном евразийском пространстве.

***– Кстати, в Новгороде, в замечательном музее-заповеднике можно увидеть многие материальные свидетельства тех контактов, которые этот древний русский город имел с Востоком. А арабские дирхамы там находили и в предыдущие годы!***

– Я недавно был в Новгороде, посетил основные православные соборы и, конечно, Софийский собор. Поинтересовался, к какому веку относится иконостас. Мне сказали, что основной массив всего иконостаса, который украшает главный храм Новгорода, относится к XIII–XIV вв. Это расцвет взаимоотношений Орды и русских княжеств. На это тоже надо обратить внимание. Многие ученые писали, что с усилением ислама в Орде при хане Узбеке (в годы его правления ислам стал государственной религией Золотой Орды – прим. ред.) языческие элементы, которые если еще и сохранялись в тех или иных русских княжествах, начали исчезать. То есть православие окончательно побеждало с укреплением ислама в Орде.

***– Именно золотоордынская тематика стала триггером, спровоцировавшим множество комментариев и отзывов к вашему выступлению. Политолог Марков пишет, что «часть общества и историков просто встали на дыбы», а автор издания «Регнум» Тараторин***

***приравнивает пересмотр подходов к историческому нарративу к подрыву русской идентичности.***

– Я знаком с этими отзывами, о которых вы говорите и благодарен авторам за желание разъяснить, а не присоединиться к потоку злобного троллинга, который льется неделями. Соглашусь, что нерв дискуссии лежит не только в научной, но и в эмоционально-нравственной плоскости, поскольку затрагивает национальные чувства и даже культурный код. Прекрасно могу понять тезис о том, что монгольское завоевание оставило в коллективной душе и исторической памяти русского народа глубокий след. Но нельзя забывать, что столь же неизгладимый след в коллективной душе других народов России оставило и покорение Иваном Грозным постордынских татарских ханств, завоевание российским государством Сибири, Кавказа и Средней Азии.

Разговор о культурном коде страны – вещь еще более серьезная, чем даже общепринятый исторический нарратив, поскольку имеет дело с бессознательным и государствообразующего русского народа, и всех других народов, веками и ценой жизней своих сыновей и дочерей, участвовавших в строительстве российского государства.

Ресентимент, а в данном случае мы имеем дело именно с ним, – вещь очень тонкая и может стать катализатором как созидательной, так и разрушительной активности. Нынешний кризис российско-украинских отношений начинался с возведения в культ трагедии голода на Украине, Первая Чеченская война подпитывалась этим же чувством ресентимента, реванша. Но может быть и наоборот. Посмотрите на Казань, где восстановили разрушенную при завоевании Казани мечеть и назвали ее именем настоятеля того храма – Кул Шариф. Сегодня это символ города, как и восстановленный Болгар стал символом Татарстана.

Мне довелось стать непосредственным участником одного из таких исторических моментов в день открытия памятника царице Сююмбике в городе Касимове. Известно, что выдача регентши Сююмбике и малолетнего наследника Утямыш-Гирея Москве стала незаживающей раной в душе татарского народа. Это травма год за годом, эпоха за эпохой заставляла татар оглядываться в XVI в. и горевать о предательстве, допущенном по отношению к правительнице. Муфтий Гайнутдин, обращаясь к собравшимся на татарском языке, апеллируя даже не к разуму, а к нашей коллективной душе, дал понять, что открытием памятника восстановлена поруганная честь царицы и мы вернули прекрасную Сююмбике на то высокое место, которого она заслуживает. И недостойное поведение последнего мужа Сююмбике – Шах Али, который был соратником и сторонником Грозного, и все противоречия XVI в. должны остаться в XVI в.,

а мы должны пережить, преодолеть свою травму и идти вперед, смотреть в будущее.

Но преодолеть не означает забыть все трагедии прошлого, снивелировать их за политкорректными формулировками, проигнорировать противоборства прошедших эпох. Нужно знать и понимать нерв конфликтов прошлого, но относиться к ним с высоты зрелой позиции, без триумфаторства или психологии жертвы.

Не секрет, когда сегодня татарские, башкирские, дагестанские мужчины видят, как с наших мусульманок пытаются сорвать платки, как топчут уличной обувью чистое молитвенное пространство наших мечетей и общинных домов, они невольно ассоциируют эти действия с теми историческими эпохами, когда велись войны, когда наши мечети разрушали, когда статус ислама в России оставался не определенным, пока не был защищен на государственном уровне, то есть в эпоху до правления Екатерины II. Разумеется, тут же появляются провокаторы, которые подведут их к мыслям о реванше, о «восстановлении справедливости», о «создании халифата». Социальные и политические технологи прекрасно знают, что нельзя рассчитывать на полноценное гражданское самосознание людей, которым отказано в своем месте и вкладе в отечественную историю и государственное строительство, тем более если их историческая память входит в конфронтацию с официальным историческим нарративом.

В царское время противоречие дискурса большинства и дискурсов меньшинств разрешалось за счет компактного, слободского проживания и, таким образом, культурной сегрегации последних. В советское время основой гражданского единства выступал марксистский классовый подход.

Прежние алгоритмы дружбы народов больше не работают, про новые основы многосоставной российской гражданской нации предстоит договориться. И лучше, если мы сами будем направлять этот процесс в конструктивное, позитивное русло, а не работать с последствиями зарубежной пропаганды.

***– Что Вы предлагаете вместо этноцентричного подхода к истории, который Вы назвали «примитивным и давно устаревшим»? В какой степени нужно пересмотреть те учебники истории, по которым сейчас учатся дети в российских школах?***

Я регулярно читаю учебники моих детей, по которым они учатся в школе. Особое внимание уделяю преподаванию отечественной истории. Я вижу, насколько однобоко и тенденциозно в них написано о других империях и народах, существовавших в разные века на российском пространстве. Например, Золотая Орда появляется в учебнике исключительно в контексте монгольского завоевания, а затем освобождения Москов-

ского великого княжества от ордынской зависимости. При этом и одного параграфа не посвящено колоссальному влиянию Золотой Орды на всю русскую административную систему и военное дело, традицию и культуру, торговлю и экономику, государствостроительство! А ведь почти половина российской элиты – это татары-полукровки: писатели, музыканты, военачальники, государственные деятели… А в учебнике сказано только о монголо-татарском иге, о том, что Орда обложила данью Русь, в полон уводила русских девушек, разрушила все города. Про Волжскую Булгарию, про Хазарию, про тюркский каганат в учебнике хорошо, если будет один абзац. Но ведь Хазарский каганат не сравнить ни с Киевской Русью, ни с Волжской Булгарией. Киев был частью каганата также, как и Волжская Булгария. Хазарский каганат – это территория современной Астрахани и Волгограда, т.е. это часть нашей российской истории и культуры. Это огромное государство, в котором и славяне играли огромную роль. На примере Хазарского каганата, некоторые каганы которого исповедовали иудаизм, мы можем показать, насколько толерантным было еще с VIII в. это государственное объединение: там были синагоги, и церкви, и мечети, свобода религии, свобода торговли.

Я считаю, что нужно быть очень корректным в вопросе учебников – все-таки не переписать, а скорректировать.

Скажем честно, национальные меньшинства не претендуют на первенство. Речь идет о нормальном человеческом достоинстве. Я не хочу, чтобы мой ребенок, читая книгу по истории отечества, подходил ко мне и спрашивал: а что наши предки – татары – были такими разбойниками? Только грабили и убивали?

Другой пример – Республики Бурятия, Калмыкия и Тыва. Там Чингисхан – не просто покоритель Вселенной, это культовая фигура, ему ставят памятники, его именем называются культурные мероприятия и заведения, его имя дают детям.

Нужно правильно расставить акценты, рассказать о каждом государственном образовании, об его взаимоотношениях с соседями. Не выпячивать их историю, а объективно ее показать и с уважением к ней отнестись.

Мне возразят аргументом о «переписывании истории». Но мы и без этого являемся свидетелями ее «переписывания». Мы повсеместно в учебниках отказываемся от Киевской Руси, вместо этого употребляем словосочетание Древнее русское государство а ведь Киев – это наше общерусское наследие. «Киев – мать городов русских», – эту фразу вставляет летописец в уста князя Олега. Не надо отдавать ее кому-то на откуп.

К слову, я перечитал недавно статью «Чингис-хан и монголосфера» философа Александра Дугина. Вот как он отзывается о Чингисхане: «Он

не просто организовал железной дланью континентальную административную машину, где мы по началу были данниками, но передал нам основы государственного аппарата, которыми мы пользовались в течение долгих веков». Со многим в этой статье можно спорить, но конкретно вот этот тезис – принимается практически всеми.

Повторяю, академическая традиция изучения русской – российской истории базируется на восприятии России как огромного многонационального и многорелигиозного государства, территория которого простирается от Японии и США включая Польшу и Прибалтику. В.В. Трепавлов задавался вопросом: можно ли считать русские княжества частью татарской Золотой Орды? И он положительно отвечал на этот вопрос, потому что в политическом плане русские княжества не имели субъектности, они не могли вести дела от имени своих княжеств. Их сюзерен – это ордынский хан, который давал ярлык на княжение.

Главная задача современной академической исторической науки – объективно показать, какие государственные образования в разные века существовали на этой территории не только на страницах сугубо научных изданий, но и для массовой аудитории.

И получится, что мы – наследники и скифов (помните у Блока: «Да, скифы – мы! Да, азиаты – мы…»), и тюркского каганата, и Волжской Булгарии, и Золотой Орды. Недопустимо представителей степной культуры считать и показывать исключительно варварами или кочевниками. Не думаю, что варваров среди печенегов было больше, чем среди скандинавов-рюриковичей! О каждом народе, будь то половцы, печенеги или болгары, нужно говорить с уважением, потому что это часть нашей русской истории, нашей культуры.

На днях я получил результат своего расширенного ДНК-анализа. Он показал, что на протяжении полутора тысячи лет мои предки жили и живут на территории той исторической области России, которая называется Мещера. Мой генотип не уходил из этих мест более пятнадцати веков. То есть я коренной представитель автохтонного древнего народа, который полторы тысячи лет живет на этой земле. Генеалогическое древо, которое мы составили на основе метрических книг, изучения ревизских сказок и семейных шаджаре, прослеживается до 1500 г. Таким образом, мы, мои предки – не пришлый народ, мы жили на современной нижегородской земле столетиями.

Поэтому симбиоз разных народов – чувашей, мордвы, удмуртов, марийцев, русских, татар – нужно правильно осмыслять. Это наше великое достояние.

Есть еще и теологический аспект вопроса. Если ты человек верующий, то ты, в конечном итоге, придешь к первочеловеку – к Адаму. Пророк Му-

хаммад, да благословит его Аллах и приветствует, сказал: «Нет превосходства у араба над не арабом, и у не араба над арабом. Как и нет превосходства белого человека над черным, и черного над белым! Превосходство одних людей над другими может быть лишь в богобоязненности». Мы все созданы из праха, мы все – сыны Адама и Евы, потомки их детей. Поэтому как бы вы ни кичились и не гордились своими племенами, народами и историей, вы все равно вернетесь к первочеловеку – к Адаму.

***– Итак, Дамир хазрат, Вы рассчитывали, что Ваш доклад на конференции вызовет научную дискуссию, но вопросов не последовало?***

– Нет, вопросов не последовало. Нужно констатировать, что наше академическое сообщество пока находится в инертном состоянии и плывет по течению, не в полной мере отдавая себе отчет в актуальности всех этих вопросов.

Зато ополчились крайние элементы. От них последовали оскорбления, угрозы физической расправы с предложением лично мне срочно собрать чемодан и покинуть РФ, пока я жив, пока машину не взорвали, жену и детей не подловили. Они подличают, копаются в моей биографии, выискивая личные факты и семейные фотографии. Тем самым они показывают свой же интеллект, свое нутро, свою сущность. И это сильно расходится с образом русских и русского духа, каким мы его знаем. Мой ближайший родственник Максуд-абзый более 65 лет проработал на Горьковском автомобильном заводе. Он всегда говорил нам: «С русскими – не шутите! Они «проснутся», никому мало не покажется. Русского никто никогда не победит в честном противостоянии!» Я с детства слышал эти слова от главы нашего рода, которому на сегодняшний день уже под 90 лет. А глядя на нынешних экстремистов, взявших на вооружение тему «русскости», я прихожу к выводу, что я больше русский, чем они. По духу и по мыслям своим!

Возвращаясь к вопросу о содержательной дискуссии, о разговоре по существу, я хочу подчеркнуть, что флагманом, знаменосцем идеи российского государства-цивилизации является не кто иной как наш президент. Владимир Путин на протяжении многих лет однозначно подчеркивает изначальную многосоставность, многонациональность, многорелигиозность единого российского народа и государства.

А я от себя добавлю, что русские в силу своего мощного духа смогли все эти государственные образования победить и включить в себя. Вот это надо показывать в учебниках истории – что русский дух оказался сильнее, что славянский этнос сильнее. Значит, в нем есть какие-то коды, какие-то элементы, которые и привели к созданию великой России такой, какой мы ее знаем сейчас.

Благодаря русским и России среднеазиатские республики из феодального прошлого шагнули в индустриальную эпоху: русские и татары строили мосты, прокладывали железные дороги, возводили промышленные предприятия, создавали оросительные системы. И если об этом кто-то в Средней Азии забывает, грош им цена. Но большинство людей – умных – не забывает.

Мы, татары, открыто говорим, что наши национальные писатели следовали, учились и подражали Пушкину, Лермонтову, Чехову, Толстому, Достоевскому!

***– Вслед за татарами так, я думаю, многие народы могут сказать!***

– Да, конечно. Но вслед за В.Р. Мединским я говорю: татары – второй государствообразующий народ. До XVI в. доминировали тюрки, русские князья были подданными татарских ханов, они им платили дань и т.д.

Когда я приезжаю в Казахстан, Кыргызстан или Узбекистан, я всегда слышу, какую колоссальную роль с XVIII по начало XX вв. сыграли татарские миссионеры – богословы и купцы! Многие исторические мечети в Казахстане, особенно на севере страны, были построены татарами, и школы были основаны ими. То есть, когда татары, башкиры, которые были частью русского имперского кода и при этом не потерявшие свою идентификацию, шли в эти земли, то воспринимались там как связующее звено с Россией. Так, первый российский муфтий Мухаммеджан Хусаинов (1756–1824) благодаря своим профессиональным дипломатическим навыкам смог склонить к русскому подданству элиту Букеевской Орды, будучи сам породнен с ее представителями.

Нельзя однобоко показывать и обеднять историю нашего российского государства, в котором сегодня «поворот на юг» в политическом плане – это концептуальное решение. Как вы собираетесь идти на юг, если вы узбеку, кыргызу, таджику говорите, что он – варвар, черный, чумазый, узкоглазый, косой, замоташка, абу-бандит, басурман?!

Наоборот, мы должны гордиться тем, что Россия сохранила 190 народов, сохранила языки, и каждый на своем языке прославляет Бога. В этом заключается величие нации. Она сильна по духу, по мысли, по своей литературе.

***– Вам возразят, что сегодня, когда идет Специальная военная операция, поднимать эти вопросы неуместно, несвоевременно.***

– Все ровно наоборот! У нас есть данные по казахским деревням Астраханской и Омской области, там массово молодые казахи отправились на СВО и сложили свои головы в ходе боев. Наши единоверцы в сердцах восклицают: «Если мы чурки, как говорят некоторые, то ради чего наши ребята погибли?!» И эти мысли сегодня западная пропаганда активно внедряет в умы молодых мусульман. Раскачка Западом россий-

ского государства идет по отработанному сценарию. Вспомните СССР, когда проблемы начались на окраинах по национальному признаку: Карабах в составе Азербайджана, Прибалтика, Фергана. Возникли конфликты и внутри России: Чеченская Республика, Татарстан с его государственным суверенитетом. Эта раскачка будет продолжаться согласно уже утвержденной стратегии. Перечитайте книгу «Великая шахматная доска» Збигнева Бжезинского. Он еще в 90-е гг. писал, что для дальнейшего развала нужно отколоть Украину и Казахстан. Нет Украины, Казахстана, Белоруссии, и вы превращаетесь в небольшое унитарное русское государство. Потом отколется Кавказ, ослабнут связи со Средней Азией и Россия скукожится до границ Московского царства. Надо быть близоруким, чтобы этого не видеть! Мы можем получить новые негативные процессы. Вместо великорусского шовинизма появится великоказахский шовинизм, или турецкий, или еще какой-нибудь!

Исследовательская, научно-педагогическая и общественная деятельность К.Н. Санукова получила широкое признание. Ему присвоены почетные звания «Заслуженный деятель науки Марийской АССР» (1986), «Заслуженный работник высшей школы Российской Федерации» (1998), Почетный гражданин города Йошкар-Олы (2000), Почетный профессор Марийского государственного университета (2004), присуждена Государственная премия Республики Марий Эл им. М.Н. Янтемира в области науки (2005), также он награжден орденом «За заслуги перед Марий Эл», орденами, медалями «За заслуги перед Отечеством» II степени и «За заслуги перед Марий Эл», «Ветеран труда», «За доблестный труд. В ознаменовании 100-летия со дня рождения В.И. Ленина», «За гуманизм и служение России, в ознаменовании 100-летия со дня рождения М.А. Шолохова», «За служение народу» (к 100-летию со дня рождения Йывана Кырли).

Имя Ксенофонта Никаноровича Санукова стало одним из символов научного мира Среднего Поволжья. Им были достигнуты такие высоты, которые до него не были покорены ни одним из историков Марийского края. Вечная память ему...

***Редакция журнала присоединяется к этой высокой оценке жизни и деятельности К.Н. Санукова, человека широкой души и истинного ученого. Татарские краеведы помнят и чтят его.***

## ТАТАР РУХЫ

## ТАТАРСКИЙ ДУХ

*Р.С. Курчааков*

# АЛТАЙСКИЙ БИЛИК ПЕРЕМЕН
(*фрагменты книги*)

### Введение

«Билик Перемен» родился на основе осмысления образов «Алтайского Билика». В 2003 г. была опубликована книга «Алтайский Билик – древние корни народной мудрости России» (Казань. ТАУ). С тех пор она переведена и издана на немецком (2006), турецком (2011) и английском (2012) языках.

Образы «Билика Перемен» возникали начиная с 2014 г., в ответ на грозные знаки и знамения глобального цивилизационного кризиса, который вначале только набирал силу и казался тлеющим низовым огнем, а теперь на наших глазах набирает силу верхового пожара.



*Н.А. Шодоев и Р.С. Курчааков у чакы (коновязи) Музея Алтайского Билика, с. Мендур-Соккон, Горный Алтай, 2016 г.*

«Билик Перемен» можно воспринимать как учебное пособие по развитию образного мышления, утраченное современными людьми, но весьма актуальное на крутых поворотах перемен, которые предстоят нам всем впереди. В своей когнитивной (познавательной) основе это современный миф, который в свернутом виде содержит историческую память и векторы судьбы тюркских и славянских народов Евразии. На этой основе и предстоит сделать выбор пути в лучшее будущее для себя, своего народа и семьи народов России. Наконец, «Билик Перемен»

приоткрывает нам весьма своеобразную Алтайскую линию откровений и пророчеств, возникшую задолго до Библии и Корана, т.е. ближневосточной (семитской) линии Всевышнего Откровения. Она отличается тем, что Всевышние Знания были ниспосланы Творцом через явления, образы и законы Матери-Природы.

Большая часть подлинной истории тюркских и славянских народов, свободная от жестких форматов государственности – это неписаная история. Поэтому европоцентричная, сугубо рациональная историческая наука до сих пор исключает эту богатую дописьменную историю коренных народов Евразии из своего «цивилизационного» поля зрения. А в «Книге Писаний» утвердившихся в социуме мировых религий, нет четкого различения «языческого невежества» и полноценного природного (языческого) восприятия мира и Создателя, основанного на единстве Веры и Знания (Билим).

В отличие от китайцев и многих других народов, тюрки и славяне по своему культурному коду открыты переменам. И это должно вселять не только надежду, но и уверенность в том, что именно в бурном потоке перемен они обретут свой новый достойный уклад жизни.

*Рустам Курчааков, 9 апреля 2025.*

**Знание (Билик) Перемен**

*Николаю Андреевичу Шодоеву, учителю*

1
Поток перемен непознаваем,
хотя его первопричины и истоки,
содержатся в пророчествах скитающихся народов (сары).

Открытые им знания записывались в разное время и разными людьми.
Они составили Книгу Писаний – Библию и Коран.

Для большинства Людей Книги ее смыслы давно забыты и закрыты,
потому что свет былых откровений погас,
а на новые пророчества наложена печать.

2
Помимо пророческих Писаний, пережитый народами опыт перемен
содержится в преданиях – мифах, легендах, былинах, сказках и песнях (кай)
народов, укоренившихся в своих ландшафтах (кара) и
сохранивших связь времен и связь с Природой.

Скитающиеся народы, потерявшие связь времен
и построившие из Природы искусственную цивилизацию,
называют их аборигенами, но разногласят насчет собственных имен.

3
Предания народов, укоренившихся в своем ландшафте, нерелигиозны,
потому что возникающие вероучения смываются потоком перемен,
а те, что записываются в Книгу (Бичик), оседают на дно реки.

Попытки придать им религиозную окраску
или заключить в оболочку мировых религий
обнаруживают более древнее сокровенное знание – Билик.

Билик не воспринимается без остатка научным и религиозным сознанием,
выходит за их пределы и обладает самостоятельной ценностью.

4
Предельное Знание (Билик) на стыке видимого и незримого
невыразимо словами, поэтому обладает наивысшей концентрацией смыслов
по критерию соотношения Знание – Информация.

Символы и знаки Билика, как и все, что создается и передается людьми,
содержат ошибки и искажения времени и места,
неточности восприятия, передачи и толкования.

Невыразимое Знание вечно обновляется, передается и наследуется
благодаря живому и вольному человеческому восприятию.

Весло и спасательный круг для пребывающего в потоке.



*Река Катунь (Хатын).*

## Вступление в Поток

8
Река жизни омывает два берега.
Различение берегов становится первым узлом в сети восприятия.
Берега различаются как правый и левый, мужской и женский,
крутой и пологий, сухой и влажный…
Различение берегов начинается от истока реки.

Есть бесчисленное множество камней и песчинок по берегам реки.
Есть бесчисленное множество признаков различения берегов.
Но лишь один из них – невидимый среди видимых –
отражает суть времени в двойственности сущего.

9
Когда поток перемен переполняет старое русло,
правый берег становится круче и возвышается над волнами,
пока не обрушится и не будет унесен потоком на новое место.
На месте берега остается лишь трех-вершинная гора Уч-Сумер.
В это время левый берег размывается и топится водой потопа.
Волны перемен гуляют по ней, смывая поселения и державные постройки,
пока река не очистится и не создаст новое русло.

10
Камешки и осколки правого берега оседают на дне и на берегу
образами и знаками Алтайского Билика.
Учитель, собирающий камешки-билики на берегу,
хранит их в музее и книгах.
Он говорит – Я ни кам, ни шаман и ни ярлыкчи,
я только собираю крупицы мудрости своего народа.

11
Истории берегов, собранные вместе, становятся историей ТюрКитая –
великой реки, протекающей по Матушке Евразии.
Когда река течет к Западу (КунКер), Солнце (Кун, Јар, Ярило) слабеет,
и люди питаются отраженной энергией Луны,
а берега реки меняются местами.

Левый берег редко заселен, его жители не оседлые и не кочевые.
Правый же берег плодится и размножается продуктами и людьми.
Процветание делает людей лунного света оживленными сверх меры,
они теряют связь времен и встречают восход на западе.

Тот, кто построил мост, владеет берегами.
Те, кто спорят о том, строить ли мост вдоль реки или поперек,
никогда не договорятся.

Сеть восприятия тяготеет к правому берегу или к левому.
Кто сплетает Сеть восприятия, ловит рыбу у своего берега.
Кто сплетает большую Сеть и переплывает на другой берег,
тот всегда с богатым уловом.

12
Женщина, овладевшая искусством ветра и воды (Фен-Шуй),
усмиряет мужчину, убаюкивает, как ребенка, и может усыпить.
Мужчина, познавший Путь воды (Фэн-Су), испытывает неутолимую жажду
и становится на Путь огня, если поймает свой Ветер.
Пока мужчина ловит свой ветер, женщина одинока на берегу.
Когда мужчина становится на Путь огня,
женщина овладевает искусством соединения Земли и Неба.

13
История левого берега записана в ДаоДэЦзин,
Книге перемен и тысяче других книг.
Подлинная история правого берега никем не записана,
она лишь отражается на зыбкой поверхности левого берега,
когда он покрыт потоком или потопом.

Билик и ДаоДэЦзин.
В потоке перемен они рождают Книгу-Бичик: ДаоБуЖизнь.
Страницы ее перелистывают ветра и волны.
На дне реки покоится Книга Судур.
Когда река потечет в Небо, берега соединятся.

## Различение смыслов

14
В реке жизни три глубины и три потока,
по ней плывут трое – Охотник, Мастер и Хозяин.
Соединенные на Раз-Рас (3×3×3), они образуют Куб.
Великий Куб не имеет углов.
Резонируя с Кангыем, он обретает форму яйца.
Обретая форму яйца, он питает родники реки (Бурханы).




*«Небесное Яйцо» КАНГЫЯ, Кук-Ай.*

15
Хозяин поддерживает берега и тихие заводи,
хранит богатые рыбой места и нерестилища.
Редкий Хозяин ведает волю Неба.
Такой Хозяин всегда одинок, его называют великим.

Мастер ведает потоки и глубины, знает породы рыб, их пищу и приманки.
Редкий Мастер знает природу и породы людей.
Такого называют Искусным Мастером.
Обладая Знанием, Искусный Мастер сплетает сеть,
с которой Охотники выслеживают и вылавливают из реки рыбу смыслов.

Каждый Охотник Желает Знать, где Сидит Фазан,
но это Знание дается только одинокому Охотнику.

16
Охотник отличается от Воина и дворцового Стражника.
Мастер отличается от Шамана, Ученого и Священника.
Хозяин отличается от Приказчика (Менеджера).

Различение сути людей и вещей дается искусством Фуркана (аль Фуркан).
Искусство различения основано на знании Бурханов –
родников, питающих реку жизни и первоисточники смыслов.

17
Имена Бурханов открываются прозорливым людям,
которые вглядываются в глубину Кук-Тенгри.

Многие великие кааны стремились познать Кук-Тенгри,
но их смыло потоком времени.

Все видят бездонное синее Небо, но никто не знает имени Кук-Тенгри.
Я знаю, ты знаешь, он знает.
Кто говорит, что ничего не знает?

18
Охотник, Мастер и Хозяин хранят знания об именах,
оберегая их от искажений суеты, корысти и глупости.
Для сохранения в поколениях имен Бурханов и искусства Фуркана
используют знаки, символы и ритуалы.

Со временем знаки, символы и ритуалы уносятся волнами перемен,
и тогда в головах наступает смута.
С наступлением смуты Охотник, Мастер и Правитель
возвращаются к истокам реки – родникам и первоисточникам,
чтобы посмотреть правде в глаза и назвать вещи своими именами.

19
Когда трое вместе, каждый живет в Ала-гармонии –
в ладу с самим собой, Природой и другими людьми.
Кто видит Ала-гармонию, тот мыслedействует в состоянии Улалу.

Разделение троих ведет к войне.
Война не начнется, пока трое не разделены.

На время войны Охотник становится Воином,
Мастер – Стратегом (начальником штаба), а Хозяин – полевым командиром.

Собравшись втроем, они образуют Роту,
а после войны собирают Артель.



*Сказочный оберег: человечек в земном яйце ауры, Јымыртка.*

**Время Перемен**

20
Установленный порядок вещей и образ жизни людей
кажутся неизменными, пока не наступит время перемен.

Перемены это образ жизни времени.
В переменах время живет, цветет и плодоносит.
Вне перемен оно только длится, постепенно теряя энергию жизни
и накапливая застойную энтропию.

Социальная энтропия высушивает реку жизни
и рождает социальную пустыню,
которая в своей безысходности хуже нищеты.

21
Перемены трехфазны, как электрический ток.
В них подвижны прилив и отлив, а устойчивым кажется берег.

Отлив энергии жизни обнажает привычную Реальность
и вскрывает непривычную Действительность,
прежде скрытые в суете обыденности.

Берег становится шире – обнажается его подоплека.
Восприятие срывается с берега и уносится ветром эмоций.
Между видимой Реальностью и осмысленной Действительностью
Начинается взаимное уничтожение.

22
Стоящие на берегу суетятся – стараются
связать порванные связи Реальности с Действительностью,
вновь назначить причины и следствия.
Но концы с концами не сходятся.

Таковы снующие по берегу: не хотят научиться плавать,
но стремятся к противоположному берегу,
тщетно строят защитные сооружения от ветров и волн перемен,
но не видят собственного берега.

А с приливом приходит другая вода, новый берег и трехфазное восприятие.

23
Причины и неизбежность перемен заложены в истоках реки.
Они целиком подвластны воле Неба.

Приход перемен напоминает людям,
что жизнь не бесцельна и не бессмысленна,
а периоды постоянства – испытание гордыни и эгоизма,
заставляющие «остановить прекрасное мгновенье».

Постоянство связано с человеческой слабостью,
перемены открывают новые силы и возможности.

Смертный человек тщетно стремится к постоянству и покою,
а неуспокоенная душа ищет перемен и попадает в поток.

24
Поток перемен проходит три поворота:
вначале поднимается ветер перемен,
затем вздымаются волны перемен,
наконец, приходит время потопа,
который производит полную перемену ландшафта.
Ландшафт складывается из Неба, Горы, Реки и Долины.

Когда задует порывистый ветер перемен,
умные задаются вопросом – Кто виноват?
После определения виноватых их выносит толпа,
и к власти приходят худшие.
После прихода худших поднимаются волны перемен,
и умные задаются вопросом – В чем причины?
После определения причин толпа сносит надежные основания,
мосты и защитные плотины, сооруженные виноватыми.

Немногие способны плыть против течения.
Немногие из тех, кто плывет против течения, выберутся на новый берег
и расскажут другим, что надо делать.

25
Время перемен несет новые ощущения, образы, слова, дела и уклады жизни.
Многие предчувствуют перемены, но немногие озаботились.
Из тех, кто озаботился, лишь немногие озадачены и пошли в разведку.
Из тех, кто озадачен и пошел в разведку будущего, только горстка
способна нащупать свое намерение жить и предпринять его.
Только избранные из числа намеренных и предприимчивых
создадут совместным сверхусилием новые уклады жизни и хозяйства.

Вначале их будет трое, за ними последуют тридцать три,
а потом вирус перемен распространится как эпидемия.

26
Ветер перемен и волны перемен.
Ветер перемен каждому приносит случай сделать выбор –
каким следовать путем по берегу или какой рекой плыть в потоке.
Тот, кто живет у реки, ловит свой ветер.

Оказавшиеся в потоке делятся на три категории.
Первые плывут по течению.
Вторые пересекают реку и продолжают путь на другом берегу.
Третьи плывут против мейнстрима.
Они достигают наибольшей глубины,
погружаясь в принимающий их встречный поток.

Однако большинство не верит и отказывается от своего выбора,
уступая его другим – обстоятельствам и хозяевам жизни.

27
С включением третьей фазы алгоритм перемен переходит в спираль,
резко уходящую в Небо и штопором проникающую в Землю.

Привычный порядок длящегося времени 1 2 3 4 5 6 7…… ломается
и вытесняется алгоритмом перемен: 1 3 7 13 21……

Сидящие на берегу воспринимают это как линейное ускорение,
поэтому в головах возникает смута из-за хаоса неожиданных событий.

Плывущий в потоке ощущает течение нового времени,
видит берег, к которому он плывет,
и знает, из чего он построит новую жизнь.

28
Подвижный воспринимает лучше, чем стоящий на берегу –
у него есть шанс подойти к потоку.
Сидящий на коне (Ир-Ат) видит иначе, чем идущий пешком и
плывущий в потоке,
поэтому вместе они собирают достоверное Знание,
не записывая его, но постоянно исправляя мнения и суждения.

Сидящий за рулем автомобиля не владеет собственным восприятием.
Его восприятием управляют те,
кто обслуживает его автомобиль и дорожные правила.

### *Комментарии*

**Рас** (тат., древнетюрк). – единица смысла, знания, правды и мысле-действия. Отсюда русское выражение «Сделать на Раз».
**Кангый** – Небесное Яйцо, Кук-Ай. В «Алтайском Билике» это невидимый Всевышний космический Дух, а «тело» Кангыя – видимая и доступная нашему знанию Галактика.
**Земное яйцо – Јымыртка** (алт.) – сгусток энергии в скорлупе, Йомырка (тат.)
**Бурханы** в «Алтайском Билике» это священные места, где зарождаются различные формы жизни – растительные, животные, неорганические, человеческие и др.
**Великий Куб** это земная Матрица имен и смыслов, с помощью которых человек познает окружающий мир и самого себя. Познавая мир, люди складывают знания и опыт в Куб. Куб, кубышка изначально обозначали сосуд яйцеобразной формы. По мере накопления знаний Куб становится Великим и уподобляется Кангыю. В конце времен Великий Куб соединяется с Небесным Яйцом Кангыя. Такое соединение-слияние обеспечивается:
– Вращением.
– Фракталом троичности.
– Энергией эгрегора.
**«Каждый Охотник Желает Знать Где Сидит Фазан»** – обозначение цветов Радуги.

**Аль Фуркан** (араб.) – различение через сравнение – одно из имен Книги Корана.
**Кук-Тенгри** – бездонное синее Небо, состоящее из 9 и 99 Небес.
**Ала** – древнейший тюркский корень, выражающий разнообразие и гармонию окружающего мира. В наше время остатки сакрального смысла сохранились в слове «пестрый» (масть коня).
**Уалу** – от корня Ала, выражает мысле-действие человека, направленное на сохранение и утверждение первозданной Ала-гармонии. Также Уалу – прежнее название Горно-Алтайска, нынешней столицы Горного Алтая.
**Артель и Рота** – слова единого тюрко-славянского корня (См.: Словарь В. Даля).



*Радуга над Каракольской долиной, Горный Алтай.*

*Айдар Хәйретдин*

# «ҖЫК!», ЯКИ ТӨРКИ-ТАТАР ТАРИХЫНЫҢ БЕР СҮЗДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

Адәм баласының балачак хатирәләре күңеле түрендә җан биргәнгә кадәр сакланадыр, мөгаен. Миндә дә шулай – хатирәләр күп, шундыйлардан берсе телебез хәзинәсенә кагылышлы. Авылдагы бер балачак дустым берәүгә ачуы чыкса, кашларын җыерып, күзләрен усал итеп кыса төшеп тегене: «**Җык**!» – дип сүгә иде.

Бу сүзнең мәгънәсе миңа билгесез иде, аның ниндидер начар нәрсә булуын гына аңладым. Шул чактан бирле ул сәер җык сүзен башка ишеткәнем булмаса да, аның ни белдергәнлеге бер җавапсыз сорау булып күңелемә сеңеп калган икән. Кайчан да булса әлеге сүз мине кызыклы бер фикергә, гипотезага китерәчәк дип, әлбәттә, уйлап та караганым булмады. Тик, дөнья булгач, ниләр булмас? Һич көтмәгәндә, бу сүз хәтерем төпләреннән калкып чыкты. Эшнең асылы болай булды: көннәрдән бер көнне кулыма мәшһүр төркиятче галим И.Л. Кызласовның «*Рунические письмена Сибири. Рассказы археолога*» (2021) исемле китабы килеп керде. Бу әсәр белән якыннан танышуымның, мавыгып укуымның насыйп сәгатьләре җитте. Китапның эчтәлеге үтә дә кызыклы: моннан мең – ике мең ел элек яшәгән борынгы төрки бабаларыбызның югары мәдәният әһелләре буларак *битик*/*бичик* (хәзерге фәндә *руналар*, *руник язу*) дип аталган махсус билгеләр уйлап чыгарулары, шул билгеләр, ягъни хәрефләр белән тау кыяларында, торараташ вә балбалларда очлы тимер белән уеп безнең көннәргә кадәр сакланып килгән язмалар калдырулары, ул борынгы ташъязмаларның табылу һәм өйрәнелү тарихы – болар һәммәсе Кызласовның талантлы хикәяләве бәрәкәте белән хыялымда еракта калган дәверләр, гүзәл табигать манзаралары, шунда гомер иткән кавемнәр, кешеләр пәйда булалар, язулары аша миңа кичерешләрен җиткерәләр, уй-хисләре белән уртаклашалар.

Инде ***җык*** сүзенә әйләнеп кайтыйк.

Башта әлеге сүзнең хәзерге вакытта татар тел белеме күзлегеннән карап, аның нинди мәгънәләргә ия булуын күрсәтәсем килә. Моның өчен Казанда 1981 елда басылып чыккан «*Татар теленең аңлатмалы сүзлеге*», Рифкать әфәнде Әхмәтьянов төзегән «*Татар теленең этимологик сүзлеге*» (2015) һәм «*Электронный фонд словарей*» кебек чыганакларга мәгълүматка мөрәҗәгать итик. Боларда әйтелгәннәрне тикшерә башлаганчы игътибар үзәгендәге ***җык*** сүзенең тискәре мәгънәгә ия булуын да истә тотыйк, чөнки минем югарыда искә алынган балачак дустымның

авызында бу сүз тиргәү иде. Шуңа күрә аның фәнни чыганакларда китерелгән мәгънәләренең тискәреләренә игътибар итәчәкмен.

«*Татар теленең аңлатмалы сүзлеге*»нә караганда, ***җык*** сүзенең исем буларак аерым кулланылмавы ачыклана. Ул бары тик сүзтезмәләрдә кулланыла:

***җык булу*** сүзтезмәсендә килеп ул *тәмам туеп, арып бету, гарык булу* мәгънәләрен белдерә;

***җык кергере*** (***тигере, булгыры***) дигән сүзтезмәдә *тиргәү*, *каргау* сүзе буларак килә, һәм, ниһаять;

***җык кебек*** дигән сүзтезмәдә *әзмәвердәй*, *зур гәүдәле*, *таза* мәгънәләренә ия булып чыга.

Моннан тыш «җык» сүзеннән ***җыклану*** ягъни *җык булу*, *интегү*, *җәфалану* мәгънәләренә ия булган исем фигыль дә ясала икән.

Инде Р. Әхмәтьяновның «*Татар теленең этимологик сүзлеге*»н ачып карыйк.

Биредә ***җык*** сүзе «в растерянности; в изнеможении; нужда; сап (болезнь лошадей)», ягъни *аптырау*, *югалып калу*; *әлсерәү*, *хәлсезләнү* кебек хәлләрне һәм атларны интектерә торган бер чирне белдерә.

«*Электронный фонд словарей*» исемле чыганакның күрсәтүенә күрә, ***җык*** сүзе ***җик*** рәвешенә китерелә һәм аның мәгънәләре урыс теленә тәрҗемә ителгәндә «нечто отвратительное, крайне трудное; мерзкий» булып чыга; ***җик булу*** «омерзеть» була. Сүзнең язылышын болай үзгәртү, миңа калса, хатага китерә, чөнки *җик* дигән сүз ялгызлык исеме, яки иҗтимагый дәрәҗә билгесе (титул) булып йөргән, мәсәлән, «Җик Мәргән» дастанын искә алу да җитә.

Тугандаш телләрнең кайберләрендә (каракалпак, кыргыз телләрендә *җек*, карачай-балкар телендә *җэк*, алтай телендә *дьек*, *дьеек*, *чэк*, төрекмән телендә *йек*, хакас телендә *чек*/*чик*) бу сүз «әшәкелек, әшәке, кабахәт, явыз рух; җирәнгеч» мәгънәләрен белдерә.

Безнең өчен иң кызыклысы ***җык*** сүзенең коман, уйгыр, чыгытай, чулым татарлары телләрендә сакланып калган мәгънәләре. Бу телләрдә *jäk* һәм *чäк* булып яңгыраган бу сүз *җен*, *хәтәр*, *явызлык*; *усал зәгыйфь*, *унике башлы шайтан* булып килә. Чуаш телендә *йăх* дип яңгыраган бу сүз «яман чир; явыз рух» булып килә. Моннан тыш, шул ук телдә бу сүзнең «*йĕк*/*йĕп*» шәкелендәге әйтелешләре да күзәтелә: «*Йĕк ура айĕнченех тухать*» (йĕк/җык аяк астыннан чыга); «*Çĕр çурăлса йĕк тухтăр*!» (Җир ярылып йĕк/җык чыксын!). Бу очракларда *йĕк* сүзе «*яман ия*» (злой дух), «*кабәхәт, җирбит*» (гадина) мәгънәләрен белдерә [Ильина: 2025]. *Йĕк* сүзе *jэ̆к* (җык) итеп тә укыла ала, мәгънәсе дә баягыча тискәре коннотациядә кала, ягъни кемне дә булса сүгү сүзе, «эт!», дигән кебек; «*Йĕк* (*jэ̆к*) – гад, гадина [Словарь: 2025].

Хәер, югарыда китерелгән нәрсәләргә И.Л. Кызласов китабында язылганнарның нинди катнашы бар, дигән сорау туарга мөмкин. Катнаш бар, һәм аның тәэсирендә барлыкка килгән фикер толымнары бик кызыклы юнәлештә ишеләләр, үреләләр.

Искә алынган китапның 106 битендә мондый сүзләр бар:

*Күк-кыяда язылган һәм, кызганыч ки, тулысынча анык булмаган бер битиктә, җен искә алына. Анда кулланылган йәк (хакас телендә чик әйтелеше белән сакланган) сүзе санскриттан алынма буларак, буддачылык язмалары белән таныш булучылыкка ишарә итә һәм төрки телдә язылган манихәй язмалары өчен гадәти күренеш булып тора* [Кызласов: 2021. С. 106] (татар теленә тәрҗемә ителде).

Ягъни, хәзерге вакытта ***җык*** (*җак / җәк / җек / йек / чак / чӓк / чик / / чык / дьек / йӓх / jәк / йӗк / jäk*) рәвешендә яңгыраган бу сүз үзенең иң борынгы семантикасында *җен* (шайтан, демон) мәгънәсенә ия булып, *табигать ияләре* арасында иң усал, иң явыз булган берсен белдергән.

Минем мәктәп яшендәге балачак дустым – гади авыл малаеның әлеге сүзне иң борынгы һәм шуңа күрә асыл мәгънәсендә куллануы, ягъни ачуын чыгарган берәүгә «Җык!», дип, ягъни, хәзергечә әйткәндә «Җен!», «Шайтан!», дип әйтүе үзенә күрә кызыклы бер күренеш булып тора. Әмма бу сәер сүз тудырган мәсьәләнең икенче бер кызыклы ягы да бар. Идел буе татарларының кан тамырларында мул итеп борынгы болгарларның да каны агуы фәндә күптән мәгълүм булган хакыйкать, шуңа күрә аңа аерым тукталып тормыйм. Кара диңгезнең төньяк ярларыннан алып Идел-Чулманга кадәр җәелгән географик җирлектә соңрак дәвердә болгарлар дип аталачак кабиләләр берлеген оештырасы ыругларның археологик эзләре V гасырдан бирле күзәтелә башлый [История: 2017. T.I. С. 183–184]. VII–VIII гасырларда әлеге ыруглар Сура, Идел, Чулман, Агыйдел, Җәек елгалары белән Урал таулары арасына барып җитәләр дә, шунда урнашып IX гасырда Болгар дәүләтенә нигез салалалар. Алга таба безгә әле генә телгә алынган V–VIII гасырларны истә тотарга кирәк, чөнки И.Л. Кызласов китергән мәгълүматны, ул атаган даталарны истә тотып бераз фикер йөрткәндә бик кызыклы нәрсәләр килеп чыга.

И.Л. Кызласов болай дип яза:

*Күпсанлы борынгы тау, елга һәм башка табигый нәрсәләрнең ияләрен үзенең мәһабәт сыны белән алмаштырган, яки, әгәр теләсәгез, буйсындырган бердәнбер Илаһ нәрсә соң ул? Ташъязмаларның эчтәлеге әлеге мәсьәләне дә хәл итәргә мөмкинлек бирә... Бу язмалардан кала тикшеренүчеләргә – борынгылык белгечләренә хәзерге көндә билгеле булган һичбер язма чыганак безнең якларда моннан 1200 ел элек булган дөньяга карашның алмашуы турында хәбәр бирә алмаячак* [Кызласов: 2021. С. 99].

Бу галим үзенең китабын 2021 елда бастырган. Шуннан башлап тарих буйлап үткәннәргә таба 1200 ел чигенсәк, без VIII йөзъеллыкка барып җитәбез. Ягъни, VIII гасырда Себердә яшәүче борынгы төркиләрнең бер өлеше потларга, ияләргә табынудан арынып тәүхид диннәренең берсе булган мәнихәячелек[1] динен кабул итәләр һәм әлеге тирән рухи үзгәреш ташъязмаларда чагыла башлый:

*Анасәйнең тәүхид белән бәйле булган ташъязмалары илаһның исемен атамыйлар, һәм бу, әлбәттә, тиктомалдан түгел. Шулай да, аны белдерү өчен кулланылган сүзләр шактый күркәле. Ташны тырнап язылган берничә юлда ул илаһ чал мәҗүсилеккә барып тоташкан һәм Күкне белдергән борынгы* ***тәңре*** *сүзе белән атала. Безнең язмаларда, Тәңрегә юнәтлелгән догалардан күргәнебезчә, бу сүз белән инде урынлата күкләргә бәйле булса да, шулай ук җир биләмәләрен дә идарә итүче бердәнбер илаһны атыйлар* [Кызласов: 2021. С. 100].

Югарыда әйтелгәннәрдән, миңа калса, бик тә кызыклы сорулар туа.

Башта ***Тәңре*** сүзен алыйк. XIX гасыр ахыры, XX гасыр башында татарларда нәшер ителгән дини әдәбияттә бу сүз Аллаһны белдерер өчен бик еш кулланылган. Хәтта «Аллаһ Тәгалә» дигән гыйбарә урынына «Тәңре Тәгалә» дигән гыйбарә кулланыла торган булган. Сибириядәге борынгы ташъязмаларда бердәнбер илаһны белдерә башлаган бу борынгы сүзнең ничә гасырлар үткәннән соң да татарларда шул ук мәгънәдә Аллаһка карата кулланылуы гаҗәеп нәрсә. Әйтерсең, дини китаплар язган татар мөселман язучылар һәм дин галимнәре борынгы дәвердә язылган ташъязмалардан үрнәк алганнар. Тугандаш төрки кавемнәрне никадәр ерак аралар, никадәр гасырлар аерып торса да, алар арасындагы рухи багланышлар беркайчан да өзелмәгән диярсең. Киресенчә, ул бәйләнешләр һаман тере, һаман исән, һаман җанлы булып торган дигән тәэсир кала. Әлеге гаҗәеп рухи бердәмлекнең сәбәбе нидә? Аның асылы нидән гыйбарәт? Бу сорауларга җавап бирү йөзеннән түбәндәге уйларым белән уртаклашасым килә.

Сибириядә яшәп калган борынгы төркиләрнең бердәнбер илаһны тәңре дип атаулары, аны шул рәвешле күзаллаулары XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәп иҗат иткән татарларга кисәк кенә күчеп пәйда була алмаган, әлбәттә. Бу сүз болгарларда да, соңрак – татарлар-

[1] Мәнихәячелек – III йөзъеллыкта хәзерге Иран биләмәләрендә барлыкка килеп, үзенә зәрдәшт диненең, гностик христианнарның, буддачыларның карашларын сыйдырган дин. Диннең мәнихәй дигән атамасы аңа нигез салган *Мәни* исемле кешенең исеменә *хәй*, ягъни «терек» сүзен кушылуы белән ясалган. VI гасырда бу диннең үзәге Сәмәрканд шәһәренә күчә, ә VII–VIII гасырларда Чинга (Кытайга) үтеп керә. 762 елда Уйгыр дәүләте башлыгы булган Бөгү Каган мәнихәй динен рәсми рәвештә кабул итә. Моннан соң яңа дин зур тизлек белән Көньяк Сибирия төркиләре арасында да тарала башлый.

да да өзлексез рәвештә яшәп килгән, сөйләмдә һәм язмада кулланылган. Димәк, эш әллә кайчан бер-берсеннән аерылган төрки кавемнәрнең һәммәсендә дә буыннан буынга Тәңре сүзенең күчеп килүенә генә кайтып калмый. Бердәнбер илаһны күзаллау, аңа ана телләрендә булган сүз белән дөрес исем бирә алу Сибирия төркиләренең дә, Көнбатышка күчеп киткәннәренең дә акылларында, каннарыда, күңелләрендә булган.

Әмма биредә болгарларның V гасырга кадәр үк Сибириядән күчеп киткәннәренә күрә, мәнихәя дине белән танышып өлгәрмәгән булуларын ныклап истә тотарга кирәк. Бердәнбер илаһ турында болгарлар IX гасырда гына, ягъни Сибирия төркиләреннән йөз ел соңга калып белә башлыйлар дип фаразларга мөмкин. Икенче фаразга күрә, алар андый илаһ турында иртәрәк, ягъни VIII гасырда хәбәр алган булырга мөмкиннәр. Кайдан һәм кемнәнме? Кавказны, Мәвараәннәһерне яулап барган гарәпләрдән, әлбәттә. Тик һич тә Сибириядә калган кардәшләреннән ишетеп түгел. Ничек кенә булмасын, алар ул илаһны, Сибириядә калган кардәшләре белән киңәшләшмичә, шул ук ***Тәңре*** сүзе белән атаганнар һәм бу төшенчәне XX гасыр башына кадәр саклап калганнар.

Икенче бер сорау баягы ***җык*** сүзе белән бәйле. Тәңре сүзенең тарихы белән чагыштырганда бу сүзнең маҗаралары күпкә катлаулырак, аның тарихы тудырган сорауларга җавап бирү дә кыенрак. И.Л. Кызласовка күрә, тамыры буддачылыкның ана теле булган санскрит теленә тоташкан бу сүзнең VIII гасырда Сибирия төркиләре арасында мәнихәя дине таралган дәвердә телләренә дә үтеп кергән. Бәлки шулайдыр да. Әмма минемчә, бу сүзнең тарихы башка да булырга мөмкин. Аның иң борынгы дәверләрдән үк төрки сүз булуы ихтимал. Чөнки Сибириядән V гасырга кадәр китеп, V–VII гасырларда Кара диңгез буйларында урнашып, соңыннан VIII–IX гасырларда Идел–Чулман–Урал арасында барып җитеп яшәгән болгарлар тәңречелек динен тотканнар. Дини ышануларга бәйле булган терминнар һәм төшенчәләр башка бер халыкның теленә бары тик аларның шул динне кабул итүләре нәтиҗәсендә генә үтеп керә ала. Шуңа ***җык*** сүзенең болгар теленә Сибириядә калып манихәя динен кабул иткән төркиләрдән үтеп керә алуы бик шикле.

Югарыда әйтелгәннәрдән нинди нәтиҗәләргә килергә мөмкин? Нәтиҗәләр берничә:

– ***Җык*** сүзе – төрки сүз.

– ***Җык*** сүзе төрки телдән башка телләргә дә үтеп кергән булырга бик мөмкин. Төрки халыкларның борынгылыгын истә тотканда, бу фикер акылга сыймаслык нәрсә булып күренми. Тын океанда сәфәр итеп зур фәнни ачыш ясаган Тур Хейердалны гына искә алыйк: үзенең салына ул «Кон Тики» дигән исем куша. Бу исем белән Тын океан буйлап сибелгән

Полинезия утрауларында яшәүче халыклар үзләре табынган Кояш (Көн) илаһын атаганнар. Тики дигән сүз исә төрки телләрдә Тәкә, яки Теки дип әйтелә һәм ул уңыш, муллык, бәрәкәт кебек төшенчәләрне белдерә, шуңа күрә *Көн Теки* – чәчрәп торган төрки исем булып чыга. Шул ук Полинезия кабиләләре телендә Күк илаһының исеме ***Таңгароа*** буларак яңгыравын да искә алыйк. Бу күренеш Күк илаһын гомер бакый ***Тәңре*** дип атаган борынгы төркиләрнең, чыннан да, планетаны, шул исәптән Тын океан утрауларын да ачкан һәм анда яшәгән кавемнәргә нык мәдәни тәэсир ясаган бер халык булуына менә дигән ишарә генә түгел, хәтта нык дәлил булып тора.

***Җык*** сүзе хәзерге татар телендә кулланыла торган *җен, пәри, дию, иблис, шайтан* кебек алынма сүзләрнең борынгы төрки тиңдәше буларак кабул ителергә һәм телебездә искә алынган сүзләр белән бертигез дәрәҗәдә кулланылырга мөмкин дә, лаек та.

**Әдәбият**


1. Ильина Г.Г., Мышкина А.Ф. Традиционные представления чувашей о фольклорном персонаже инкек. [Электронный ресурс] URL: https://www.gramota.net/article/phil20171405/fulltext (Дата обращения: 09.04.2025).
2. История татар с древнейших времен. Т. I. Казань, 2017. С. 183–184.
3. Кызласов И.Л. Рунические письмена Сибири. Рассказы археолога. – Москва, Абакан: Хакасское книжное издательство, 2021.
4. Словарь чувашского языка. [Электронный ресурс] URL: https://ru.samah.chv.su/s/8/йӗк (Дата обращения: 09.04.2025).

*Мәгариф Раянов*

# КЕРИМ ӘЛЕ УРМАННАРГА

Керим әле урманнарга,
Каеннар арасына;
Сөйлим әле моңнарымны
Сандугач баласына.
*(Рөстәм Яхин музыкасы,*
*Гарифҗан Мөхәммәтшин сүзләре)*

Туган җиребезнең узган елның (2024) яз һәм җәй айлары үз вакытларына тәңгәл килә торган матурлыклары белән безнең яшәешебезне канатландырып җибәрделәр дә, үзләре табигатьнең мулдан әзерләнгән үзгәрешләр кочагына кереп сыендылар кебек. Без инде «булганына шөкер» – диюдән башка гамәлләр кыла алмадык...

Алмагачларыбыз чәчәккә бөреләнеп, хуш исләрен тарата гына башлаган иде, гадәти булмаган салкын җилнең дулкыннары астында калып, тирә ягындагы җирләрне бизәү эшләрен генә башкарырга мәҗбүр булдылар. Чәчәкләре җирне бизәү белән шөгелләнгәч, мул яфраклы ботаклары алмаларсыз гына җәйне үткәрергә ризалаштылар. Аннан соң инде корылык көннәре дә безнең тирәгә килеп, яшеллек белән каплана башлаган җиркәебезне үзенә якын итте. Сибелә башлаганда күзгә дә күренмәслек вак кына тамчыларын туктаусыз һаман сипкәли торган болытлары урынына, эреләнеп киткән салкынчарак тамчыларына җилдә кушып коя торган болытларда озак көттермичә килеп, күкләребезне каплап алдылар.

Әйе, табигать ул белә торгандыр инде үзенең ни эшләгәнен. Безгә аны аңлау һәм үзгәртү сәләтләре бирелмәгән һәм бирелмәячәктер дә шул. Табигатебездә булган мондый үзенчәлекле үзгәрешләрнең тәэсире кешеләрне дә читләтеп үтмәгәннәрдер инде. Мин дә үземнең ел саен июль азакларында башкара торган эшләремне онытып, 22 август көнне генә миллек (мунча себеркесен) бәйләр өчен каен ботакларын җыярга ниятләп, бакчабыз янындагы салкын чишмәле тарлавыкның сул як ярындагы урман тирәсенә юл алдым. Ул урман читендәге кырларны элеккеге елларда сөреп, эшкәртеп арыш, бодай һәм кайчакны – борчаклар да чәчеп үстерәләр иде. Ә без инде, бакчадагы бетми торган эшләребезне туктатып торып, шул басуларның читләреннән генә арыш башакларын, бодай башакларын уып, ә инде борчак булса – кузакларыннан аерып – яшел арыш, яшел бодай, тәгәрәп чыккан яшел борчаклар белән сыйланып, аларның тәмлелегеннән бөтен дө-

ньябызны онытып, авылдагы балачак елларына кайтып килгәндәй хис итә идек үзебезне…

Хәзер инде ул җирләрне сөрмиләр. Анда хәзер төрле чәчәкләр, алардан аерылырга теләмәгән әрем, алабута, әрекмән, билчән, хәтта кычытканнар да гөрләшеп үсеп утыралар. Беренче карауда бу күренеш, сөрелми калган җирләрдә була торган гадәти хәл кебегерәк кабул ителсә дә, монда игътибарны җәлеп иткәннәре әрем-әрекмән түгел, ә кечкенә буйлы наратларның нәни ылысларын тырпайтып, мулдан чыгып үсә башлауларыдыр. Бу инде, без ачыклап бетерә алмаган тарихның беренче бите түгелме соң? Димәк монда элеккеге гасырларда гөрләп үскән зифа буйлы нарат урманнары булган. Кемнәрдер ул урманнарны, ни өчендер кискән…

Нәкъ менә шушы урында, рәттән куелган өч нокта рәвешендәге тыныш билгеләреннән соң, Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы белән идарә итү мәнәфәгатенең 100 еллыгына багышлап 2021 елда чыгарылган «Урман гасырдан да артык яши» дигән 300 битлек китаптан берничә өзек китерсәм, мин кузгаткан урманнар темасын тулырак аңларга ярдәмләшер кебек тоелды:

«Казан ягы электән урманнары белән дан тоткан. XVII гасырда ук алман сәяхәтчесе Адам Олеарий аларның байлыкларына сокланган. Россия буенча сәяхәт иткәндә: «Түбән Новгородтан башлап Казанга кадәр биек яр буйларында бик матур агачлыклар, аерым үсүче куаклар бар. Әйтерсең монда урман очсыз-кырыйсыз», – дип язып калдырган ул. Казан губерниясендә урман ресурслары күп булу сәбәпле, алар әле Петр I идарә иткән вакытларда ук дәүләт икътисади оешмалары трафыннан үзләштерелә башлый. Шулай ук бөтен Идел кораб төзүне контрольдә тоткан һәм Петербургка кораб төзү өчен агач ташыган Казан Адмиралтействосына нигез салына. Кораб төзү өчен күп материал таләп ителгән 1703 елдан Идел-елганың ике яры буенда 50 км ераклыкта үскән бөтен урманнар тыюлык урманнарына кертелә һәм алар Балтыйк верфьләрен тәэмин итү өчен теркәлә. Галимнәр китергән саннар мондый: 1822 елдан 1857 елга кадәр губерниядә ел саен уртача 26 000 гектар урман киселгән (35 ел эчендә 830 697 десятин), Казан уезды 1857 елга 1822 елда булган 56% урман мәйданын югалта».

Менә шул үсеп киткән яшь наратлар тирәсендә, аларга сыеныбырак каен агачлары калкып чыга башлагач, мин аларның астагырак яшел ботакларын бакча кайчысы (секатор) белән иплән кенә кисеп, мунча себеркесен бәйләр өчен алып кайта башладым. Менә шушы ният белән, югарыда әйткәнемчә, соңлабырак булса да махсус рәвештә әзерләп куелган зур капчыгыма секатор да салып юлга чыктым. Елның үзенчәлеклеге аркасында минем «таныш» каеннарымның яфраклары элеккеге еллардагы кебек яшел

нурларын бик үк мулдан сипмиләр иде шул. Мин аларның халәтләрен дөрес аңларга тырышып, сәламнәремне тапшырдым да, урманның эченә табарак юл алдым. Урман читендә үскән зифа буйлы агачлар, җирдәге дымлылыкны мулырак саклаулары нәтиҗәсендәдер инде, яннарына сыенып үскән каеннарның «күлмәкләре» яшелрәк тә, муллырак та иде…

Мин капчыгымны яшел ботаклар белән туплый-туплый, аның авырлыгында тойган халәтемдә урманның эченәрәк, «каеннар арасынарак» атлавымны дәвам иттем… Бервакытны, тулы капчыкның җилкәмне ныгырак баса башлаганын тоеп туктадым да, капчыкны җиргә яткырып, тирә-ягыма караштыра башладым… Мин кайдарак килеп җиттем соң әле? Кайсы яктан урманга кердем дә, кайсы якта микән аннан чыгу юлы?

Элеккерәк елларда урманга керер алдыннан мин кояшка карап: ул – алдамы миннән, әллә арттамы? Уң яктамы? Сул яктамы икәнен абайлап калып, чыгу юлларында җиңел генә таба идем. Ә бүген? Бу эшне башкарырга онытканмын бит… Капчыкны җилкәмә салып, үземчә юнәлеш алып, бер сукмак кебегерәк үләнлерәк җирдән атлый башладым. Үләннәр дә күренми башлады, аркылыда – торкылы корыган һәм чери дә башлаган агач ботаклары ята. Мин аларны шытыр-шатыр сындыра-сындыра, абына-сөртенә алга атлыйм. Каршымда корып беткән ботакларын җәеп юан бәдәнле, озын буйлы, нindидер сәбәптән җиргә ауган агач та ята. Аның аркылы чыгарга мөмкинлек күренмәгәч, мин аны урап үтәргә булдым. Анда да күренеш матурлардан түгел иде. Зур буйлы, юан бәдәнле агачлар тирәли кечкенәрәк буйлы, ботакларын төрле якка сузган вак агачлар, куаклар мыжлап тора. Ауган агачка сулыш алырга да мөмкинчелек булмагандыр инде. Һәм мин дә, моннан ничек үтим микән дип аптыраушта туктап калдым. Җитмәсә, вак куаклар арасында гадәти булган чүп-чарларда күренгәләп яталар.

Җилкәдәге капчык иңсәләремне дә, кулларымны да сызлата башлагач, мин аны җиргә төшереп, куаклар арасыннан сөйри-сөйри уң якка таба атлый башладым. Кайчандыр, кайдадыр мин укыган идем кебек: «Әгәр дә адашсаң, уң якка борыл» – дип. Уң якка юнәлеш алып, чыбык-чытырманнар арасыннан, битемне, кулларымны агач ботакларыннан тырната-тырната, капчыгымны да ташлап калдырмаска тырышып күпме атлаганымны хәтерләмим. Хәлем бөтенләй бетеп, аякларымның да җегәрлеге кимегәнен сизеп, шыбыр тиргә баткач, туктадым да, тирә-ягыма карана башладым, Кара урман чытырманнары уртасыннан берәр ачыклык күренмәс микән дигән ниятем иде… Нәкъ минем каршымда бер ачыклык күренеше пәйда булгач, мин шул якка җирдә яткан төрле халәттәге агачларга кабаттан абына-сөртенә, бөтен калган көчемне җыеп, атлый башладым.

Иншалла! Минем каршымда нарат бүрәнәләреннән бура ясап ятучылар оешмасы икән бит. Шул бура янында бер яшь егет балтасы белән нәрсәдер чапкалап маташа. Мин бөтен рухи көчемне җыеп, иплерәк, ягымлырак итеп дәшергә тырышып, аның белән сәламләштем дә, ул миңа асфальт юлның моннан ерак түгеллеген әйтеп, аның юнәлешен күрсәтте. Мин шатлыгымнан җиңеләеп киткән аякларым белән тиз-тиз атлап, Югары Ослан ягына бара торган асфальт юлга чыгып бастым…

Тырыша торгач, мин миллекле булу дәрәҗәсенә дә ирештем. Хәлдән таеп, егылырлык дәрәҗәдә арыгач, зарлана-зарлана бакчабызга таба атлый башларгамы-юкмы дип асфальт юлда басып торам. Туган җиребезнең мин йөргән тирәдәге урманнарының хәле минекеннән дә авырырак икән лә-баса. Урман ыңгырашмый, наратларның да зарыгып шыгырдаган тавышлары ишетелми. Ләкин хәлләре, минекенә караганда күпкә авырырак икәнлеге «сукыр күзгә дә күренерлек» бит… Ирексездән, моннан «ерактарак» булган бер урманның күренеше күз алдыма килеп басты. Бу инде 1950–1960 еллар тирәсе булып чыкты. Минем ГДРның Лейпциг исемендәге шәһәрендә Совет Армиясенең аерым элемтә батальонында хезмәт иткән елларым. Безнең батальон шушы шәһәрдән берникадәр ерактарак җирлектә «учение» үткәрә. Кабельләрне суздык, аппаратларны тоташтырдык. Шундый матур агачлар үсеп утыра монда. Яшел үлән һәм чәчәкләр дә күп. Мин түзмәдем, взвод командирына мөрәҗәгать итеп: «Товарищ ст. лейтенант, что за это такой большой парк?» – дип сорадым. Ә ул: «Ты что товарищ сержант, это же у них лес такой!» – дип җавап бирде. Андагыдай чисталыкны, андагыдай матурлыкны мин үзебезнең илнең паркларында гына күргәнем бар иде шул… Хәтердә сакланып калган күптәнге мизгелләрне дә искә төшерү бәлки кирәктер. Ләкин алар бит инде үткән эшләр һәм еракларда калган еллар…

Мин урман чытырманлыгыннан исән-имин чыгып, асфальт өстендә күпме басып торганмындыр, анысын әйтә алмыйм, ләкин бөтен тәнемдә, тын алышымда, йөрәк тибешемдә җанга рәхәт бирә торган тынычлык хисләренә күмелә башлагач, бакчабызга таба атлый башладым. Асфальт юлдан атлавы шундый җиңел, әйтерсең лә мин йомшак мендәр өстеннән барам. Аякларым да авыртмый, капчыгымның да авырлыгы сизелми башлады…

Җиңелчә генә такталардан кагылып эшләнеп, яшел төскә буялган капкасын ачып бакчабыз эченә атлагач, үземне тагы да җиңелерәк хис итә башладым. «Җиңеләеп» киткән капчыгымны үзем утыртып үстергән туя агачы янына яткырдым да, «авызын» чишеп шиңә башлаган яфраклы каен ботакларын мунчабыз алдына җәелгән келәм өстенә таратып куйдым… Ә үзем мунча күтәрмесенә барып утыргач, кабаттан уйлар дәрьясында йөзә башладым… Мин бакчабызга бара торган юлның ике як чи-

тендә дә гөрләп үсеп утырган урманнарыбызның матурлыгына һәрвакыт сокланып уза идем. Урманның эченә кереп, аның эчке күренешләренә бүгенге кебек тап булганым юк иде шул. Мин йөргән урыннардагы эчке күренешләрнең тышкы яктагы матурлыкка тәңгәл килмәве, мине бик нык борчуга салды. Бу очраклы гына хәл микән, әллә инде безнең урманнарыбыз өчен табигый күренешме? Ихлас күңелемнән аның очраклы гына булуына ышанасым килә:

Юл буенда зифа буйлы нарат
Бик тә озын булып үскән дә,
Яннарында үскән каен-усак
Никтер калган аннан түбәндә.
Аның янындагы ак каеннар
Яфракларын җиргә сипкәннәр,
Бераз моңсуланган карашлары
Зәңгәр күктән читкә киткәннәр…
Бөдрәләнеп үскән яшь наратка
Рухи көчләр бәлки каеннан?
Шуңа күрә һичтә теләмидер
Җибәргә аны яныннан…
Нараткайга терәк кирәк булса
Каенга да урын ярыйдыр,
Бер-берсенә кул бирешеп яшәү
Алгарышка (яшәешкә) юллар барлыйдыр!

Әйе, ышаныч та, яшәеш тормыш өчен өметләрнең дә яктырак булуы бик тә кирәкле этәргечләрдер. Ләкин, чынбарлыкның ни хәлдә икәнлеген камилрәк рәвештә белеп гамәлләребезне кылу, күпкә мөһимрәктер бит.

Менә ошбу уй-фикерләрем, туган җиребездәге урманнарның биләмәләре зурларданмы, ниндиерәк шартларда алар «гомер кичерәләр», елгаларыбызның ярларын, игеннәребезнең кырларын бүген дә бизәрлек дәрәҗәдә сакланып калганнармы, урманнарыбыз белән безнең мөнәсәбәтләребез уңай юнәлештәме – ягъни табигать тарафыннан безгә бүләк ителгән байлыкларны саклап калу юлында тиешле көрәшне дөрес итеп алып бара беләбезме, дигән сорауларга җавап табасы килә бит… Әлбәттә инде, тарих битләрен кузгатып, кайдан үрнәк, кайдан гыйбрәт алмыйча да дөресерәк гамәлләр кылып булмый торгандыр шул… Мин инде, кузгаткан темага кагылышлы тарих битләрен бик тирәннән «каермыйча», урта мәктәп укучылары өчен Ә.С. Тайсин язган Татарстан АССР географиясеннән башларга ниятләдем.

Урманнар республика территориясенең 16,4% билиләр Кама алдында чыршы, ак чыршыдан торган ылыслы һәм катнаш урманнар, Идел, Кама,

Вятка һ.б. елгаларның биек террасаларында нарат урманнары, Идел алды һәм Кама аръягы районнарында киң яфраклы һәм каен белән усак урманнары үсә.

Районнарның урман белән капланган булулары төрлечә. Кайбер районнар урманга шактый бай: Яшел Үзән, Чирмешән, Мамадыш, Зәй районнары 25%, Октябрь районы хәтта 34,6 процентка урманлы. Киресенчә, Минзәлә, Актаныш, Сарман һәм Буа районнары 5–7%, ә Чүпрәле районы җирләренең нибары 3,4 проценты гына урман белән капланган.

Агач төрләре составы буенча республика урманнары ылыслы урманнарга (урманнар мәйданының 20%, исәптән нарат урманнары 12% җирләрне ала), имән урманнарына (24% тан артыграк), юкәлекләргә (14%), каенлыкларга (11%) һ.б. төрләргә бүленә.

Безнең урманнарыбызга янгын куркынычы зур. Шуның өчен, янгыннан урманнарны саклау чараларын алдан ук күрергә кирәк. Урманга килгән һәр кеше, елның нинди вакыты булуына карамастан, урманда янгын куркынычының зур булуы турында онытмаска тиеш. Урман байлыкларының файдалану кагыйдәләре – киселгән урман урынына яшь урман утыртыларга тиеш. Республикада яңа урман үстерү эшләре зур мәйданда алып барыла. Кыйммәтле агачлар утыртылып, урманның составы яхшыртыла. Хәзер Татарстанда утыртып үстерелгән урманнар мәйданы 240 мең гектарга җитте. Бу сан урман белән капланган җирләрнең 21% тәшкил итә. Шуңа карамастан, республикада урманнар бик аз. Бу хәлне яхшыртыр өчен авыл хуҗалыгы производствосында файдаланылмаган барлык җирләрдә, авыллар һәм шәһәрләр тирәсендә, төрле буш җирләрдә, юл буйларында, нык эрозияләнгән кырларда, ерымнарда, балкаларда һәм шуңа охшаган башка җирләрдә агач утыртырга, урман үстерергә кирәк. Урманнар мохитне саклау һәм халык ихтыяҗларын тәэмин итү ролен үтәсен өчен, республикабызның урман белән капланган мәйданын 25–30% җиткерү мөһим.

Менә шундыйрак киңәшләр белән тәмамлана география дәреслегенең «Үсемлек ресурслары» дигән бүлекчәсе.

2018 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов 2019–2028 елларга Татарстан Республикасының урман планын раслый. Шулай ук төбәктә Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр урман хуҗалыгы үсеше стратегиясе эшләнә. 2019 елда Татарстанда «Экология» милли проекты «Урман саклау» проекты кысаларында «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты тормышка ашырыла башлый. Аның максаты – 2024 елга урманнарны утильләштерү һәм торгызу балансын 100% нисбәттә тәэмин итү.

Менә шушы юлларны «Урман гасырдан артык яши» дигән китаптан укыгач, урманнарыбызның әчке халәтен югарырак дәрәҗәдәге кешеләр-

нең дә миннән иртәрәк күреп, белеп, тиешле карарларында хөкүмәт дәрәҗәсендә кабул итә башлаганнарын аңлагач, күңелемдәге борчулы хисләрем тынычлык дулкыннарында тибрәлә башладылар…

Димәк, Республикабыздагы урманнарның мәйданын да тиешле 25–30% җиткерәчәкләр! «Экология» һәм «Урманнар саклау» проекты тормышка ашырыла башлагач, урман эчендәге тәртип тә, Германия урманнарына охшаш булып, безнең «Горький» исемендәге парк кебек булачак. Иншалла!

*Казан, 17 декабрь 2024 ел.*

## ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ. РЕЦЕНЗИЯЛӘР

## ИНФОРМАЦИЯ О КРАЕВЕДЧЕСКИХ ТРУДАХ. РЕЦЕНЗИИ

ЯҢА КИТАП




Вышла новая книга по истории Золотой Орды. Это краткое популярное издание на татарском и русском языках, рассчитанное на массового читателя. В книге освещаются в сжатом виде все аспекты истории этого крупнейшего средневекового татарского государства. Тираж книги не очень большой – 2000 экз. Обращаемся к нашим сородичам с предложением своевременного приобретения данной работы.

## МИЛЛИ АШЛАР, СӘЛАМӘТЛЕКНЕ САКЛАУ ЮЛЛАРЫ

## НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ, ПУТИ СОХРАНЕНИЯ ЗДОРОВЬЯ

*Фирая Захарова*

### ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫ

***Туклануның нерв системасына йогынтысы.***

Туклану, әлбәттә, нерв системасына йогынты ясый. Шуның өчен дә табигый, витаминнарга һәм микроэлементларга бай ризыкларга өстенлек бирергә кирәк.

«*В*» *төркеме витаминнары* баш мие һәм нерв системасы эшчәнлегенә актив тәэсир итә. Әйтик, В1 (тиамин) ризыкны нерв күзәнәкләре өчен энергиягә әйләндерә. Ул җитеп бетмәгәндә кеше гасабилана башлый, төшенкелеккә бирелә. В5 стресска каршы торырга булыша, В6 киеренкелекне йомшарта, ярсуны басарга ярдәм итә. В12 витамины – В төркемендәге сигез витаминның берсе – организмда туплана һәм саклана ала. В12 фәкать хайваннардан ясалган азык-төлектә генә була. Хайваннарның ашказаны-эчәк юлында бактерияләр белән кушыла, кешенең юан эчәгендә барлыкка килсә дә нечкә эчәгендә генә үзләштерелә. Ягъни ашказаны-эчәк юлына азык белән бергә генә барып җитә ала. Ул сыер бавырында, сигезаяк, сельдь, скумбрия, йомырка сарысында, креветкада, каты сырда һәм башка ризыкларда була. Димәк, шуларны ашау мәслихәт. В12 (әле аны кобаламин дип тә йөртәләр) йөрәкне һәм кан тамырларын саклауда мөһим роль уйный, гомумән, нерв системасы яхшы гына эшләсен өчен зарур нәрсә.

Витаминнар иммун системасын гына түгел, нерв системасын да ныгыта.

*Е витамины* арыганда хәл кертә, нерв күзәнәкләре шәкелләнүдә (формалашуда) катнаша.

*Магний* мускул һәм мускул тукымасы йомшаруына йогынты ясый, киеренкелекне киметә, нерв импульсларын тапшыруда катнаша.

*Бакыр* гемоглобин системасында катнашучы һәм нерв системасын ныгытучы мөһим микроэлемент.

*Кальций* кан оюда, мускулларның саклануында һәм күзәнәкләргә нерв импульслары тапшыруда, ярсу һәм тоткарлану барышында катнаша.

*Калий* мускулларның йомшаруына, нерв һәм йөрәк-кан тамырлары системасын җайга салуга булыша.

*Хром* нерв күзәнәкләренә уңай йогынты ясый, арыганлыкны, таркаулыкны җиңәргә ярдәм итә.

*Фосфор* үзәк һәм перифериядәге нерв системасы эшчәнлеген җайга сала.

*Йод* – үзәк нерв системасы эшчәнлеген җайга салучы микроэлемент.

***Нерв системасы өчен файдалы азык-төлек.***

*Чикләвек* организмны майларга, витаминнарга һәм микроэлементларга баета. Нерв системасы аңа мохтаҗ. Чикләвекләрнең күбесе когнитив функцияләрне, игътибар туплауны яхшырта, хәвефләнүне киметә.

*Шоколад* мәгълүм эндорфиннар чыганагы гына түгел, туклану һәм баш миен ял иттерү өчен яхшы ярдәмче.

*Үлән чәен* эчү нерв системасына уңай йогынты ясый, киң колачлы тәэсир итә.

*Бананда* магний һәм кальций күп. Әлеге матдәләр мускулларда йомшару һәм киеренкеләнү барышына җавап бирә. Аларны йөрәк-кан тамырлары системасы да үз күрә.

*Яшел чәйдәге* С витамины һәм теанин аминокислотасы кәефне яхшырта, киеренкелекне бетерә, тонусны күтәрә, шул ук вакытта йомшарта да.

*Сөт ризыкларын* үзләштергән сурәттә йокысызлыктан ярдәм була, киеренкелекне бетерә. Сыйфатлы, табигый ризыкны күздә тотуыбыз.

*Яфраклы яшелчәләр* туклану барышында никадәр күбрәк булса, шулкадәр әйбәтрәк. Берүк вакытта нерв системасын тынычландырып һәм йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеген яхшыртып, алар кешегә көч-куәт бирә.

*Авокадода* туендырылмаган майлар бик күп. Ул йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системасын ныгыта. А төркемендәге витаминнар күп булу сәбәпле, стресска каршы торучы яхшы чара санала.

*Йомырка* сарысындагы фосфор нерв системасы эшчәнлеген җайга сала. В6 шулай ук гасабилануны бетерә, триктофан кәефне күтәрә. Бер йомыркада 125 мг холин бар. Әлеге матдә нерв импульсларын тапшыру өчен зарури булган миелин тышчасын коруда катнаша. Холин (В6) шулай ук гасабилануны, ярсуны бетерә.

*Бөртекле ярмаларда* нерв системасы эшчәнлеген хуплап тору өчен зарур булган В1 витамины бар.

